# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2020 1(25)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ХӘМИДОВА Ч.И.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Телицин Н.Н.* Борынгы уйгур телендәге парлы фигыльләрне интепретацияләүгә карата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дини лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
*Мөхиярова Р.Х., Закиров Р.А.* XXI йөз башы язма әдәби тел лексикасының кайбер үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . 21
*Галиуллина Г.Р.* Хәзерге татар гаиләләрендә туганлык атамаларының кулланылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Шәрипова А.С.* XX йөз башы азәрбайҗан-татар әдәби-мәдәни багланышларын ныгытуда Нариман Наримановның роле . . . . . 36
*Насыйбуллина Н.Ш.* Тукайның остазы – Мирхәйдәр Чулпаный . . 43
*Юсупова Н.М.* 1960–1980 еллар татар шигъриятендә яшерен эчтәлек һәм аны җиткерү юллары . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
*Каюмова Г.И.* Ризван Хәмид драматургиясендә психологизм . . . 60

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Сәлахова Э.К.* Миңлебай авылы мулласы Гыйльман хәзрәтнең мәгърифәтчелек эшчәнлеге (1870–1900 еллар) . . . . . . . . . . 71

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Хөсәенова Г.Р.* Пермь төбәге әкиятләре: охшаш сюжетлар һәм мәдәни кыйммәтләр *(Пермь төбәгендә җыелган фольклор материаллары нигезендә)* . . 77

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Сәгъдиева Р.К.* Татар теле дәресләрендә толерантлык . . . . . . . 83

### СӘНГАТЬ

*Шкляева Л.М.* Ульяновск өлкәсе мишәрләрендә укалап чигү *(Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ экспедициясе нәтиҗәләре буенча)* . . 90
*Галимова Э.М.* Сәгыйть Сүнчәләй һәм музыка . . . . . . . . . . 100
*Савченко* Е.Ф. Рәссамнар иҗатында Сөембикә портретлары . . . 104

### ЭПИГРАФИКА

*Гайнетдинов А.М.* Казанның Дары бистәсе зираты ташъязмалары . 110

### ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Сибгатуллина Ә.Т.* «Нәселем – Казаннан»: Төркия эшчеләр партиясе рәисе Бәһиҗә Боран (1910–1987) . . . . . . . . . . . . 115

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Зәйнәп Максудова, Шакир Абилов.* Шагыйрь Сөләйман Саксини һәм аның «Дастане Могҗизат» әсәре (XII йөз) . . . . . . . . . . 121

**ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Булатова Ә.К.* Азнакай районы Мөслим авылының җирле сөйләш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Сәйфуллина Ф.С.* Әлфрид Бостановның «Зәйнәп Максудова китапханәсе» (Мәскәү: «Мәрҗани» басма йорты, 2019) китабына рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

*Розенберг Н.А.* Р.Р. Солтанованың «Татар театры сценографиясе: төп үсеш этаплары һәм закончалыклары (XX – XXI гасыр башы)» монографиясе турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

**ФӘННИ АЧЫШЛАР ЭЗЕННӘН**

*Хәертдинов Р.Ә., Равилов Р.Х., Әхмәтов Т.М., Камалдинов И.Н.* Татарстан терлекчелегендә селекцион казанышлар . . . . . . . 175

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Телицин Н.Н.* К интерпретации парных глаголов в древнеуйгурском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Мирхаев Р.Ф.* Особенности употребления религиозной лексики в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
*Мухиярова Р.Х., Закиров Р.А.* Некоторые особенности лексики татарского литературного языка начала XXI века . . . . . . . . 21
*Галиуллина Г.Р.* Особенности функционирования родственной терминологии в современных татарских семьях . . . . . . . . . . . 28

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Шарипова А.С.* Вклад Наримана Нариманова в развитие азербайджано-татарских литературно-культурных связей в начале XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
*Насибуллина Н.Ш.* Мирхайдар Чулпаный – духовный наставник Тукая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
*Юсупова Н.М.* Прием иносказательности в татарской поэзии 1960–1980-х годов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
*Каюмова Г.И.* Психологизм в драматургии Ризвана Хамида . . . . 60

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Салахова Э.К.* Просветительская деятельность муллы (религиозного деятеля) деревни Миннебаево Гильмана Ибрагимова (1870–1900 годы) . . . . . . . . . . . . . . . . . 71

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х., Хусаинова Г.Р.* Сказки Пермского края: схожие сюжеты и культурные ценности *(на основе фольклорных материалов, собранных в Пермском крае)* . . 77

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Сагдиева Р.К.* Толерантность на уроках татарского языка . . . . . . . 83

### ИСКУССТВО

*Шкляева Л.М.* Золотное шитье у татар-мишарей Ульяновской области *(по итогам экспедиций ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
*Галимова Э.М.* Сагит Сунчелей и музыка . . . . . . . . . . . . 100
*Савченко* Е.Ф. Портреты Сююмбике в творчестве художников . . 104

### ЭПИГРАФИКА

*Гайнутдинов А.М.* Эпиграфические памятники на кладбище Пороховой слободы Казани . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110

## ПЕРСОНАЛИИ

*Сибгатуллина А.Т.* «Мой род из Казани»: руководитель Рабочей партии Турции Бехидже Боран (1910–1987) . . . . . . . . . . . . 115

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Зайнап Максудова, Шакир Абилов.* Поэт Сулейман Саксини и его произведение «Дастане Могҗизат» (XII в.) . . . . . . . . . . 121

## ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Булатова Ә.К.* Диалектологические особенности речи жителей села Муслюмово Азнакаевского района Республики Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

## НОВЫЕ КНИГИ

*Сайфуллина Ф.С.* Рецензия на книгу Альфрида Бустанова «Библиотека Зайнап Максудовой» (Москва: ИД «Марджани», 2019) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

*Розенберг Н.А.* О монографии Р.Р. Султановой «Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI в.)» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ОТКРЫТИЙ

*Хаертдинов Р.А., Равилов Р.Х., Ахметов Т.М., Камалдинов И.Н.* Селекционные достижения в животноводстве Республики Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.132

*Н.Н. Телицин*

# БОРЫНГЫ УЙГУР ТЕЛЕНДӘГЕ ПАРЛЫ ФИГЫЛЬЛӘРНЕ ИНТЕПРЕТАЦИЯЛӘҮГӘ КАРАТА

Древнетюркская лексика представляет собой огромный пласт общетюркской лексики, которая является предметом многочисленных исследований. Одним из сложных вопросов изучения древнетюркской лексики можно назвать вопрос интерпретации парных слов. Для древнеуйгурского языка, в отличии от других зафиксированных в памятниках древнейших тюркских языков, характерны парные слова модели «имя-имя», «глагол-глагол» и т. п., интерпретация которых вызывает определенные вопросы.

**Ключевые слова:** парные слова, древнеуйгурский язык, тюркские языки, лексика.

Old Turkic vocabulary is a huge layer of common Turkic vocabulary, which is the subject of numerous studies. One of the difficult issues of studying the Old Turkic vocabulary is the question of the interpretation of pair words. The paired words of the model “name-name”, “verb-verb” etc. are characteristic for the Old Uyghur language, in contrast to the other Old Turkic languages recorded in monuments, the interpretation of these paired words raises certain questions.

**Keywords:** paired words, Old Uygur language, Turkic languages, vocabulary.

Иң борынгы төрки истәлекләрнең телен өйрәнү төрки телләр төзелешенең хәзерге халәтен яхшырак аңларга, аларның үсеш тенденцияләрен билгеләргә мөмкинлек бирә. Морфология, синтаксис, семантика буенча тикшеренүләр белән беррәттән, лексикологик эзләнүләр үткәрүне дә мөһим юнәлеш дип танырга кирәк. Борынгы төрки лексика – күпсанлы тикшеренүләр предметы булган гомумтөрки лексиканың гаять зур катламы.

Парлы сүзләрне (биномнарны) интерпретацияләү мәсьәләсен борынгы төрки лексиканы өйрәнүнең иң катлаулы мәсьәләләреннән берсе дип атарга мөмкин [Наделяев, с. 35].

А.Н. Кононов фикеренчә, парлы сүзләр дигәндә ике сүзне кушу юлы белән ясалган, һәм компонентларның лексик мәгънәсенә һәм формасына бәйле рәвештә, лексик мәгънәләрнең компонентларындагы җыю, гомумиләштерү, экспрессивлык яки стилистик модификацияләр семантикасын алган кушма сүзләр аңлашыла [Кононов, с. 135–138]. Мондый тезмәләрне төрки һәм монгол телләре өчен хас дип танырга кирәк. Аларда «ике башлангыч нигез уртак семантик кырда урнаша, катлаулы нигез бер очракта – абстракт мәгънәгә, икенчеләрендә – зуррак җыелмалылыкка, кайчагында аларның мәгънәләре суммасына ия була» [Наделяев, с. 35].

Парлы сүзләрнең ясалу һәм яшәү-кулланылу сәбәпләре, аларның төрки телләрдәге мәгънәләре турында галимнәр төрле фикерләр белдерәләр. Әйтик, мәсәлән, аларның барлыкка килүенең «төп сәбәбе» булып «кардәш кабилә һәм халыкларның телләре кушылу» санала [Ганиев, с. 100]. Парлы сүзләрнең функцияләрен һәм мәгънәләрен өйрәнүгә күпсанлы хезмәтләр багышланган, һәм аларда күбесенчә семантик һәм структур аспект карала. Нәтиҗәләр, нигездә, аларның мәгънәсе һәр компонентның мәгънәсеннән барлыкка килүе турындагы фаразга кайтып кала, нәтиҗәдә уртак семантика, җыелмалылык, интенсивлык күзәтелә һ.б.

Безнең карашыбызча, борынгы төрки лексиканы өйрәнү бу мәсьәләгә ачыклык кертергә мөмкинлек бирәчәк. Күбрәк борынгы уйгур теле буларак билгеле токуз-угыз кабиләләре теле теркәлгән истәлекләрнең текстлары аеруча зур кызыксыну уята. Борынгы уйгур теленең барлыкка килүен һәм үсә башлавын Уйгур каганлыгы яшәгән чор (744–840 еллар) һәм уйгур аксөякләренең манихейлык динен кабул итүе белән бәйлиләр. Нәкъ менә шушы фактны, мөгаен, уйгур язуының үсә башлавы булмаса да, һәрхәлдә, аның киң таралыш алуы дип санарга кирәк, чөнки манихейлык кертелү белән, күрәсең, уйгур язуы да алга таба үсеш кичерә һәм ул, манихей язуы белән беррәттән, Үзәк Азиянең бик зур территорияләрендә аларның дини җәмгыятендә кулланыла. Бу уйгур язуында язылган иң беренче әсәр – «Манихейлыларның тәүбә догасы» («Хуастуанифт») белән дә раслана. Бу әсәр, традицион рәвештә, борынгы фарсы яки борынгы грек теленнән уйгур теленә тәрҗемә булып санала. Әмма, В.В. Радлов фикеренчә, текст яхшы төрки телдә язылган һәм бер дә тәрҗемәгә охшамый. Башка мәгълүматлар буенча, башлангыч этап «Нирванасутра» сутрасының (якынча VI гасыр) тәрҗемәсе белән, ә чәчәк ату чоры – IX–XIII гасырларга бәйләп карала. Безгә кадәр килеп җиткән истәлекләрнең күбесе – дини, күбрәк буддачылык, әсәрләрнең согыд, тохар, кытай телләреннән һәм санскриттан тәрҗемәләре, манихейлык һәм христианлык әсәрләренең тәрҗемәләре сирәгрәк очрый.

В.В. Радлов тарафыннан борынгы уйгур язулы күпсанлы истәлекләр бастырып чыгарылган. Аларга Tišastvustik дип аталган буддачылык сутрасының борынгы уйгур теленә тәрҗемәсе, Suvarnaprabhāsa («Алтын балкыш»), Kuan-ši-im Pusar (Sadharmapundarīka («Яхшы канун лотосы») сутрасының кытай телендәге версиясенең 25 нче бүлеге) сутралары, А. Грюневельд җитәкчелегендәге беренче немец экспедициясе (1902–1903 еллар) документлары (46 өзектән тора), атаклы Xuāstuānīft («Манихейлыларның тәүбә догасы»), Säkiz Yükmäk сутрасының уйгур тексты һ.б. карый.

Нәкъ менә шундый истәлекләрнең лексикасын өйрәнү борынгы һәм хәзерге төрки телләр үсешендә теге яки бу тенденцияләр барлыкка килүнең беренче сәбәпләрен ачыкларга мөмкинлек бирә дә.

Борынгы уйгур телендәге мондый төзелмәләрнең яшәү-кулланылу үзенчәлекләрен бөтен тулылыгында күрсәтүче берничә парлы сүзне күрсәтеп үтәргә кирәк.

bu savlar öz köŋülčä qaryšmaq jaršmalašmaqlyq üzä išlägülük bulγuluq ärmäz (BTT II (195–197) «Бу сүзләрне, чагыштыру өчен (?), үзең теләгәнчә кулланырга һәм файдаланырга ярамый (?)»

Бу мисалда без «парлы фигыльләр»нең ике парын күзәтәбез (кабатлануым өчен гафу итегез. – *Н.Т.*): qaryš- jaršmalaš- һәм išlä- bul-. Аларны тикшергәндә, компонентларның үзара бәйләнеше мәсьәләсендә шактый кыенлыклар белән очрашабыз.

qaryš- jaršmalaš-

Беренче компонент (qaryš- фигыле) күп кенә истәлекләр буенча билгеле һәм текстларда аның түбәндәге мәгънәләрен очратабыз: «катышу, бөрешү, бәрелешү, бәрелешкә керү, дошманлашу һ.б.»

Тикшеренүчеләр jaršmalaš- фигыленең берничә мәгънәсен билгелиләр:

– «sich anpassen» (BTT II) – җайлашу, конкуренция алып бару; җайлаштыру, төзәтмәләр кертү һ.б.

– «Äquivalent von jing 競 (эквивалент 競) – ярышу, узышу, конкуренция алып бару һ.б. (VATEC (Vorislamische Alttürkische Texte: Elektronisches Corpus))

– «ярышу» (Тугушева).

jaršmalaš- фигыленең jarš- ~ jarïš- фигыленең субъектив бәя формасы булуын һәм истәлекләрдә сирәк очравын исәпкә алсак [Телицин 2017: 87], qaryš- jaršmalaš- парында төп «лексик йөкләнеш» беренче компонентка төшә, ә икенчесе әлеге контекстта туры килә торган мәгънә буенча сайлап алынган дип нәтиҗә чыгарырга мөмкин.

Әлеге нәтиҗәне игътибарга алсак, ул вакытта истәлекләрдә теркәлгән башка фигыль парларын да башкача интерпретацияләргә мөмкин: мондый тезмәләрдә кулланыла торган фигыльләр төрле «мәгънәләргә» ия булалар, әмма мәгънәләре буенча сайлап алыналар, һәм әлеге контекстта коммуникант тарафыннан охшаш итеп кабул ителәләр. Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк, төп «лексик» йөкләнеш беренче компонентка төшә. Мондый «рольләр бүленеше» төп һәм ярдәмче фигыльләрдән торган күп кенә аналитик фигыль тезмәләрендә күзәтелә.

jaq- japsyn- (Suv 240 22), ilin- japsyn- (Suv 148 15), ört- kizlä- (Suv 138 2), ört- köšit- (TT X 36), qarïš- qavïš- (TT VI 324), qatïl- qavïš- (Suv 132 11), qatïl- qarïl- (MK, QB) һ.б.

Югарыда китерелгән һәм башка күпсанлы мисалларны анализлаганда, мондый фигыль тезмәләренең, беренчедән, бәян ителгән чынбарлык күренешләренең «образлылыгын» тапшыру максаты белән мәгънәләре бердәй булмаган, ләкин мәгънә ягыннан охшаш эш-хәрәкәтләрне тапшыру өчен файдаланылуын фаразларга мөмкин. Икенчедән, кулланыла торган фигыльләр бер үк фигыльләр белән парлы тезмәләр ясый алмыйлар. Мәсәлән, qarïš- qavïš- һәм qatïl- qavïš- истәлекләрнең текстларында билгеләнгән, ә qatïl- qarïš- фигыле белән очрамый, шулай ук qatïl- qarïl- билгеләнгән, ә qavïš- qarïl- белән бергә – юк.

**Әдәбият**

*Ганиев Ф.А*. Функциональное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань, 2009. 264 с.

*Кононов А.Н.* Грамматика современного узбекского литературного языка. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 446 с.

*Наделяев В.М.* Современный монгольский язык. Морфология. Новосибирск: Наука, 1988. 113 с.

*Телицин Н.Н*. К вопросу о формах субъективной оценки в древнеуйгурском языке // Актуальные вопросы тюркологических исследований: Международная научная конференция XIX Ивановские чтения, 19 мая 2017 г.: Материалы конференции / под ред. Н.Н. Телицина. СПб.: Центр содействия образованию, 2017. С. 87–90.

***Телицин Николай Николаевич,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Санкт-Петербург дәүләт университеты Көнчыгыш факультетының*
*төрки телләр филологиясе кафедрасы мөдире*

УДК 81′373+82-3

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ДИНИ ЛЕКСИКАНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье рассматриваются вопросы изучения лексической структуры произведений татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков в парадигматическом и синтагматическом аспектах. Далее на основе результатов исследования автором предпринимается попытка реконструции языкового портрета татарской просветительской интеллигенции, что в свою очередь позволит прояснить ряд моментов, связанных с расширением функциональных и общественных сфер употребления татарского языка в этот период. Считается, что оно во многом связано с деятельностью представителей указанной социальной группы татарского общества конца XIX – начала XX веков.

**Ключевые слова:** старотатарский письменно-литературный язык, язык татарской просветительской прозы, парадигматический аспект, синтагматический аспект, религиозная картина.

The article discusses the study of the lexical structure of Tatar educational prose of the late XIX – early XX centuries in the paradigmatic and syntagmatic aspects. The author attempts to reconstruct on the basis of study results the linguistic portrait of the Tatar educational intelligentsia, which in turn will clarify a number of points related to the expansion of the functional and social spheres of the use of the Tatar language during this period. It is believed that it is largely associated with the activities of representatives of the indicated social group of the Tatar society of the late XIX – early XX centuries.

**Keywords:** Old Tatar written and literary language, language of Tatar educational prose, paradigmatic aspect, syntagmatic aspect, religious picture.

Хәзерге тел белемендә теге яки бу чорда иҗат ителгән әдәби әсәрләрнең теле парадигматик һәм синтагматик аспектларда өйрәнелә. Беренче очракта өйрәнелә торган текстларның лексик структурасы һәм телнең лексик системасы арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуга игътибар бирелсә, икенче очракта әсәрне язу өчен сайлап алынган лексик берәмлекләрнең авторлар тарафыннан кулланылыш үзенчәлекләре тикшерелә [Супрун, 1995, с. 55–62]. Шуның белән бергә әдәби әсәрләрнең телен әлеге ике аспектта тикшерү алар язылган чорда язма әдәби тел нормаларын һәм традицияләрен торгызу, әсәрләрнең жанр үзенчәлекләренә һәм аларның авторларының социаль чыгышын билгеләүче төркемнәргә мөнәсәбәттә телнең иҗтимагый кулланылыш белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган функциональ-стилистик һәм социаль яктан аерымлануын өйрәнү ягыннан зур әһәмияткә ия. Бу яктан караганда, татар әдәбияты һәм татар әдәби теле дәверне башлап

җибәргән XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре [Мирхәев, 2015, б. 29], аларда кулланылган лексик материал әлеге чорда формалашкан татар мәгърифәтчелек интеллигенциясенең тел портретын торгызырга, аның берәмлекләре белән иске татар язма әдәби теленең нормалары һәм традицияләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Фәнни-тикшеренү эше белән бәйле барлык материалны бер мәкалә кысаларында бирү мөмкин булмаганлыктан, әлеге очракта язма чыганакларда гасырлар дәвамында кулланылып килгән дини лексика [Мирхәев, 2017, б. 22] белән чикләндек. Биредә әлеге төр лексик берәмлекләрдән иске татар язма әдәби теленең традицион берәмлекләреннән саналган *дин, диндар, шәригәт, иман, намаз, доға, мәхшәр, оҗмах, җәннәт, җәһәннәм, тәмуғ, гөнаһ, гөнаһлы, дөнйа, ахирәт, хәрәм, хәләл* һ.б. сүзләрнең кулланылышы күзәтелә.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) Аллаһы Тәгаләнең, гомумән, нинди дә булса югары көчләрнең чынлап та булуына, барлыгына ышану, инану белән бәйле халәт; 2) Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы; 3) кайсы да булса диндәге руханиларның һәм дин тотучыларның дини оешмасы мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *дин* сүзе [Татар теленең аңлатмалы..., III т., 2017, б. 176] М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында икенче – ‘Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы’ мәгънәсендә кулланыла: *Менла сәнең игтиқадың пәк йахшыдыр, – сүзә керешде Әбүзәр бәк, – туғры әйтәсен, дине исламән хақиқат дин, ән олуғ дин, бөйлә иғтиқадда мин үзем дә торамын* [Акъегет, 1886, б. 21].

Әлеге сүз нигезендә барлыкка килгән *диндар* лексик берәмлеге әсәрдә билгеле персонажга мөнәсәбәттә кешенең дингә ышану белән бәйле рухи сыйфатын атап килә: *Ғайәт диндар, йахшы wә хақыйқәтле қадын иде* [Акъегет, 1886, б. 47].

‘Мөселманнарның Коръәндә билгеләнгән әдәп, хокук, тәртип кагыйдәләре җыелмасы һәм шул кагыйдәләрне Аллаһ кушканча үтәү тәртибе аңлатмалары’ мәгънәсендәге гарәп асыллы *шәригәт* сүзе чыганакта публицистик чигенешләрдә иҗтимагый коннотацияләр белән баетылып кулланыла: *Инглиз кеби кәсебкәр улмадығымыза сәбәб кәзалик үземезмез; һич шәриғәтемез дәгел. Билғақес шәриғәт йулы илә барсақ, безгә инглиздән мәһарәтлерәк булмақ ләзем кәлә* [Акъегет, 1886, б. 22].

‘Ислам динен тотучылар өчен фарыз биш төп гамәлнең икенчесе: кабул ителгән тәртиптә, тәүлекнең билгеләнгән вакытында көнгә биш тапкыр үтәлә торган (иртәнге намаз, өйлә намазы, икенде намазы, ахшам намазы, ястү намазы) гыйбадәт’ мәгънәсендәге гарәп асыллы *намаз* сүзе әсәрдә *җомға намазы, йәстү намазы* кебек сүзтезмәләр составында туры мәгънәсендә теркәлде: *Җомға намазыны уқыдық-*

*дан соңра Хисаметдин менла атны чанайа йигеб, ...* [Акъегет, 1886, б. 7]; *Мосахәбәт исә менла йәсту намазыны уқыйанҗайа дәк дәwам итде* [Акъегет, 1886, б. 11].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) дини кешеләрнең, дин тотучыларның Аллаһыга аны мактап, аннан сорап, ялварып әйткән сүзләре; 2) дин тотучыларның Аллаһыга, изгеләргә мөрәҗәгать иткәндә һәм дини йолалар вакытында әйтелгән сүзләре, махсус дини эчтәлектәге текст; 3) фатиха мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *доға* сүзе [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 187] әсәрдә *доғалар эчереб* конструкциясе составында ‘догалар язылган кәгазь салып өшкерелгән су’ мәгънәсендә теркәлде: *Wә бу хәйлә илә Хәнифә туташқа доғалар эчереб wә айағына тупрақлары ташлаб wә башқа буның кеби һөнәрләр эшләб, ишан хәзрәтләре Ғаббас ағада берәр һәфтә қадәр зыйафәт итде* [Акъегет, 1886, б. 50].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) фани дөньяда гөнаһлы гамәл кылмаган, ислам дине кануннарын чын күңеленнән үтәгән хак мөселманнар өчен бакый дөньяда вәгъдә ителгән рәхәт тормыш, оҗмах; 2) бәхет һәм ләззәт дөньясы, рәхәт тормыш; 3) рәхәт яшәү өчен бөтен мөмкинлекләре булган җир, урын; 4) кешенең үзе өчен кадерле булган тирәлеге, үз почмагы, өе; булган тормышыннан канәгатьлек; 5) җанга һәм тәнгә ял, дәва бирә торган рәхәтлек; 6) бик матур җир мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *җәннәт* сүзе [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 290] әсәрдә үзенең беренче туры мәгънәсендә кулланыла: *Атасы нәйә лазем? Ул wафат, Алла җәннәт вирсен* [Акъегет, 1886, б. 7]; *Бер кемсә хәләл кәсеб қылмақындан арыб кич үткәрсә, wәҗеб булыр аңа җәннәт* [Акъегет, 1886, б. 23].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) дин кануннарын бозу, шәригать таләпләрен үтәмәүдән гыйбарәт Алла каршындагы гаеп, язык; 2) традиция, тәртип, әдәп-әхлак кагыйдәләрен һ.б.ш. бозу; гаеп эш мәгънәләре теркәлгән фарсы асыллы *гөнаһ* сүзе [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 100] чыганакта беренче мәгънәсендә генә кулланыла: *Нәдер, йә Алла, қанғы гөнаһларыма күрә, бәне ғазаб идәсен* [Акъегет, 1886, б. 55].

Шул ук вакытта аның нигезендә барлыкка килгән һәм әлеге күренешкә мөнәсәбәттә кешегә хас булган сыйфатны белдереп килүче *гөнаһлы, гөнаһкәр* лексик берәмлекләрнең семантикасында, иҗтимагый контекстта кулланылу сәбәпле, икенче мәгънә алгы планга чыга: *Милкең wә ғадәләтең улмайыб ике қадын алсаң, хоқуқларыны вирмәйән гөнаһлы буласын* [Акъегет, 1886, б. 11]; *Бәс wақытны да бушқа сарыф итсәң, гөнаһкәр буласын* [Акъегет, 1886, б. 65].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) дин, шәригать тарафыннан тыелган; 2) алдашып, урлашып, законсыз юл белән табылган мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *хәрәм* сүзен [Татар теленең аңлатмалы ..., III т., 1981, б. 385] автор нигездә ике мәгънәсендә дә, ләкин образлы коннотацияләр белән баетып куллана: ... *мәсәлән, кешене әнҗедәрләр, ғайренең малына әл узатыб, хәрәм йейәрләр*

[Акъегет, 1886, б. 49]; *Сәрмайаны бушқа исраф хәрәмдер* [Акъегет, 1886, б. 65].

Аның 1) шәригать тарафыннан тыелмаган; 2) намуслы; 3) никахлы мәгънәләрен белдерә торган гарәп асыллы антонимы – *хәләл* лексемасы әсәрдә икенче мәгънәдә теркәлде: *... йахшы wә хәләл кәсебе билгақес саwабдан хисаб идәр* [Акъегет, 1886, б. 22].

Сүзнең сөйләм теле өчен хас булган өченче – ‘никахлы’ мәгънәсе *хәләл улу* тезмә фигылендә чагылыш таба: *Бәне әвләнмәк морадаңызы күреб мәсрүр улдым, сезә хәләл улмақ бәңа бик хушдыр* [Акъегет, 1886, б. 37].

*Дин* сүзен З. Бигиев күбрәк ‘Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы’ мәгънәсендә куллана: *...дин wә дөнйамыза файдалы улыб, ата wә бабалары табмайан нам wә шөһрәтләре табыб, ...* [Бигиев, 1887, б. 62]; *Следователь Маһруйның исеме, фамилиясе, званиесендән wә динендән сөал қылгач, ...* [Бигиев, 1890, б. 24].

*Кәфер дине, ислам дине* сүзтезмәләре составында аның семантикасы теге яки бу дингә мөнәсәбәттә билгелелек мәгънә төсмеренә ия була: *Кәфернең көферлегендән wә ни-нәрсә кәфер дине эчендә вардыр – барчасындин биздем! Қабул қылдым ислам динене wә ни-нәрсә кем ислам дине эчендә вардыр – барчасыны қабул қылдым, ...* [Бигиев, 1887, б. 77].

Шуның белән бергә автор әлеге сүзне *дин тотмақ, дин йулында улыб, дин қуәте* кебек гыйбарәләрдә образлы һәм иҗтимагый коннотацияләр белән баетып куллана: *Әмма дүрт-биш сәнә мөқәддәм Ростовда дин тотмақ, хәрәм wә мәкруһатдан иҗтинаб идеб, фәраиз wә wәҗибаты әда қылмақ бик аз иде* [Бигиев, 1890, б. 4]; *...һәрwақытда дин йулында улыб, хәрам wә мәкруһатдан иҗтинаб қылыб, биш wақыт намазы мәсҗедә килеб җәмәгәтлә әда қылалар* [Бигиев, 1890, б. 4]; *... әһали файдасы, дин қуәте wә дөнйа рәхәте өчен гәм чигеб, ...* [Бигиев, 1890, б. 10].

‘Мөселманнарның Коръәндә билгеләнгән әдәп, хокук, тәртип кагыйдәләре җыелмасы һәм шул кагыйдәләрне Аллаһ кушканча үтәү тәртибе аңлатмалары’ мәгънәсендәге гарәп асыллы *шәригәт* сүзе үзенең туры мәгънәсендә авторның «Гөнаһе кәбаир» романында гына теркәлде: *...ислам шәригәте муҗибенчә дәфен қылынмасыны риҗа қылды* [Бигиев, 1890, б. 57].

‘Ислам динен тотучылар өчен фарыз биш төп гамәлнең икенчесе: кабул ителгән тәртиптә, тәүлекнең билгеләнгән вакытында көнгә биш тапкыр үтәлә торган гыйбадәт’ гарәп асыллы *намаз* сүзе язучы әсәрләрендә үзенең туры мәгънәсендә һәм аерым лексема буларак, һәм *җеназа намазы, йәстү намазы, җомга намазы, сабах намазы, йәстү намазы, икенде намазы, ахшам намазы* сүзтезмәләре составында семантикасы конретлаштырылып кулланыла: *Намаз тәмам улдықдан соңра хадимләрнең берсе Нигмәтулла бай өчен чәй – самавар хазыр-*

*ламыш* [Бигиев, 1887, б. 9]; *Муса әфәнденең сөйләшүендән мәрхүмә Зөләйханың җеназа намазында улуы да аңлашыладыр* [Бигиев, 1887, б. 9]; *... йәстү намазына шөруг қылыб, ...* [Бигиев, 1887, б. 9]; *Намаз гақыйбендә мәсҗед йанында мулла илә ике кемсәнә мөсафәхә қылыб күрешделәр* [Бигиев, 1890, б. 3]; *Җомга намазы wақыты йидмеш, ...* [Бигиев, 1890, б. 3]; *Сабах намазын әда қылыб мәсҗеддән қайтмышлар* [Бигиев, 1890, б. 5] һ.б.

*Доға* сүзе З. Бигиевнең әсәрләрендә үзенең туры ‘дини кешеләрнең, дин тотучыларның Аллаһыга аны мактап, аннан сорап, ялварып әйткән сүзләре’ мәгънәсендә кулланыла: *Бәнем әгмәле хасәнәтем йуқ, бән сезнең доғаларыңыза мохтаҗмын!* [Бигиев, 1887, б. 70]; *Қөррәте гәйнем wә гайәт сәwеклем Маһруй! Лә йоғадде wә лә йохса доға wә сәламемездер* [Бигиев, 1890, б. 17].

*Гөнаһ* сүзе З. Бигиев әсәрләрендә ‘традиция, тәртип, әдәп-әхлак кагыйдәләрен һ.б.ш. бозу; гаеп эш’ мәгънәсендә кулланыла: *Нахақ йирдә һәлақ қылдық Муса Салиховны, гөнаһ булыр сезгә!* [Бигиев, 1887, б. 51]; *Бәнем гөнаһларым өчен хөкемем тәмам: үз-үземне қәтел қыламын* [Бигиев, 1887, б. 69]; *... Алла сақласын, хараб булыр, гөнаһсы да бик зур ич* [Бигиев, 1890, б. 20]; *Йәшлекдә улан гөнаһлары халық wә җәнабе Хақ гафу бойырыр ...* [Бигиев, 1890, б. 62].

Әлеге мәгънә «Гөнаһе кәбаир» романында теркәлгән *гөнаһлы* лексик берәмлегенең семантикасында да чагылыш таба: *... романымызда мәхлут улан әшхасның әксәре гөнаһлы бәндәләр улыб, ...* [Бигиев, 1890, б. 2].

*Хәрәм* һәм *хәләл* сүзләре авторның «Гөнаһе кәбаир» романында гына теркәлде. Биредә автор *хәләл* сүзен дә *на хәләл* формасында, *хәрәм* сүзенең антонимы буларак, ‘дин, шәригать тарафыннан тыелган’ мәгънәсендә куллана: *... хәйләи шәргый wә на хәләл кәсебләр қылыб, ...* [Бигиев, 1890, б. 2]; *Әмма дүрт-биш сәнә мөқәддәм Ростовда дин тотмақ, хәрәм wә мәкруһатдан иҗтинаб идеб, фәраиз wә wәҗибаты әда қылмақ бик аз иде* [Бигиев, 1890, б. 4].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) материянең бербөтен тәшкил иткән барлык формалары; 2) галәмнең аерым бер өлеше, планета; 3) җир йөзе, анда булган терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы; 4) безне чолгап алган бар табигать, мохит; 5) җирдә яшәүче һәм яшәгән барлык кешеләр; кешелек җәмгыяте; 6) кешеләр тормышы, яшәеше, гомумән көнкүреш; 7) кешенең үлгәнчегә кадәр гомер иткән урыны; дөньялык һ.б. мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *дөнйа* сүзе [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 196] язучы әсәрләрендә нигездә ‘кешенең үлгәнчегә кадәр гомер иткән урыны; дөньялык’ мәгънәсендә кулланыла. Бу очракта ул Ислам динендә ‘үлгәннән соңгы тормыш, «теге дөнья»’ төшенчәсен белдереп килгән гарәп асыллы *ахирәт* сүзенә каршы куела: *... башқача дөнйа сүзләре сөйләшеб, байтақ wақыт чәй эчеб ултырдылар* [Бигиев, 1887, б. 12]; *Дөнйада сафа қылмақ бәндән қалыр* [Бигиев, 1887, б. 69]; *Дөнйада мөгәззәз wә ахирәтдә мөшәррәф улмақ – «әл-гыйлме гыйзз әт-дөнйа*

*wә шәрәф әл-ахирәт» улдыгычүн дә гыйлемә баглыдыр* [Бигиев, 1890, б. 7].

Шул ук вакытта «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романында аның ‘җир йөзе, анда булган терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы’ мәгънәсендә кулланылу очрагы да теркәлде: *Дөнйада Муса әфәнде фәқәт бер генә дәгел, ...* [Бигиев, 1887, б. 12].

«Гөнаһе кәбаир» романында теркәлгән *дөнйа рәхәте* сүтезмәсе составында ул образлы коннотациягә ия була: *... әһали файдасы, дин куәте wә дөнйа рәхәте ичүн гәм чигеб, ...* [Бигиев, 1890, б. 10].

Әлеге сүзләр белән бергә язучының «Гөнаһе кәбаир» романында Ислам динендә ‘кешелек дөньясының җирдә яшәүдән туктау көне, ерак бабалары һәм әбиләреннән башлап, бөтен буын үлгән кешеләрнең яңадан терелеп очрашуы, Алла алдында хисап бирү көне’ мәгънәсендәге һәм ‘үлгәннән соң, гөнаһлы кешеләрнең җанын газаплый торган урын, утлы тәмуг’ төшенчәләрен белдереп килгән *мәхшәр* һәм *җәһәннәм* лексемалары да теркәлде: *... йауме мәхшәрдә гафур әр-рәхим Алланың рәхмәте wә фазылына мөләқәт қылмасалар, әһле җәһәннәм улдуқлары аңлашачақдыр* [Бигиев, 1890, б. 2].

*Дин* сүзен Р. Фәхреддин ‘Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы’ мәгънәсендә иҗтимагый коннотацияләр белән баетып куллана: *Үз динене, үз делене, үз гореф wә гадәтене белмәгән кемсәнәгә ...* [Фәхреддин, 1899, б. 24]; *... вагон, парахуд, вокзал кеби урынларда дин мәсьәләләрендә мөназарә идешмәк һич мөнасыйб дәгел* [шунда ук, б. 50]; *Без исә бундан хәзрәтең безне маниг идүе дин ичүн дәгел, ...* [Фәхреддин, 1903, б. 85].

«Әсма яки гамәл вә җәза» романында теркәлгән *һәр дин, ислам дине* сүтезмәләрендә әлеге сүз билгелелек мәгънә төсмеренә ия була: *Һәр қаwем, һәр қабилә, һәр дин, һәр мәзһәбдә бер миқдар йаман wә әхлақсыз кемсәләр улыныр, ...* [шунда ук, б. 39]; *... зира әхлақ төзәтмәк ислам диненә мәхәббәт қуймақ ...* [Фәхреддин, 1903, б. 98].

Әлеге әсәрдә бу сүз нигезендә барлыкка килгән *диндар, дини* берәмлекләре кешенең дин тотуга мөнәсәбәттә барлыкка килгән рухи сыйфатын белдереп киләләр: *... боңа гақыллы, тәқwә, диндар, җәсур, мәрхәмәтле бер хатын мөйәссәр улды* [шунда ук, б. 5]; *Хәлбуки безем иске мөгаллим wә хәлфәләремез арасында бәгзы бер дини wә рәзил затлар йуқ дәгел иде!...* [шунда ук, б. 39].

*Шәригәт* сүзе авторның әсәрләрендә үзенең туры ‘мөселманнарның Коръәндә билгеләнгән әдәп, хокук, тәртип кагыйдәләре җыелмасы һәм шул кагыйдәләрне Аллаһ кушканча үтәү тәртибе аңлатмалары’ мәгънәсендә кулланыла: *Русча, францызча йазылган китаблардан ислам шәригәте хақында улганларыны күпләрене уқыдым* [Фәхреддин, 1899, б. 25]; *... шәригәтдә бойырылган wә йәки мәнг иделгән шәйләрнең ...* [шунда ук, б. 26]; *... сезең шәригәт қашында улан хезмәтләреңез ...* [Фәхреддин, 1903, б. 8]; *Бу тугрыда нә шәригәт wә нә низам нәзарында гөнаһым йуқдыр зан идәрем* [шунда ук, б. 37].

Алдагы авторларда күзәтелмәгән һәм татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) ышану, ышаныч, инану; 2) Ислам динендә: дин куйган тәгълиматларга чын күңелдән ышану, игътикат; 3) мөселман икәнлекне исбатлау, раслау, Аллага инануны белдерә торган дога сүзләре мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *иман* сүзе [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 513–514] Р. Фәхреддин әсәрләрендә нигездә икенче мәгънәсендә кулланыла: *Күбесе урамда деләнчелек идеб йөрүчедән гыйбарәт улган қыз балалар иман, иғтиқад wә ғыйлеме хәл белгәнләр, ...* [Фәхреддин, 1899, б. 45]; *... иман, ислам, уқымақ, йазмақ, ғыйлме хәл кеби шәриғәт хөкемләре ...* [шунда ук, б. 47]; *... ысулы иғтиқад, иман wә ислам, Рәсүле әкрәм wә сахабәләренең әхwәлене белергә wақыт йитмәмеш иде* [Фәхреддин , 1903, б. 46]; *Иман wә кәфер туғрысында улан хөкем йалңыз Аллаһы Тәғаләнең кәндесенә хас улыб, ...* [шунда ук, б. 100].

«Сәлимә яки гыйффәт» романында теркәлгән *тәқдиргә иман идү* образлы гыйбарәсендә аның семантикасында беренче мәгънә алгы планга чыга: *Тәқдиргә иман идүемез бу кеби әмерләрдә күңелемезе тәслийә идәр wә сабырға дәғwәт қылыр* [Фәхреддин, 1899, б. 77].

‘Ислам динен тотучылар өчен фарыз биш төп гамәлнең икенчесе: кабул ителгән тәртиптә, тәүлекнең билгеләнгән вакытында көнгә биш тапкыр үтәлә торган (иртәнге намаз, өйлә намазы, икенде намазы, ахшам намазы, ястү намазы) гыйбадәт’ гарәп асыллы *намаз* сүзе язучы әсәрләрендә үзенең туры мәгънәсендә һәм аерым лексема буларак, һәм *җомға намазы, ахшам намазы, фарыз намазларны, җомға wә ғайед намазлары* сүзтезмәләре составында конретлаштырылып кулланыла: *Таһарәт wә намаз тирәләрене һәм беләдер* [шунда ук, б. 41]; *... мөнбәрдә утырыб, җомға намазындан элек ...* [шунда ук, б. 70]; *Бере ахшам намазыны* (اخشام نمازنى) *уқыр ичүн шәм эзләтеб, намаз wақытыны уздырмыш иде* [Фәхреддин, 1903, б. 27]; *Һәр нә қадәр фарыз намазларны қалдырмаз исә дә, ...* [шунда ук, б. 32] һ.б.

‘Дини кешеләрнең, дин тотучыларның Аллаһыга аны мактап, аннан сорап, ялварып әйткән сүзләре’ туры мәгънәсендәге *доға* сүзен автор *усал доғалар, хәйер доғасы, бер-беренә зыд улан доғалары, сақлаб йөртмеш бер доғаны, сәвдергеч доғалар* сүзтезмә һәм конструкцияләрендә билгелелек мәгънә төсмере һәм аерым очракларда иҗтимагый коннотацияләр белән баетып куллана: *Буның ичүн безләрне батырландырған wә тәхриз иткән хәлфәләргә нә кеби усал доғалар қылырға белмәй идем, ...* [Фәхреддин, 1899, б. 55]; *... wә кемләрнең хәйер доғасы бәрәкәтендә бундай сәғадәтләргә наил улдығымны фикерләб, ...* [шунда ук, б. 79]; *Бичара бәндә!... Бер дақиқа эчендә бер-беренә зыд улан доғалары әйтмәкдәдер!...* [Фәхреддин, 1903, б. 44]; *... йанында ничә йыллардан бирү сақлаб йөртмеш бер доғаны уқыдыб, ...* [шунда ук, б. 69]; *... сәвдергеч доғалар йаздырыб китерер ...* [шунда ук, б. 72].

*Җәннәт* сүзен язучы үзенең ике әсәрендә дә халык арасында киң таралган әйтемдә ‘бәхет һәм ләззәт дөньясы, рәхәт тормыш’

мәгънәсендә куллана: *Җәннәт аналар айақ астында* [Фәхреддин, 1899, б. 68]; *Җәннәт аналар айагы астындадыр* [Фәхреддин, 1903, б. 94].

Моннан тыш «Сәлимә яки гыйффәт» романында әлеге сүзнең семантикасы *җәннәт кеби гүзәл* гыйбарәсендә образлы мәгънә төсмере белән баетыла: ... *башқорд сахраларының җәннәт кеби гүзәл һәм йәшел бер wақытында үтеб китмешләрдер* [Фәхреддин, 1899, б. 3].

Әлеге үзенчәлек шул ук әсәрдә *җәннәт* сүзенең синонимы булган *оҗмах* лексемасының кулланылышында да күзәтелә: *Шагыйрьләремезнең "дөнйа оҗмахы" дийә тәусыйф итдекләре мәдрәсә почмагында улган урынымдан биздем,* ... [шунда ук, б. 7]; *Булындыгым урын оҗмах, қаршымда торган қызны хур дийә хөкем идеб,* ... [Фәхреддин, 1899, б. 80].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә 1) дини тәгълимат буенча: үлгәннән соң, гөнаһлы кешеләрнең җанын газаплый торган урын, утлы тәмуг; 2) күч. түзә алмаслык авыр шартлар, газаплы, интектергеч тормыш; 3) күч. үлем-кырылыш, сугыш кырындагы коточкыч хәлләр, дәһшәт; 4) күч. тавыш-талаш, шау-шу, чуалчык, буталчык; гаугалы вакыт; 5) күч. бик ерак, әллә кайдагы урын, билгесез җир мәгънәләре теркәлгән гарәп асыллы *җәһәннәм* сүзен [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2016, б. 297] Р. Фәхреддин беренче мәгънәсендә образлы, аерым очракларда иҗтимагый коннотацияләр белән баетып файдалана. Әлеге үзенчәлек аның синонимы *тәмуг* лексемасының кулланылышында да күзәтелә: *Бу дәрәҗә мәмнүнийәте җәһәннәмдән азадлық йазуы китерелдегендә,* ... [Фәхреддин, 1899, б. 43]; ... *әүwәлгесе кеби бу йул һәм туп-тугры җәһәннәмә алыб вармақда иде* [Фәхреддин, 1903, б. 65]; *Гүйә җәһәннәмдән азад улмыш кемсә мисалында нә сөйләмәйә белмәз* ... [шунда ук, б. 75]; ... *сезнең ичүн тәмугга керер хәлем йуқ!* [шунда ук, б. 85].

Алдагы авторлардан аермалы буларак, Р. Фәхреддин әсәрләрендә *дөнйа* һәм аның нигезендә барлыкка килгән *дөнйалық* сүзләре түбәндәге мәгънәләрдә кулланылалар:

1) 'кешенең үлгәнчегә кадәр гомер иткән урыны' мәгънәсендә: *Имде дөнйада олуг эшем қалмады. Үлгәнемне ишетсәң, дога қылырсын* [Фәхреддин, 1899, б. 5]; *Бәлки дөнйалықда сезнең илә күрешмәк мөйәссәр улмаз,* ... [шунда ук, б. 13]; *Wә дөнйа һәм ахирәтдә улан өмидләре дә Әсмада иде* [Фәхреддин, 1903, б. 14]; ... *безләр шулай булыб йөреб, хайwан булыб дөнйадан кидәчәкмез икән,* ... [шунда ук, б. 81];

2) 'җир йөзе, анда булган терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы' мәгънәсендә: *Гәһ халық арасында йөрер wә гәһ киң дөнйаны қараб варыр идем* [Фәхреддин, 1899, б. 22]; *Қадерене белеб, дөнйа гизеб, Аллаһы Тәгаләнең бәндәләрене дә күрергә тийешле* [шунда ук, б. 38]; *Дөнйада бөйлә хатынлар һәм вардыр* [Фәхреддин, 1903, б. 10]; *Дөнйада нәләр улмаз, нәләр!!...* [шунда ук, б. 117];

3) ‘кешеләр тормышы, яшәеше, гомумән көнкүреш’ мәгънәсендә: *Дөнйа бөйләдер, шадлыгында да дәwамы йуқ, хәсрәтендә дә!...* [шунда ук, б. 44]; ... *ошбуның ичүн бу хатын да дөнйа көтмәйә башқа бер йул табды* [шунда ук, б. 65].

Шуның белән бергә чыганакларда әлеге сүзнең образлы мәгънә төсмерләре белән баетылып кулланылу очраклары да теркәлде: *Зира дөнйа сәфәрендә һәр даим бөйлә тормақ мөмкин улмадыгындан мөнасиб һәм дәгелдер* [Фәхреддин, 1899, б. 108]; ... *гомерене ахмақлар гадәте үзрә сәфаһәт дөнйаларында кичермәк* ... [Фәхреддин, 1903, б. 5].

‘Кешенең үлгәнчегә кадәр гомер иткән урыны’ мәгънәсендәге *дөнйа* сүзенә әсәрләрдә ‘үлгәннән соңгы тормыш, «теге дөнья»’ төшенчәсен белдереп килгән гарәп асыллы *ахирәт* сүзе каршы куела: *Ахирәт ичүн йалңыз дин гыйлеме, дөнйа тормышы ичүн дин илә дөнйа гыйлемене һәм белмәк ләземдер* [Фәхреддин, 1899, б. 5]; *Сиңа дөнйа wә ахирәтдә сәгадәт насыйб итсен!* [шунда ук, б. 6]; *Ахирәтдә исә дәха бийүк җөзәләр күрсә иде!...* [Фәхреддин, 1903, б. 111]; ... *имде буның ичүн ахирәтдә әмсалсыз шадлықлар күрсен!...* [шунда ук, б. 116].

*Гөнаһ* сүзе ‘дин кануннарын бозу, шәригать таләпләрен үтәмәүдән гыйбарәт Алла каршындагы гаеп, язык’ мәгънәсендә авторның «Әсма яки гамәл вә җәза» романында кулланыла: ... *бидгат wә гөнаһ идегене иглан итдекләрендән башқа,* ... [шунда ук, б. 76]; *Бу тугрыда нә шәригәт wә нә низам нәзарында гөнаһым йуқдыр зан идәрем* [шунда ук, б. 37].

«Сәлимә яки гыйффәт» романында ул ‘традиция, тәртип, әдәп-әхлак кагыйдәләрен һ.б.ш. бозу; гаеп эш’ мәгънәсендә теркәлде: ...*үпкә идеб бер читкә чықмақ һәм гайеб гөнаһдыр* [Фәхреддин, 1899, б. 6].

Аның нигезендә барлыкка килгән *гөнаһсыз* һәм *гөнаһлы* берәмлекләрен язучы иҗтимагый контекстта образлы һәм эмоциональ контекстлар белән баетып файдалана: ... *буның илә бәрабәр нә қадәр гөнаһсыз wә мазлум қанларны түгеб, йылга рәwешендә агыздылар;* ... [шунда ук, б. 52]; *Йа Алла! Бән бер гөнаһлы бәндәйем,* ... [Фәхреддин, 1903, б. 72].

*Хәләл* сүзе Р. Фәхреддин әсәрләрендә нигездә ‘шәригать тарафыннан тыелмаган’ мәгънәсен белдереп килә, аерым очракларда иҗтимагый коннотацияләргә ия була: ... *сәфахәтне хәләл идеб дөнйага бер шәригәт килмәмешдер* [Фәхреддин, 1899, б. 74]; ... *Хөсәйен хәзрәт исә хәләл идегене бәйан әйләр иде* [Фәхреддин, 1903, б. 79]; *Хәләл рызықлардан ләззәт табмай үләксә ардындан йөрмәкдә улан қозгынлара буны фида әйләмә!...* [шунда ук, б. 121].

Шуның белән бергә «Сәлимә яки гыйффәт» романында аның сөйләм телендә чагылыш таба торган ‘никахлы’ мәгънәсендә дә кулланылу очрагы да теркәлде: ... *дөнйаның қайгы wә шадлықлары хәләл ире илә уртақлашмақ;* ... [Фәхреддин, 1899, б. 74].

Аның антонимы булган *хәрәм* сүзен автор тарафыннан «Әсма яки гамәл вә җәза» романында ‘дин, шәригать тарафыннан тыелган’

мәгънәсендә аерым лексема буларак һәм сүзтезмәләр составында, аерым очракларда иҗтимагый һәм эмоциональ коннотацияләр белән баетып файдалана: *Грифель илә ҡара таҡтаға йазмаҡ шәриғәткә хилаф, соңра аны бозыб алмаҡ да хәрәм!...* [Фәхреддин, 1903, б. 30]; *Хәсән хәзрәт русча уҡымаҡ, рәсем чыҡартмаҡ, ысулы җәдидә ачмаҡ хәрәм идегене сөйләдеге хәлдә, ...* [шунда ук, б. 78]; *Риwайәтләрә күрә, арамызда бу кеби хәрәм кәсеб идүче бер чуҡ Хәмидәләр улыныб, ...* [шунда ук, б. 117]; *... ханәңездә гел хәрәм эшләрдән азад улдыҡыныз хәлдә...* [шунда ук, б. 120].

Югарыдан күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дини лексикага мөнәсәбәттә иске татар язма әдәби теленең традицияләре дәвам иттерелә. Шул ук вакытта текстларда әлеге төркемгә караган лексик берәмлекләрнең кулланылышында аерым үзенчәлекләр дә күзәтелә һәм алар нигездә синтагматик планда, аерым алганда аларның яңа коннотацияләр белән баетылып, яңа контекстларда (мәсәлән, иҗтимагый) килүләрендә чагылыш таба. Бу үз чиратында әлеге чорда формалашкан татар мәгърифәтчелек интеллигенциясе социаль төркемен характерлаучы бер үзенчәлек булып тора.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә: роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир: роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Мирхәев Р.Ф.* Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә матур әдәбият һәм публицистик катламнар нисбәте // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 28–32.

*Мирхәев Р.Ф.* Татар лингвокультурасында «Алла» концепты // Фәнни Татарстан. 2017. № 3. Б. 22–27.

*Супрун А.Е.* Лексическая структура текста и лексическая синтагматика // V nemzetközi szlavisztikai napok 1994 / Международные дни славистики. 1. kötet. Szombathely, 1995. С. 55–62 [Электрон ресурс].

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. өч томда. III том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й. Казан: ТӘҺСИ, 2016. 748 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казан: ТӘҺСИ, 2017. 744 б.

*Фәхретдинов Р.* Сәлимә, яки Гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер. Казан: типогр. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

*Фәхретдинов Р.* Әсма, яки Гамәл вә җәза. Оренбург: типогр. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81′373

***Р.Х. Мөхиярова,***
***Р.А. Закиров***

# XXI ЙӨЗ БАШЫ ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье, путём анализа языка средств массовой информации, выявлено шесть основных тенденций в развитии татарского литературного языка начала XXI века:1) расширение значения ряда исконных слов; 2) образование новых слов для обозначения новых явлений или замены русско-европейских заимствований; 3) активизация ряда перешедших в XX веке в пассивную лексику тюрко-татарских слов; 4) попытки возвращения в активный словарь многих старых арабско-персидских заимствований; 5) существенное увеличение западноевропейских слов преимущественно английского происхождения, связанных, в первую очередь, компьютерной техникой и новыми общественно-экономическими реалиями; 6) создание многочисленных словообразовательных калек.

**Ключевые слова**: активная и пассивная лексика, заимствования, кальки, литературный язык, неологизм.

The article, by analyzing the language of the media, identifies six main trends in the development of the Tatar literary language of the beginning of the XXI$^{st}$ century: 1) expanding the meaning of a number of native words; 2) formation of new words for denoting new phenomena or replacing Russian-European borrowings; 3) activation of a number of Turkic-Tatar words that passed into passive vocabulary in the XX$^{th}$ century; 4) attempts to return to the active vocabulary of many old Arabic-Persian borrowings; 5) a significant increase in Western European words of predominantly English origin, primarily related to computer technology and new socio-economic realities; 6) creating numerous word-forming loan translations.

**Key words:** active and passive vocabulary, borrowings, tracings, a literary language, a neologism.

Сәяси, икътисади, мәдәни үзгәрешләр, интернет челтәренең киңәюе әдәби тел лексикасына да тәэсир итә. Телдәге үзгәрешләр иң беренче чиратта публицистик стильдә чагылыш таба. Соңгы еллар вакытлы матбугатын өйрәнү язма әдәби тел лексикасы үсешендә түбәндәге тенденцияләрне ачыкларга мөмкинлек бирде.

I. Сүзләрнең мәгънәләре үзгәрү, яңа мәгънә төсмерләре белән баюы. Үзгәртеп кору елларында **эшкуар** сүзе бик популярга әйләнде. Татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлегендә бу сүзгә шундый билгеләмә бирелгән: «Эшкуар – *и.* Эшләрне (бигрәк тә коммерция эшләрен) бернинди ысулдан да чирканмыйча, оста итеп алып баручы» [ТТАС, 1981, б. 594]. 1981 елгы бу билгеләмәдә пейоротив төсмер сизелә, ул чорда бу сүз белән капиталистик җәмгыять бизнесменнарын гына атаганнар. Хәзер исә ул стилистик яктан нейтраль һәм күпкә киңрәк мәгънәдә кулланыла. 2005 елда басылып чыккан Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә **эшкуар** сүзенең билгеләмәсе

хәзерге чор мәгънәсенә тәңгәл килерлек итеп бирелгән: «Эшкуар – *ис.* Эшләрне оста һәм табышлы итеп алып баручы» [ТТАС, 2005, б. 716]: *Әмма бу хакта бер генә **эшкуар** да белгертергә теләми* (М.ж.). *Әхлаксыз чиновниклар...бер-ике елда череп баеп китәргә омтылган **эшкуарларны** савып, үзләрен алардан да начаррак итеп күрсәтә киләләр* (В.Т.).

**Эшмәкәр** сүзе дә, мәгънәсен киңәйтеп, иң актив сүзләрнең берсенә әйләнде. 1981 елгы сүзлектә ул «диалекталь сүз» билгесе белән «эшчән, уңган, эшлекле» мәгънәсендә бирелгән [ТТАС, 1982, б. 536]. Хәзер ул, нигездә, «предприниматель» мәгънәсендә «эшкуар» сүзенең синонимы буларак кулланыла: *...совет киңәшмәсенә 20 дән артык шундый **эшмәкәр** чакырылган иде* (Ш.Ч.). ***Эшмәкәрләрне** министрлык кайгыртачак* (В.Т.). *Танылган **эшмәкәр** 1999–2003 елларда Татарстан Дәүләт Советы депутаты булды* (В.Т.).

XX гасырның 90 нчы елларында **эшкуар** сүзе күбрәк кулланылса, хәзерге чорда, киресенчә, **эшмәкәр** атамасына өстенлек бирелә. 2005 елгы сүзлектә «диалекталь сүз» тамгасы һаман сакланган, шулай да бер мәгънә өстәлгән: «Эшмәкәр – *ис. диал.* 2) Нинди дә булса берәр сәнәгать-сәүдә эшенең иясе һәм шуннан табыш алучы» [ТТАС, 2005, б. 716].

Шулай ук **килешү, берлек** сүзләренең дә мәгънәләре киңәйде: *2002 елда ул балалар әдәбияты өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Язучылар **берлегенең** А. Алиш исемендәге бүләгенә лаек булды* (К.у.). ***Берлекнең** аерым бинасы да юк...* (В.Т.). ***Килешү** Кемерово өлкәсендә яңа сервис үзәге төзүне күзаллый* (Ш.Ч.). *Инде Италия компаниясе белән **килешү** төзелә* (Ш.Ч.).

Сүзләрнең мәгънәләре киңәю еш кына аларның, бер стиль чикләреннән чыгып, стильара, әдәби тел сүзенә әйләнүенә китерә. Әйтик, аңлатмалы сүзлектә «сөйләү теле стиле белән чикләнгән» дип билгеләнгән **алыпсатар** (спекулянт), **арадашчы** (маклер) сүзләре соңгы елларда, мәгънәләрен киңәйтеп, әдәби телдә урын алдылар: *...урлап алып килгәннән дә баш тартмый андый **алыпсатарлар*** (В.Т.). *15 гыйнвар көнне икенче курста укучы егеттән **арадашчы** ролен башкаручы студент аркылы 3000 тәңкәне ала да, килеп тә каба бу* (М.ж.).

Бик күп сүзләрнең яңа мәгънә төсмере белән баеп, киңрәк мәгънәлегә әйләнүе телебезнең зур эчке мөмкинлекләрен күрсәтә. Чөнки, күренекле тел галиме Р.А. Будагов раславынча, яңа сүзләр барлыкка килү лексиканың сан ягыннан үсешен күрсәтсә, сүзләрнең мәгънә киңәю исәбенә сыйфат ягыннан үсеше аның камилләшүе турында сөйли [Будагов, с. 35–71].

II. Тормыштагы яңа күренешләрне атау яисә рус (Көнбатыш) алынмаларын алыштыру өчен, телебезнең үз чаралары белән һәм үз материаллары нигезендә яңа сүзләр ясау да активлашты. Алар арасында төрле модельләр буенча ясалганнары бар.

1. Кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр: **ашчы, кертем, тотак, эшмәкәрлек, хокукчы** (юрист), **эшмәкәрлек.**

2. Парлы сүзләр. Структур яктан алар үзләре берничә төргә бүленә:

а) татар сүзе - татар сүзе: **рөхсәт-юллама, уен-бәйге, төбәк-почмак, төзү-бизәү;**

б) татар сүзе - рус яисә Көнбатыш Европа сүзе: **чыгыш-лекция, эшкуар-меценат, эшмәкәр-бизнесмен, оешма-учреждение;**

в) рус яисә Көнбатыш Европа сүзе - татар сүзе: **талант-сәләт, план-ният, рецензия-бәяләмә, музей-тыюлык, колония-сөрген, шофер-узышчы;**

г) гарәп-фарсы сүзе - татар сүзе: **мөнәсәбәт-караш, тамаша-бәйге.**

Синонимик компонентлары төрле чыганаклы парлы сүзләрнең матбугатта күп кулланылуы игътибарга лаек. Ул гадәттә авторларның әйтәсе сүзен укучыга ныклабрак төшендерергә тырышуы белән аңлатыла һәм вакытлы күренеш булып тора.

**Эшмәкәр, бәяләмә** төшенчәләре гомумкулланышка ныклап кереп урнашкач, ул сүзләрне «меценат» яисә «бизнесмен», «рецензия» сүзләре белән парлап бирүнең кирәге калмаячак.

3. Кушма сүзләр. Компонентларның кайсы сүз төркеменнән булуларына карап, алар түбәндәге төркемнәргә бүленә:

а) исем + исем: **илбаш, янкорма, кулчатыр;**

б) алмашлык + фигыль: **үзбилгеләнү, үзтотыш;**

в) алмашлык + исем: **үзөйрәткеч, үзаң;**

г) исем + фигыль: **җанатар, җанкыяр, җирсөяр.**

III. Иске төрки-татар сүзләренең телгә кире кайтуы.

Милли гореф-гадәтләрнең яңаруы нәтиҗәсендә күп кенә иске төрки-татар сүзләре яңадан әдәби телгә кайтып активлашты: **ошбу, олуг, тугра, җыен, кала** һ.б. Мәсәлән: *Дәүләт җитәкчесенең фикер алышу барышында җиткерелгән тәкъдимнәрне Федераль **Җыенга** юлламасын әзерләүдә исәпкә алырга ниятләвеннән чыгып, тагын ике әһәмиятле мәсьәлә буенча үз фикеремне әйтергә кирәк, дип исәплим* (М.җ.). *«Теоретик механика» кафедрасында эшләүче **ошбу** өметле укытучы зачет куйган өчен нибарысы 2,5 мең сум акча алып тотыла* (М.җ.).

Шулай ук соңгы елларда күп кенә рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынмаларны революциядән соң пассивлашкан татар яисә гарәп-фарсы сүзләре белән алыштыру тенденциясе дә көчәйде: **корылтай** (съезд, конгресс), **шура** (совет), **кизү** (дежур), **алгарыш** (прогресс), **тотак** (заложник), **чәчтараш** (парикмахер). Мәсәлән: **Корылтайны** *ТР Диния нәзарәте оештыра* (В.Т.). *...берничә чит ил кешесен* **тотык** *итеп алганнар* (В.Т.). *«Минем һөнәрләрем күп, – ди Рузалия:**чәчтараш**, сатучы, тегүче»* (В.Т.).

IV. Гарәп-фарсы алынмалары белән мавыгуның көчәюе. Гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышын үзен ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин: 1) элек телебездә кулланылган, соңыннан пассивлашкан, шулай да халыкка аңлаешлы сүзләрне активлаштыру: **мантыйк, ширкәт, гыйбадәтханә, милләтпәрвәр, ватанпәрвәр,**

**хасият, икътисад, тәрәккый, вәкаләт, табиб, дикъкать, фал, җөрьәт, илаһият, кавем, нәүмиз, шәкел, хастаханә, фәрман** һ.б.;

2) телдән бөтенләй төшеп калган, архаизмга әйләнгән сүзләрне кире кайтарырга омтылу: **сәнәд, вилаять, мәсләки, тәҗвид, хәер хаһ, мәрасим, мөнбәр, вазгыять, шигарь, зынҗыр, җәсад, тәкълид, әскәнҗә** һ.б.

Гарәп-фарсы сүзләрен матбугатта төрлечә язу очраклары да бар. Әйтик, «табиб» сүзен «табип» рәвешендә дә язалар. *Светлана Мирвагыйз кызы Хәсәнова югары белемле* **табип** (Ш.Ч.). **Табиблар** *шаккаткан...* (М.җ.).

Яңа орфографик сүзлекләрдә **вазгыять** дип теркәлгән булса да, **вәзгыять** рәвешендә куллану күбрәк очрый: *Безнең һәркайсыбыз әлеге* ***вәзгыятькә*** *ничек йогынты ясый ала?* (Ш.Ч.). *Ә бу үз чиратында илдәге эчке* ***вәзгыятьнең*** *катлаулануына... китерәчәк* (М.җ.).

Больница урынына хәзер **дәваханә, шифаханә, хастаханә (хәстәханә), сырхауханә** кебек сүзләр ешрак кулланыла. Бу сүзләрнең **шифаханә** һәм **хастаханә** дигәннәре татар теленең аңлатмалы һәм орфографик сүзлекләрендә теркәлгән.

**Сырхауханә** сүзенә килгәндә исә, аның беренче өлеше – татар сүзе. Ул халык телендә киң таралган. Димәк, әйтү өчен уңайсыз (олы яшьтәге кешеләр «булнис», «бәлнис» дип сөйләшергә мәҗбүр) **больница** сүзен «сырхауханә»гә алыштыруны халык тизрәк кабул итә ала. Г. Тукай, Ш. Камал кебек классиклар кулланган «шифаханә» исә, «поликлиника» сүзен «татарчалаштыру» өчен кулайрак, мәгънәсе буенча ул шулай ук «профилакторий», «санаторий» төшенчәләренә дә якын: *...Зифа ханым бүгенге көндә «Зеленая роща»* **шифаханәсенең** *теш дәвалау бүлеге мөдире булып эшли* (Ө.).

Фарсы телендә «өй, йорт» дигәнне аңлатучы «ханә» сүзе хәзерге татар телендә яңа сүзләр ясауда актив кулланыла. Соңгы елларда аның ярдәмендә **гыйбадәтханә, гыйлемханә, даруханә, кофеханә, остаханә, сыраханә, ятимханә** кебек сүзләр ясалып, матбугат битләрендә кулланылышка кереп бара.

Фарсы телендә «хат, язылган нәрсә, китап» дигән мәгънәләрдәге «намә» компоненты белән ясалган кушма сүзләр дә язма әдәби телдә еш очрый башлады. Мәсәлән: **васыятьнамә, шартнамә, ышанычнамә** (доверенность), **хисапнамә, кисәтүнамә** (повестка), **боерыкнамә** (предписание), **юлнамә** (путевка), **таныкнамә, никахнамә, туунамә, йолдызнамә, тәкъбирнамә** (төш юрау китабы), **шаһәдәтнамә** (нәрсәне дә булса раслап бирелгән язу, таныклык) һ.б.

Матбугатта составларына **пәрвәр** тамыры кергән гарәп-фарсы асыллы **тәрәккыйпәрвәр, милләтпәрвәр, ватанпәрвәр** дигән кушма сүзләр дә кулланыла, хәтта **милли-мәдәнипәрвәр** кебек окказиональ формалар да очрый: *Чөнки ул мәдәни чараларга йөри һәм үзен* **милли-мәдәнипәрвәр** *итеп күрә* (М.җ.).

V. Соңгы елларда рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән, беренче чиратта инглиз теленнән кергән **айпат, айфон, аккаунт, бло-**

**гер, брифинг, ватсап, волонтер, грант, импичмент, инвестор, индексация, инновация, инстаграм, интернет, ипотека, компьютер, коронавирус, магистр, мониторинг, муниципаль, ноутбук, портал, портфолио, продюсер, риэлтор, сайт, смартфон, спикер, спонсор, файл, хакер** сүзләре бик активлашты. Бу сүзләрнең күбесе базар мөнәсәбәтләрен чагылдыра, сәясәткә, мәдәнияткә караган сүзләр дә байтак. XX гасыр ахырында алар неологизм буларак кабул ителсәләр, хәзер иң актив сүзләр исәбенә күчтеләр: *Узган ел **Инстаграмдагы аккаунтымны** урладылар* (Ш.Ч.). ***Блогерларны** хәзерге заманның язучылары дип тә йөртәләр* (Ш.Ч.). *Төрек теле өчен андый программа булуын ишеттек, әмма ачык **интернет** киңлекләрендә ул юк* (М.җ.). *Болар барысы да **ипотека** хакын арзанайтырга тиеш* (В.Т.). *Чир килеп чыгуга яңа төр **коронавирус** (2019-nCoV) сәбәпче* (В.Т.). *...киләчәктә дөньяви юнәлешләр буенча **магистрлар** әзерләү күздә тотыла* (М.җ.). *... транспорт бүлеге хезмәткәрләре һәр көнне иртәнге 5 тә **мониторинг** үткәрәләр* (Ш.Ч.). *Казан мэриясе **сайтында** хәбәр ителгәнчә, поезд барлыгы 4044 чакрым юл үтәргә тиеш* (В.Т.). ***Смартфонда** да, **компьютерда** да **парольләрем** бар...*( Ш.Ч.). ***Хакерлар** һөҗүме мине дә читләтеп үтмәде* (Ш. Ч.).

Көнбатыш Европа телләреннән административ бүленешне һәм аның җитәкчеләрен атый торган сүзләр дә килеп керде (мәсәлән: **префект, префектура, мэр, муниципалитет, департамент** һ.б.): *Башкалада узган илкүләм форумда шәһәр **мэры** Илсур Метшин әнә шундый бурыч куелганын әйтте* (В. Т.).

**Офис** сүзе дә ныклап кулланышка керде: *Мин шул сорауга җавап эзләп, 7 нче комплекста урнашкан* **офиска** *юнәлдем* (Ш.Ч.).

Банк системасының киңәюенә бәйле рәвештә яңа гасырда **депозит, дивиденд, инвестор, инвестиция, эмитент** кебек сүзләрнең кулланылышы активлашты: *Чит ил **инвестицияләрен** кертү сәбәпле, КамАЗда штатлар кыскарту куркынычы бар* (Ш.Ч.).

**Квота, логистика, респондент** кебек сүзләр дә еш очрый: *Илчелек РФ Мәгариф министрлыгы белән берлектә безгә хәзергә 25 урынга **квота** бирә* (В.Т.). *«Бу, беренче чиратта, аэропортны киңәйтеп, халыкара статуска ирештерү, икенчедән, телефон элемтәсен көчәйтү, өченчедән,* **логистика** (*халыкара складлар, базалар системасы) үзәге булдыру дигән сүз»* (В.Т.). **«Респондентлар** *ни өчен «Сөембикә»гә язылганнар соң»* (С.).

Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр, күбесенчә, русча әйтелгәнчә кабул ителә, аларга татар кушымчалары да өстәлә: **аккредитацияләү, аттестацияләү, глобальләшү, инвестицияләү, индексацияләү, интеграцияләшү, компьютерлаштыру, логистикалау, оптимизацияләштерү, тестлаштыру, утильләштерү, унитарлаштыру.** Мәсәлән: *Араларында **глобальләшү** процессын сәбәп итүчеләр дә бар* (М.җ). *Халыкара ислам бизнесы һәм финанслары саммитының бер зур нәтиҗәсе – Казанда хәләл ризыкны **логистикалау** үзәге төзелү* (В.Т.).

VI. Яңа алынмалар белән беррәттән татар теленең сүзлек составы калькалаштыру юлы белән ясалган сүзләр исәбенә дә байый: **иминлек мендәре** (подушка безопасности), **интернет челтәре** (сеть интернета), **куллану базары** (потребительский рынок), **искәртү ремонты** (профилактический ремонт), **күләгәле икътисад** (теневая экономика), **мөрәҗәгать** (послание), **пилот режимы** ( пилотный режим ) **социаль челтәр** (социальная сеть), **үзидарә** (самоуправление), **хәрби мәҗбүриятле** (военнообязанный). Мәсәлән: *Бүген **интернет челтәрендә** татар телендә 200 сайт бар* (М.җ.). ***Мөрәҗәгатьнең*** *беренче өлеше икътисадтагы казанышларга багышланса, икенче өлешендә ул илнең тышкы сәясәтенә тукталган* (М.җ.). ***Социаль челтәрләрдә*** *автобусларның юкка чыгуына нәфрәт белдерүчеләр дә күп...* (Ш.Ч.).

Тулаем алганда, XXI гасыр башы татар әдәби теленең язма стильләрендә гарәп-фарсы алынмалары йогынтысы ныграк сизелә. Татар телендә актив синонимнары булганда, искергән гарәп-фарсы алынмаларын куллану, безнеңчә, үзен акламый. Шундыйлардан **җөрьәт** (батырчылык итү, тәвәкәлләү), **мәгъкуль** (лаек, лаеклы, кулай), **хәбис** (пычрак, шакшы, начар, әшәке), **нәүмиз** (күңелсез, боек), **мәсләк** (караш, максат, юнәлеш, тоткан юл), **вазгыять** (торыш, халәт, хәл), **гыйбарә** (өзек, өземтә әйтем, сүзтезмә), **тәрәккыять** (алга китеш, үсеш, прогресс), **кәсафәт** (начарлык, зарар, зыян) кебекләрне күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән: *Фән һәм техника **тәрәккыяте** ашкынып алга чыкты* (М-т). ***Мәсләкне*** *ничек билгеләргә?* (В.Т.). *Укытуда милли-төбәк компонентын исәпкә алмау **кәсафәте** бүген көнүзәк мәсьәлә булып калкып чыкты* (М.җ.).

Д.Б. Рамазанова хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «аларның барысы да тел кулланучыларның киң катламына аңлаешлы түгел, аларның мәгънәләрен аңлар өчен, тәрҗемә сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә» [Татар лексикологиясе, б. 88].

Сөйләм телендә бу сүзләр кулланылмый диярлек. Дөрес, соңгы елларда гарәп-фарсы алынмалары белән мавыгу публицистик стильдә бераз кимеп бара.

Телгә инде ныклап кереп урнашкан интернациональ сүзләрдән баш тарту тенденциясе дә, безнеңчә, бик үк максатка ярашлы түгел. Чөнки алар урынына гадәттә барыбер башка телдән сүзләр кулланырга кирәк була. Әйтик, мәктәпләрдә озак еллар класс сүзе кулланылды, хәзер матбугат телендә ул сыйныфка, союз – берлеккә, член – әгъзага, секретарь – сәркатипкә, республика – җөмһүрияткә, экономик – икътисадыйга, промышленность – сәнәгатькә, редактор – мөхәрриргә әйләнеп бетеп бара. Ә сөйләм телендә барыбер беренче вариантлар гына кулланыла. Бу архаизмнар аерым стильләрдә, әйтик, поэзиядә матур яңгыраса да, барлык телләргә дә диярлек хас булган глобальләшү тенденциясе шартларында алар белән артык мавыгу бик үк урынлы түгел.

### *Әдәбият*

*Будагов Р.А.* Что такое развитие и совершенствование языка? М.: Наука, 1977. 264 с.

Татар лексикологиясе: өч томда. II том. Казан: ТӘһСИ, 2016. 392 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. III том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

### Шартлы кыскартылмалар

В.Т. – «Ватаным Татарстан» газетасы

М-т – «Мәгърифәт» газетасы

М.җ. – «Мәдәни җомга» газетасы

Ө. – «Өмет» газетасы

С. – «Сөембикә» журналы

ТТАС, 1981 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. III том. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. 832 б.

ТТАС, 2005 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Т.я. – «Татарстан яшьләре» газетасы

Ш.Ч. – «Шәһри Чаллы» газетасы

***Мөхиярова Рәзинә Хәйбрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты*

***Закиров Раиф Әмирьян улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты*

УДК 811.512′373

***Г.Р. Галиуллина***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ГАИЛӘЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Статья посвящена изучению особенностей функционирования родственной терминологии в современных татарских семьях. На основе социолингвистического исследования выявлены наиболее распространенные формы внутрисемейной родственной терминологии. Анализу подвергались также новые варианты изучаемой терминологии, которые стали активно функционировать на современном этапе. На основе изучения ответов трех исследуемых групп респондентов пришли к выводу, что на современном этапе родственная терминология претерпевает определенные изменения, что наиболее заметно в семьях, проживающих в поликультурной среде.

**Ключевые слова**: татарский язык, татарская семья, родственная терминология, социолингвистика, язык семейного общения.

The article is devoted to the study of functioning peculiarities of related terminology in modern Tatar families. On the basis of sociolinguistic research, the most common forms of intra-family related terminology are identified. New versions of the studied terminology were also analyzed, which have become active at the present stage. Based on the study of the responses of three groups of respondents, we came to the conclusion that at the present stage, related terminology is undergoing certain changes, which is most noticeable in families living in a multicultural environment.

**Keywords:** Tatar language, Tatar family, related terminology, sociolinguistics, language of family communication.

Гаилә – җәмгыятьнең кече иҗтимагый төркемнәр составына кертеп карала торган иң кечкенә берәмлеге. Галимнәр күрсәткәнчә, кече төркем әгъзаларын уртак көнкүреш, шәхси контактлар, уртак кызыксынулар һәм әхлак кагыйдәләре берләштерә [Словарь социолингвистических терминов, 2006, с. 200].

Гаилә эчендәге иҗтимагый, икътисади, мәдәни һәм әхлакый мөнәсәбәтләр гаиләнең үзенә генә түгел, бәлки җәмгыятьнең микроклиматына да зур йогынты ясый. Шунлыктан гаиләнең тотрыклылыгы, милли традиция, гореф-гадәтләрнең сакланышы һәм алдагы буыннарга тапшыру мөмкинлеге милләт яшәешенең төп күрсәткечләреннән санала. Шәхеснең формалашуы һәм иҗтимагый тормышка яраклашуы да, беренче чиратта, гаилә кысасында туганнары, якыннары янәшәсендә башлана. Гаиләдә алган тәрбия, кешелек һәм миллилек сыйфатлары кешенең алга таба үсеш юлын билгеләп, гомер юлында тулылана, байый бара.

Гаилә эчендә кантуганлыкка нигезләнгән ир һәм хатын, ата һәм ана, балалар, апа-абыйлар, эне-сеңелләр арасында төрле мөнәсәбәт-

ләр урнаша. Аларның бер өлеше традицияләргә нигезләнсә, беришe исә тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә барлыкка килгән була [Современный русский язык, 2003, с. 382].

Татар гаиләсе өчен гасырлар дәвамында миллилеккә, дини кануннарга нигезләнгән традицияләр дәвамлылыгы аеруча зарур, чөнки милли традиция халыкның рухи кыйммәтләреннән иң әһәмиятлесе санала һәм ул бүгенге көнебезне үткән тарихыбыз белән бәйли торган өзелмәс чылбыр да булып тора. Татар халкында гаиләнең иң якын туганнардан (ата-ана һәм балалар) торганы да, аларның 3–4 буынын (әби-баба, ата-ана, ул-кыз, оныкларны) берләшергәне дә булган [Татар энциклопедия сүзлеге, 2002, б. 156]. Бүгенге көндә татар гаиләләре, башлыча, ике буынны – әти-әни һәм балаларны берләштерә.

Татар гаиләсенең гасырдан-гасырга артык үзгәреш кичермичә тапшырыла торган традицияләре бар. Шулар арасында аерым игътибар гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәткә, бер-берсенә эндәшү, туганлык терминнарына бирелә. Алар бик борынгы заманнарда формалашып, үсеш юлында төрле үзгәрешләргә дучар булганнар, лексик составлары, кулланылыш киңлеге ягыннан байый, тулылана барганнар. XX гасыр дәвамында шәһәрләштерү, индустрияләштерү, акыл хезмәтенең алгы планга чыгуы нәтиҗәсендә гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрдә, туганлык атамаларының кулланылышында демократик чалымнар арта бара. Яңа гасырда исә тиз темплар белән үтеп кергән глобальләшү күренеше, мәдәниятләрнең үзара керешүе, тормышның аерылгысыз өлешенә әйләнгән икетеллелек күренеше гаилә яшәешенә, гаилә әгъзаларының үзара мөнәсәбәтләренә, аралашу үзенчәлекләренә дә зур йогынты ясый. Әлеге йогынты шактый консерватив саналган туганлык атамаларының составында, аларның функциональ мөмкинлекләрендә дә чагылыш таба. Татар теленең әлеге лексик фондында да төрле үзгәрешләр, күчешләр барлыкка килә.

Мәкаләдә хәзерге заман шартларында татар гаиләләрендә кулланыла торган туганлык терминнарының кулланылыш үзенчәлекләренә, киң таралыш тапкан төрләренә статистик алым ярдәмендә күзәтү ясарбыз. Фактик материал 2012–2019 еллар аралыгында тупланган татар гаиләләре сөйләме язмаларын һәм татар балалары арасында үткәргән анкета нәтиҗәләрен үз эченә ала.

Билгеләп үткәнчә, татар гаиләләрендә туганлык атамаларының озак дәверләр аралыгында формалашкан һәм калыпка утырган синонимик рәте бар. Д.Б. Рамазанованың «Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре» (2014) хезмәтендә татарлар арасында кулланылышта йөргән туганлык атамаларының составы һәм семантикасы шактый җентекле анализлана. Ул билгеләгәнчә, «туганлык атамалары бербөтен система булып формалашкан ябык сүзләр рәтен хасил итә, парадигматик оешулары ягыннан да системалылык саклыйлар, төп дифференциаль билгеләре буенча бер-берләренә карата симметрияле рәвештә капма-каршы торалар (ана-ата, апа-сеңел, әби-онык һ.б.) яисә янәшәлек хасил итәләр» [Рамазанова, 2014, б. 5].

Д.Б. Рамазанова белән тулысынча килешеп, гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп килгән туганлык атамаларының төп асылы үзгәрмәсә дә, заман, яшәеш даирәсе тәэсирендә барлыкка килеп, кулланылышка күптән түгел генә кереп киткән яңа вариантлар да барлыкка килү тенденциясе күзәтелүен ассызыклау кирәк. Шулай ук көнкүреш сөйләм ситуациясенә бәйле туганлык атамалары төрле үзгәреш, яңарыш дә кичерергә мөмкин.

Туганлык атамаларын кантуганлык һәм никахлашу туганлыгы нигезендә барлыкка килгән атамалар тәшкил итә [Рамазанова, 2014, б. 6]. Бу терминнарны төркемләү җәмгыятьнең иҗтимагый оешуы, этник төркемнең үзенчәлекләре нигезендә башкарыла. Әлеге мәкалә кысасында без якын туганнарга, ягъни әти һәм әни, әби һәм бабайга гаилә эчендә балаларның эндәшү вариантларын карарбыз. Төп анализ объекты буларак *Сез әтиегезгә, әниегезгә, әби һәм бабагызга ничек дәшәсез?* соравына балаларның җаваплары алынды.

Туганлык атамаларының хәзерге заманда кулланылыш үзенчәлекләрен төгәл билгеләү максатыннан, сорашу традицион милли мохитне билгеле бер дәрәҗәдә саклаган Тәтеш районында (барлыгы 168 респондент) һәм күпмәдәниятле Казан шәһәрендә үткәрелде. Казан шәһәре буенча 2016 елда үткәрелгән сорашуда ике төркем респондент аерылды. Беренче төркемдә югары сыйныфларда укучы 327 респондент катнашып, шуларның 81,7%ы – татар гаиләләрендә, 13,8% ы катнаш гаиләләрдә тәрбияләнгән, 4,6% респондент гаилә составы турында сорауга җавап бирергә теләмәде. Беренче төркемгә кергән укучылар татар мохитендә тәрбияләнгән һәм мәктәптә, нигездә, татар телендә белем алган. Икенче төркем респондентлар (барлыгы 300 бала) – рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучылар. Шуларның 89,3% ы – татар гаиләләреннән, 9,3% ы – катнаш гаиләләрдән; 1,3% ы – әлеге сорауга җавап бирмәүчеләр, мәкаләдә әлеге респондентларның җаваплары каралмады.

Туганлык атамалары арасында төп урынны *әти* термины алып тора. Татар гаиләләрендә гаилә башлыгын атау өчен әдәби вариант буларак традицион рәвештә *әти* сүзе кулланыла. Моннан кала, диалекталь вариантлардан *әткәй, әтәй* таралыш тапкан, гәрчә, бүгенге көндә әлеге вариантлар кулланылыш ягыннан бераз пассивлашып баралар. Авыл җирлегендәге татар гаиләләрендә, милли традицияләр билгеле бер дәрәҗәдә тотрыклы булганлыктан, традицион туганлык атамалары кулланылыш активлыкларын югалтмыйлар, мисал өчен, без анализлаган район гаиләләрендә *әти* терминын 78,1% бала куллана. Казан шәһәрендә үткәргән сорашулар күрсәткәнчә, әлеге туганлык атамасының кулланылышында беркадәр пассивлык сизелә, мисал өчен, беренче төркемдә *әти* атамасын респондентларның 56,6% ы, 2 нче төркемдә исә бары тик 26,6% ы гына актив куллана. Әмма шәһәр җирлегендә яшәүче балалар сөйләмендә чагыштырмача яңалардан саналган *әтием* формасының активлашуы сизелә, мәсәлән, Тәтеш районы балалары сөйләмендә әлеге атаманы кулланучы

респондентлар саны 13,4% тәшкил итсә, Казан шәһәренең беренче төркемендә – 41%, икенче төркемендә исә 58,3% тәшкил итә. Сирәк очракларда респондентлар рус теленнән кергән *-к* суффиксы ярдәмендә ясалган *әтикә /атика* вариантларын күрсәтәләр, мәсәлән, беренче төркемдә – 2,4%, ә икенче төркемдә 11,2% бала әлеге атаманы билгеле. Диалекталь вариантлар *әткәй, әтәй* атамаларының кулланылышы бик сирәк очрый, мәсәлән, Тәтеш районыны респондентларының 8,5%ы сөйләмендә бу төр атама кулланыла. Диалекталь вариантларның байтагы элек-электән киң таралыш тапкан сөйләшләрдә дә бүгенге көндә аның пассив икәнлеге күзгә ташлана, мисал өчен, гаилә сөйләм теле тупланган безнең язмаларда һәм сорашу үткәрелгән төркемнәрдә әлеге атамаларның кулланылмавы күренә.

*Әти, әтием* атамалары гомумтөрки *ата* >**ata* сүзенә барып тоташа. Әлеге сүз балалар тәтелдәвеннән барлыкка килгән дигән караш бар [Мусаев, 2006, с. 537]. Күпчелек төрки телләрдә аның төгәл терминологик мәгънәсе – «тудыручы зат». Бу лексик берәмлек күрсәтелгән мәгънәдә хәзерге татар телендә дә киң кулланылыш тапкан. Моннан кала, *ата* сүзе киңрәк мәгънәләргә дә ия, аерым алганда, «ата кеше, өлкән буын вәкилләре, нәсел башлыгы һ.б.».

*Әтием* сүзе *әти* лексик берәмлегенә I зат тартым кушымчасы *-ем* ялганып ясалган, килеп чыгышы хәзерге татар теленә карый, актив рәвештә туганлык атамалары составында кулланылышы XX гасыр урталарыннан башлана. Әлеге мөрәҗәгать сүзенең элегрәк стилистик дифференциация өчен хезмәт итү функциясе һәм ярату, якын итү кебек коннотатив төсмерләре алгы планга чыкса, бүген исә номинатив функциясе өстенлек алып тора.

Әйтергә кирәк, туганлык атамалары өлкәсендә булган үзгәрешләр, яңалыклар, беренче чиратта, төрле мәдәниятләр кисешелендә көн итүче гаиләләрдә ачык күренә. Фикеребезне раслау өчен гаилә башлыгын атау өчен кулланыла торган терминнарның икенче төркем респондентлар сөйләмендә ни рәвешле чагылышын түбәндәге диаграммада күрсәтербез.

Диаграмма 1



Хәзерге гаиләләрдә, башлыча, әни кешегә эндәшү өчен *әни, әнкәй* (диалекталь форма), *әнием* (соңрак барлыкка килгән форма) атамалары кулланыла. Авыл җирлегендә *әни* сүзе – 65,7%, *әнием* атамасы исә 18,3%, диалекталь вариант саналган *әнкәй* сүзе 16% бала сөйләмендә даими кулланыла. Шәһәр җирлегендә исә күрсәткечләр беркадәр аерыла: беренче төркемдә картина түбәндәгечә: *әни* – 47,1%; *әнием* – 45,2%, *әнкәй* – 4,2%, *мама* – 1,5%; икенче төркемдә *әни* атамасын 28,8% сорашуда катнашучы, *әнием* сүзен – 60%, *әнкәй* – 0,6%, *мама* – 3,6% респондент куллана. Сирәк очракларда *әника* вариантын билгеләүче балалар да бар, алар, башлыча, шәһәр җирлегендә яшәүче гаилә вәкилләре булып торалар. Төгәлрәк картинаны түбәндәге таблицада карап үтик:

Таблица1

| **Кулланылыш даирәсе** | **Туганлык атамасы** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ***әни*** | ***әнием*** | ***әнкәй*** | ***мама*** | ***әника*** |
| **Тәтеш районы** | 65,7% | 18,3% | 16% | – | – |
| **1 төркем, Казан** | 47,1% | 45,2% | 4,2% | 1,5% | 2% |
| **2 төркем, Казан** | 28,8% | 60% | 0,6% | 3,6% | 7% |

Туганлык терминнары арасында гаиләдә өлкән буын вәкилләрен атаган төркем составы ягыннан шактый төрле. Татар гаиләләрендә бабайны атау өчен *бабай, дәү әти, бабаем, бабакай* кебек атамалар кулланыла. *Бабай* атамасы гомумтөрки **baba* сүзенә барып тоташа. К.М. Мусаев, билгеләвенчә, әлеге атама борынгы төркиләрдә нәсел башлыгын белдергән һәм семантик яктан аерымланмаган булган [Мусаев, 2006, с. 538]. Күп кенә төрки телләрдә бу сүз хәзер дә ата кешене белдерү өчен кулланылса, татар телендә исә әти яки әни кешенең әтисен белдерү өчен кулланыла. Без тикшергән төркемнәрдә *бабай* сүзенең әнинең әтисен яки әтинең әтисен белдерүдә зур аерымлыклар күзәтелмәвен әйтеп үтәргә кирәк.

Хәзерге гаиләләрдә *бабай* сүзенә 1 нче зат тартым кушымчасы -*ым* ялганып ясалган *бабаем* вариантының шактый активлашуы күзәтелә. Югарыда карап үткәнчә, мондый төр туганлык атамалары ясау моделе (термин + 1 зат тартым кушымчасы) хәзер киң таралыш тапкан һәм күпчелек очракта шәһәр җирлегендә яшәүче гаиләләрдә актив кулланыла.

*Дәү әти* атамасы татар теле үсешенең соңрак чорларында барлыкка килгән һәм хәзерге татар телендә әлеге тасвирлама форма төрле структуралы телләрнең үзара керешүе нәтиҗәсендә шактый активлашты. Шулай ук татар теленең төрле диалектларында бу форманың синонимик рәтен тәшкил иткән *зур бабай, карт бабай* һәм башка шундый вариантлар булуын да искәртү зарур. Диалектларда бу төр формаларның кулланылышын, семантик төсмерләрен Д.Б. Рамазано-

ва югарыда аталган хезмәтендә тәфсилле аңлата [Рамазанова, 2014, б. 121–135]. Шулай ук Европа телләрендә мондый формаларның киң таралганлыгы мәгълүм, мәсәлән, алман телендә *«großmutter»* и *«großvater»*, инглиз телендә *«grandmother»* һәм *«grandfather»*.

*Бабай* атамасы һәм аның вариантларының өйрәнелгән төркемнәрдә кулланылышы түбәндәгечә: авыл җирлегендә: *бабай* (40,5%), *дәү әти* (37,2%), *бабаем* (17,6%), *бабакай* (4,7%).

Казан шәһәрендә киң таралыш тапканнардан түбәндәгеләрне атарга була: беренче төркемдә мондыйрак картина: бабай – 34,9%; бабаем – 25,2%; дәү әти – 17,7%; дәү әтием – 15,8 %; бабакай – 3,7%; дәү әтика – 1,8%, дедушка – 0,9%.

Икенче төркемдә *бабай* атамасын 20,3% респондент куллана; бабаем – 38,3%; дәү әти – 24,3%; дәү әтием – 3,4%; бабакай – 2,0%; дедушка – 4,9%; дәү әтика – 6,8%. Бу төркемдә *бабаем* атамасының кулланылышы *бабай* сүзенә караганда активрак икәнлеге күренә, шулай ук *дәү әти* атамасының да активлыгы зуррак. Моннан кала, шәһәр җирлегендәге гаиләләрдә рус теле йогынтысында барлыкка килгән *дәү әтика* атамасының да кулланылышы күзгә ташлана.

Р. Әхмәтьянов күрсәтүенчә, *әби* сүзе татар телендә ясалган: «әбә-й (к. әбә) > әбей; тат. теленнән (бигрәк тә «кендекче хатын» мәгъ.) күп күрше телләргә кергән: башк. әбей, чув. эпи, апи, мар. ави, äви, äбий (к. Гордеев I: 33), удм. аби һ.б. Гомумән, шуңа охшаш сүзләр барлык Урал-Алтай телләрендә очрый: ком. абай, әбәй «әби», кар., төр. эбә, әбә, эб, эбанай «кендекче әби», иске монг. ebei «әни», як., эвенк. эбэкэ «әби» һ.б» бар [Әхмәтьянов, 2015, 1 т., б. 122]. Хәзерге татар телендә *әби, дәү әни, әбием, әнкәй, әбекәй, әбикә* кебек вариантлар актив кулланылышта йөри. Әлеге вариантларның кулланылыш ешлыгы түбәндәге таблицада китерелә.

Таблица 2

| **Кулланылыш даирәсе** | **Туганлык атамасы** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ***әби*** | ***әбием*** | ***дәү әни*** | ***әбекәй*** | ***дәү әника*** | ***әбика*** | ***бабушка*** |
| **Тәтеш районы** | 29,7% | 33,2% | 36,4% | 0,7% | – | – | – |
| **1 төркем, Казан** | 25,7% | 32,4% | 38,2% | 2,8% | 0,9% | – | – |
| **2 төркем, Казан** | 18,4% | 46,3% | 29,6% | 2,2%; | 0,9% | 2% | 0,6 |

Гаилә сөйләмен туплаган аудиоязмаларны өйрәнеп тә без, башлыча, югарыда каралган терминнарның кулланылышына тап булдык. Мисал өчен, гаилә сөйләменнән алынган кайбер фрагментларга тукталып үтик. Беренче фрагмент авыл җирлегендә яшәүче 89 һәм 45 яшьлек информантлар сөйләменнән алынды: *Әни, нихәлең бар? / Кайсыгыз ул? / Вәсилә. / Ә-ә-ә, ий, кызым, әллә нәрсә түгел. Авыраям, һаман авыраям. / Шулайдыр инде, әни, шулайдыр инде.* Икенче фрагмент шулай ук авыл җирлегендә яшәүче 54 яшьлек әти һәм 22 яшьлек

кыз сөйләменнән: *Кызым, чәй алып бир әле миңа. / Мә монысын, әти. / Менә монысы әнкәңә, кызым*. Алдагы өзек 88 яшьлек бабай һәм 23 яшьлек оныгы сөйләменнән алынды: *Сәлам бабыкай. Ничек хәлләрең? / Сәлам, кызым. Хәлләр... ярай инде, ярай, картлый инде. Шул инде хәзер. Син нихәлдә? / Әйбәт мин, бабыкай.*

Шәһәр җирлегендә яшәүче гаиләләргә рус теленең йогынтысы, аның гаилә сөйләменә ныклап үтеп керүе шактый сизелә, мәсәлән, 22 һәм 10 яшьлек туганнар сөйләме, нигездә, рус телендә бара: *Әбиләр килми что ли авылдан? / Бәрия әби приехала. / Приехала? / Әнии... мама сказала, что приехали*. Биредә әнинең әнисен атау барышында *әби* сүзе белән бергә аның исеме дә кулланыла. Шулай ук *әни* һәм *мама* терминнарының янәшә кулланылуы күзәтелә. Икенче фрагментта 1 зат тартым кушымчасы ярдәмендә ясалган туганлык терминының атау функциясендә килүе әни кешене генә түгел, башка туганнарны атау өчен дә кулланылганлыгы күренә: *Әнием, әйдә яса әле миңа шундый салатны, мин сиңа чипсы алып кайтам. / Апаңа әйтермен, алып кайтыр, син бала әле. / Апам да бала бит әле. / Ишеттеңме, әнием, мин дә бала әле* (21 һәм 9 яшьлек туганнарның әниләре белән сөйләшүеннән).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге гаиләләрдә туганлык атамаларның составы тараю тенденциясе сизелә. Диалект һәм сөйләшләрдә таралыш тапкан һәм гасырлар дәвамында кулланылып килгән атамалар беркадәр пассивлаша, кайберләре бөтенләй кулланылмый. Шулай ук рус теле тәэсирендә татар теленә яңа төр формалар үтеп керә яки алар татар теле җирлегендә барлыкка килә. Әлбәттә, әлеге эзләнү нәтиҗәсендә генә катгый нәтиҗәләргә килергә мөмкин түгел, моның өчен тагын да киңрәк тикшеренүләр таләп ителә. Шулай да искәртеп үтү зарур: татар теленең диалект һәм сөйләшләрендә теркәлгән күп кенә туганлык терминнарының пассив кулланылышы киләчәктә аларның юкка чыгуына китерүе бар. Туганлык атамаларын белү һәм куллану туган телне, милли үзенчәлекләрне мөмкин кадәр бөтен килеш саклау күзлегеннән генә түгел, бәлки милләтнең яшәеше яссылыгында да каралырга тиеш. Туганлык атамаларының көнкүреш аралашуда югалуы яки исем белән, башка телләрдән кергән вариантлар белән алмашуы татар гаиләсенең нигез ташларыннан булган ныклы туганлык мөнәсәбәтләренең дә какшавына китерергә мөмкин.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. I том: А–Л. 543 б.

*Мусаев К.М.* Картина мира пратюркского этноса по данным языка. Представления о небе и небесных явлениях // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. М.: Наука, 2006.

*Рамазанова Д.Б.* Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 287 б.

Словарь социолингвистических терминов / под ред. В.Ю. Михальченко. М.: Институт языкознания РАН, Институт иностранных языков, 2006. 312 с.

Современный русский язык: Социальная и функциональная дифференциация / Рос. Академия наук. Ин-т русского языка им. В.В. Виноградова. М.: Языки славянской культуры, 2003. 568 с.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе сүзлеге, 2002. 830 б.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен*
*һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау,*
*өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының*
*3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында*
*нәшер ителә*

***Галиуллина Гөлшат Рәис кызы***,
*филология фәннәре докторы, профессор, Казан федераль*
*университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы мөдире*

УДК 82.091

*А.С. Шәрипова*

# XX ЙӨЗ БАШЫ АЗӘРБАЙҖАН-ТАТАР ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫН НЫГЫТУДА НАРИМАН НАРИМАНОВНЫҢ РОЛЕ

Данная статья приурочена к 150-летию со дня рождения видного азербайджанского писателя, публициста, политического и общественного деятеля Наримана Нариманова (1870 – 1925), внесшего значительный вклад в развитие азербайджано-татарских литературно-культурных связей в начале XX века. Автором статьи освещается творческая и общественно-политическая деятельность Н. Нариманова, делается попытка определения его места в истории зарождения татарского театрального искусства.

**Ключевые слова:** Нариман Нариманов, Габдулла Тукай, азербайджано-татарские литературно-культурные связи, драматургия, театр, трагедия.

This article is dedicated to the 150th anniversary of the birth of a prominent Azerbaijani writer, publicist, political and public figure Nariman Narimanov (1870 – 1925), who made a significant contribution to the development of Azerbaijani-Tatar literary and cultural links at the beginning of the 20th century. The author of the article highlights the creative and socio-political activities of N.Narimanov, also an attempt is made to determine his place in the history of the emergence of the Tatar theater art.

**Keywords:** Nariman Narimanov, Gabdulla Tuqay, Azerbaijani-Tatar literary and cultural links, dramaturgy, theater, tragedy.

Нариман Нариманов (1870–1925) – күренекле азәрбайҗан язучысы, публицист, мәгърифәтче, мөгаллим, табиб, танылган сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе. XX йөз башында азәрбайҗан-татар әдәби-мәдәни багланышларын ныгытуда әлеге шәхеснең эшчәнлеге аерым игътибарга лаек.

Нариман Нариманов Тифлис шәһәрендә туа, Гори шәһәрендә Укытучылар семинариясендә белем ала, хезмәт юлын авыл башлангыч мәктәбендә укытучы буларак башлап җибәрә. Белем-мәгърифәткә омтылган яшь мөгаллим 1894 елда, шактый кыенлыклар белән, Баку шәһәрендә азәрбайҗан халкы тарихында беренче уку залын ачуга рәсми ризалык алуга ирешә. Зур булмаган фатир шартларында мөселманнар өчен оештырылган китапханәгә төрле телләрдә нәшер ителә торган кырыкка якын атамадагы газета килеп торуы, 1894 елның 8 апреленнән 4 маена кадәр вакыт аралыгында гына да әлеге уку залында җиде йөздән артык кешенең шөгыльләнүе турындагы мәгълүматлар [Ахмедов, с. 37] китапханәнең киң җәмәгатьчелек арасында зур кызыксыну уятуы турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Соңрак Нариман Нариманов инициативасы белән талантлы яшьләрдән торган театр труппасы оештырыла, аның үзенең дә режиссерлык итүе, спектакльләрдә аерым рольләрне башкаруы билгеле.

Әдип публицистика өлкәсендә дә актив эшли, газеталарда мәгариф, театр, хәйриячелек, әхлак мәсьәләләре буенча мәкаләләре дөнья күрә.

Мөгаллимлек эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, 1899 елда «Төрки-татар теленең кыскача грамматикасы», «Рус теле үзөйрәткече», «Руслар өчен татар теле үзөйрәткече» (ул чорда кабул ителгәнчә, «татар теле» сүзе астында азәрбайҗан теле күздә тотыла) хезмәтләре нәшер ителә.

Н. Нариманов әдәбият мәйданына 1890 еллар башында килә, әдәби эшчәнлеген проза һәм драматургия өлкәсендә башлый. 1892 елда Н. Гогольнең «Ревизор» комедиясен азәрбайҗан теленә тәрҗемә итә. Драматургның беренче пьесалары – «Наданлык» («Невежество»), «Шабдан бәк» – 1894–1895 елларда дөнья күрә. Образлар системасы, сюжет үстерелеше үзенчәлекләре, теге яки бу күренешкә комментарий бирү яки аерым идеяләрне пропагандалауга корылган озын монологлар булу пьесаларның мәгърифәтчелек реализмы рухында иҗат ителүен күрсәтә. Әлеге драма әсәрләре – «милли мәгърифәтчелек идеологиясе һәм реалистик әдәби-эстетик модельнең классик чагылышы» [Рустамова, с. 385].

1896 елда «Бахадур һәм Сона» повесте басылып чыга. 1913–1916 елларда автор үзенең әлеге драма һәм проза әсәрләренә кабат кайта, билгеле бер үзгәрешләр кертә, «Бахадур һәм Сона» повестеның пьеса вариантын (1915) эшли. Моннан тыш, Григорий Генның «Җәза» («Казнь») драмасын азәрбайҗан теленә тәрҗемә итә, «Пир» повестен, «Бер авылдагы маҗаралар» («Приключения в одном селении») хикәясен иҗат итә. Әсәрләрнең нигезенә кешене аң-белемгә өндәү, югары идеалларга хезмәт итәргә чакыру идеясе салынган.

Драматургның азәрбайҗан әдәбиятына яңалык алып килгән әсәре – «Надир шаһ» (1899) пьесасы. Ул – азәрбайҗан әдәбияты тарихындагы тарихи трагедия жанрына караган беренче әсәр, авторның моңа кадәр иҗат ителгән пьесаларыннан сюжетының, үзәк герой һәм персонажларның катлаулы характеры, рухи яктан каршылыклы булуы белән аерылып тора. Әсәрдәге вакыйгалар бер-берсеннән кискен аерылган шартларда (шаһ сарае, сугыш кыры), төрле вакыт арасында (Надирның яшь чагы, картлык чоры) бара. Үзәк герой Надир әсәр дәвамында юлбасардан – полководецка, соңрак шаһка әйләнә. Азәрбайҗан галиме Тахира Мамед «Азербайджанская национальная литература» хезмәтендә трагедиянең аерым сугышларның тасвирланышы, героик күренешләр булу, сарай интригаларын күрсәтүгә урын бирелү, герой тирәсендәге вакыйгалар үрелеше буенча борынгы эпос традицияләре белән аваздаш булуын билгеләп үтә [Мамед, с. 69].

Азәрбайҗан-татар әдәби-мәдәни багланышларын ныгытудагы роле, татар театры һәм драматургиясенә алып килгән яңалыгы ягыннан XX йөз башында әлеге пьесаның татар театры сәхнәсендә куелуы аерым игътибарга лаек. «Надир шаһ» трагедиясен татар тамашачысы беренче тапкыр 1908 елда карый. Ул, азәрбайҗан һәм татар артистлары Тифлистә очрашу нәтиҗәсендә, Габдулла Кариев һәм Хөсәен

Араблинский җитәкчелегендә оештырылган «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» тарафыннан сәхнәгә куела. Спектакль 1908 елның җәендә (Х. Араблинский режиссерлыгында) азәрбайҗан телендә Әстерхан шәһәренең «Аркадия» бакчасы, Түбән Новгород шәһәренең «Фоли-Бержер» театрларында аншлаг белән үтә.

Уртак эшчәнлек ике милли труппаның да репертуарын баета. Шул чордан башлап, татар театры сәхнәсендә Н. Нариманов, М. Ахундов һәм башка азәрбайҗан авторларының пьесалары ныклы урын ала [Салихова, б. 112]. «Азәрбайҗан актерлары белән бергә эшләү чорында татар труппасы, репертуарына үзе өчен яңа булган трагедия жанрын кертеп, иҗади диапазонын киңәйтә, моңа кадәр азәрбайҗан сәхнәсендә куелган Көнбатыш Европа классикасы үрнәкләре белән таныша» [Илялова, с. 61].

Гомумән, «Сәйяр» труппасының 1907–1910 еллар репертуарындагы 40 лап спектакльнең бары тик икесе генә трагедия жанрына караганлыгы билгеле. Һ. Мәхмүтов әлеге күренешнең берничә сәбәбен күрсәтә. Беренчесе – төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып оешкан профессиональ труппаның, драматургиянең, театрларның формалашу чорына хас үзенчәлекләрнең берсе буларак, комедиячел юнәлештә башлангыч алуы. Галим моны иҗтимагый хәрәкәт яки тормыш-көнкүрештәге актуаль мәсьәләләр, кимчелекләр тизрәк тотып алыну, бу жанрга хас гадилек, сәхнәгә кую өчен чагыштырмача җиңел булу, катлаулы драма һәм трагедияләрнең сәхнә әдәбияты беркадәр өлгергәч барлыкка килүе белән аңлата. Икенче сәбәбе буларак, әлеге чорда кешене, җәмгыятьне камилләштерү мәсьәләсенең сәнгатьтә, әдәбиятта алга чыгуы, шуның нәтиҗәсе буларак, комедияләрнең күбрәк язылуын яки тәрҗемә ителүен билгеләп үтә. Өченчесен җитди драма һәм трагедияләргә караганда, комедияләрне сәхнәләштерү өчен рөхсәтнең тизрәк бирелүе белән бәйли [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт, б. 82–83].

«Трагедия жанры татар театрына, нигездә, 1913–1914 елларда Ф. Шиллер, Г. Гейне, Н. Нариманов әсәрләрен тәрҗемә итү аша килеп керә. Бер үк вакытта бу агым тормышны киң масштабта һәм калку, конфликтларны кискен итеп сурәтли торган романтик юнәлешнең дә активлашуына китерә. Шул рухта М. Фәйзинең «Галиябану», Г. Исхакыйның «Зөләйха», Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедияләре мәйданга чыга» [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт, б. 357].

1913 елда «Надир шаһ» трагедиясе Г. Адаков тәрҗемәсендә Әстерхан татар театрында татар телендә (режиссеры – З. Солтанов) сәхнәгә куела.

1915 елда тарихи трагедияне татар теленә Ф. Сәйфи-Казанлы тәрҗемә итә, һәм пьеса Петербург цензурасы рөхсәте белән 1917 елның 20 гыйнварында Казанда Зур театр сәхнәсендә күрсәтелә. Әлеге вакыйга татар тамашачысы тарафыннан яңалык буларак кабул ителә, бу уңайдан «Аң» журналында Г. Кәрамның «Надир шаһ» вә «Ванушинның балалары» мәкаләсе басылып чыга, автор трагедияне «Иран шаһларының хәятыннан алынган гүзәл вә мәгънәле бер әсәрдер», –

дип бәяли [Татар әдәбияты тарихы, б. 365].

Әлеге пьеса шулай ук Уфада «Нур» театрында, соңрак, 1924 елда, Беренче дәүләт татар драма театрында сәхнәгә куела. Төрле елларда трагедиянең үзәк герое Надир ролен Әстерханда З. Солтанов, Казанда Г. Кариев һәм Уфада М. Мутин башкаруы билгеле.




1917 елның 27 июлендә Казанда уйналган «Надир шаһ» спектакле (авторы – Нариман Нариманов) программасы

Татар театры тарихында Н. Наримановның «Надир шаһ» трагедиясе милли сәхнәдә куелган беренче тарихи әсәр буларак та игътибарга лаек. Ул «алынган проблемалары, материалы белән дә, жанр ягыннан да репертуарны баетып җибәрә, романтик юнәлешнең җанлануына, колачлырак булып үсеп китүенә этәргеч ясый, тарихи сюжетларга яки легендаларга нигезләнгән әсәрләрнең сәхнәгә чыгуына юл ача, җирлек әзерли. Моның белән генә чикләнеп калмыйча, тарихи һәм романтик трагедияләргә кыюрак мөрәҗәгать итәргә кирәклеген, мондый адымнарга театрның көче җитәрлек булуын ачык күрсәтә» [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт, б. 192].

Нариман Нариманов татар мәдәнияте үсешендә үзе дә турыдан-туры катнашкан шәхес. Ул, Одесса университетының медицина факультетында югары белем алу чорында революциягә бәйле сәяси вакыйгалардагы активлыгы нәтиҗәсендә, 1909 елда Әстерханга сөргенгә җибәрелә. Әстерханда яшәү чорында, табиблык эшчәнлеге белән беррәтттән, иҗтимагый-сәяси һәм мәгърифәтчелек эшен дәвам итә. Татар һәм рус телендә нәшер ителүче җирле вакытлы матбугат басмаларында әдәбият, сәнгать, педагогика, медицина мәсьәләләре буенча мәкаләләре басылып тора.

Н. Нариманов Каспий диңгезчелеге эшләре буенча Әстерханга килгән А. Ахвердов, «Молла Насретдин» журналының сөргенгә җибәрелгән хезмәткәре Р. Наджафов белән тыгыз аралаша, алар шәһәрнең мәдәни тормышына актив кереп китәләр. «Шураи-ислам»

җәмгыяте каршында татар-кавказ театр труппасын оештырып җибәрәләр һәм әлеге коллектив азәрбайҗан һәм татар телләрендә спектакльләр кую белән шөгыльләнә башлый. Труппаның репертуарын билгеләү, яшьләрне сәнгатькә тарту, спектакльләрнең сәхнәгә куелыш сыйфатын, идеялелекне үстерү юнәлешендә эшлиләр. Әстерхан театр труппасының шул чордагы җитәкчесе Зәйни Солтанов үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «1910 елларда безнең труппа аеруча җанланып китте. Нариман Наримановның Әстерханга сөргенгә җибәрелүе һәм шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең килүе труппаны күтәреп, рухландырып җибәрде. Нариманов, доктор һәм зур культура иясе булу белән бергә, театр сәнгатенең яхшы белгече һәм театрга бик якын торган кеше иде. Ул Әстерханга килеп төшүенә безнең белән кызыксынды һәм безнең репетицияләргә килеп йөри башлады. Ул вакытларда Әстерханда азәрбайҗан төрекләре дә күп иде. Алар үз телләрендә сирәк-сирәк кенә булса да спектакльләр куйгалыйлар иде. Ләкин хатын-кызның бөтенләй булмавы аларны еш кына уңайсызлыклар кичерергә мәҗбүр итеп килде, ә бездә, күп булмаса да, берничә хатын-кыз бар иде. Нариманов хәлнең ничек булуын бер күрү белән сизеп алган булса кирәк, ике труппаны берләштереп, татар һәм азәрбайҗан төрки телендә бергәләп спектакльләр кую фикерен алга сөрде. Безгә, Әстерханда үскән татар яшьләренә, азәрбайҗан төрки теле таныш булганга, азәрбайҗан спектакльләрендә катнашу артык читен булмады һәм без, татар спектакльләре белән беррәттән, Нариманов җитәкчелегендә азәрбайҗан телендә уйналган спектакльләрдә дә катнашып килдек...» [Рахманкулов, б. 3].

Азәрбайҗан галиме Керимов Ингилабның «Становление и развитие азербайджанского театра (конец (XIX – начало XX в.)» хезмәтендә татар театрына нигез салынуны Н. Нариманов, А. Ахвердов һәм Г. Араблинский исемнәре белән бәйләве очраклы түгел. Ул Н. Наримановның драматург буларак кына түгел, актер буларак та, режиссер һәм театрны оештыручы буларак та татар театры тарихында аерым урын алып торуын билгеләп үтә [Керимов, с. 194]. Х. Гобәйдуллин да Нариман Наримановны Әстерхан татар театр труппасына якыннан торып булышлык итүче кешеләрнең берсе буларак бәяли [Татар совет театры, б. 27]. Бу турыда Һ. Мәхмүтов болай дип яза: «Әстерхан татар театры 1909 елдан башлап аеруча җанлана. Бу, беренче чиратта, илдәге гомуми культура үзгәрешләре йогынтысында З. Солтанов, Җ. Байкин, Г. Адаков һ.б. яшьләрнең эшне активлаштыруына бәйле булса, икенчедән, бигрәк тә 1909–1914 елларда Әстерханда читтән килгән бик күп культура эшлеклеләре яшәве белән дә аңлатыла. Мәсәлән, шундыйлардан күренекле революционер, драматург һәм доктор Нариман Нариманов, шагыйрь һәм драматург Сәгыйть Рәмиев, язучы Фатих Сәйфи-Казанлы, укытучылардан Хөсни Кәрим, Касыйм Туйбахтин, Саттар Еникиев, артист Әхмәт Кулалаев Әстерхан театры белән тыгыз бәйләнештә булалар, театрны оештыру, дөрес юнәлештә алып бару өчен күп ярдәм итәләр. Аерым алганда, бу яктан

Н. Наримановның эшчәнлеге зур игътибарга лаек» [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт, б. 308]. И. Илялова исә әдипнең рус мәдәнияте белән яхшы таныш булуын, аны пропагандалау юнәлешендәге эшчәнлеген ассызыклый [Илялова, с. 62].

Әдипнең татар зыялылары белән турыдан-туры бәйләнешләре да нәкъ менә Әстерханда яшәгән чорда башланып китә. Нариман Нариманов шул елларда Әстерханда нәшер ителгән «Идел» газетасында эшләүче Сәгыйть Рәмиев белән дуслаша. 2011 елда С. Рәмиев аны Әстерханга дәвалану өчен килгән Габдулла Тукай белән таныштыра. Әлеге аралашу соңрак дуслыкка әверелә. Г. Тукай вафат булгач, Нариман Нариманов шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү һәм әсәрләрен тарату юнәлешендә эшли. Ул 1913 елда Әстерхан университетының мөселман бүлекчәсендә Г. Тукай истәлегенә багышлап махсус лекцияләр оештырмакчы була, әмма, рәсми рөхсәт бирелмәү сәбәпле, бу нияте тормышка ашмый кала [Габдулла Тукай. Энциклопедия, б. 479]. Әлеге дуслык турында 1976 елда Самат Шакир «Тукай һәм Нариман» шигырен иҗат итә.

Гомумән, Нариман Нариманов – мөселман халыклары мәнфәгатьләрен яклауда, төрки телләрне саклау һәм үстерү юнәлешендә күп көч куйган шәхес. Ул 1919 елда Мәскәүгә эшкә чакырыла, Чит ил эшләре Халык комиссариатының Якын Көнчыгыш бүлеге мөдире, соңрак РСФСР милләтләр эшләре буенча халык комиссары урынбасары вазифаларын башкара. 1920 елда Азәрбәйҗан вакытлы Революцион комитеты рәисе итеп билгеләнә, 1921 елда Азербайҗан ССР Совнаркомы рәисе вазифасына сайлана. 1922 елдан СССРның Кавказ арты Республикалары Берләшмәсе җитәкчесе, 1923 елдан СССР Үзәк башкарма комитеты рәисләренең берсе була. 1925 елда ул Көнчыгыш институтының шәрәфле тыңлаучысы һәм Көнчыгышны өйрәнүче галимнәр бөтенсоюз ассоциациянең шәрәфле әгъзасы итеп сайлана. Әмма, озак та үтми, Нариман Нариманов вафат була, Мәскәүдә Кызыл мәйданда Кремль дивары янында җирләнә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: XX йөз башында ике тугандаш халык – азәрбайҗан һәм татар халкы арасындагы мәдәни бәйләнешләр шактый нык була. Әдәби традицияләр уртаклыгы нәтиҗәсендә, сәхнә сәнгате юнәлешендәге хезмәттәшлеккә нигез салына, әлеге эшчәнлек һәр ике як өчен дә билгеле бер дәрәҗәдә тәҗрибә мәктәбе булып тора. Бу җәһәттән күренекле азәрбайҗан әдибе, мәгърифәтчесе Нариман Наримановның XX гасыр башы татар мәдәнияте үсешендә турыдан-туры катнашуы, азәрбайҗан-татар мәдәни бәйләнешләрын ныгытуга керткән өлеше аерым игътибарга лаек. Ул шул чордагы татар мәдәнияте учакларының берсе булган Әстерхандагы татар театрын үстерү юнәлешендә шактый эш башкара, татар әдипләре белән тыгыз хезмәттәшлек итә, үзенең «Надир шаһ» тарихи трагедиясе белән татар сәхнә сәнгатенә яңалык алып килә.

2020 елда Нариман Наримановның тууына 150 ел тула. Бүгенге көндә дә татар халкы Нариман Наримановны хөрмәт белән искә

ала. Казан шәһәре үзәгендә тугандаш халыкларның ике зыялы шәхесе – Г. Тукай һәм Н. Нариманов исемнәрен йөрткән урамнар янәшә урнашкан. 2013 елда әлеге урамдагы 52 нче йортта Нариман Кербалаи Наджаф оглы Нариманов истәлегенә мемориаль такта куелу да шуны раслый.

**Әдәбият**


*Ахмедов Т.* Нариман Нариманов. Баку: Язычы, 1988. 280 с.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З.З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

*Илялова И.* Межнациональные связи татарского театра: монография. Казань: АН СССР, Казанский филиал, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова; Татар. кн. изд-во, 1985. 240 с.

*Керимов И.* Становление и развитие азербайджанского театра (конец XIX – начала XX в.). Баку: Элм, 1991. 292 с.

*Мамед Т.* Азербайджанская национальная драматургия. Тбилиси, 2001. 247 с.

*Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б.* Октябрьгә кадәр татар театры: очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 399 б.

*Нариманов Н.* Бахадур и Сона (повести и пьесы). М.: Художественная литература, 1971. 223 с.

*Рахманкулов Ш.* Тукай Астраханьда // Соц. Татарстан. 1983. 23 нояб.

*Рустамова А., Набиев Б., Караев Я.* Азербайджанская литература. Краткий очерк (для азербайджанской диаспоры). Баку: Элм, 2005. 456 с.

*Салихова А.Р.* Татар театрының үсеш этаплары // Фәнни Татарстан. 2016. № 4. Б. 111–120.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т.: XX йөз башы / фәнни мөх. Р.К. Ганиева; төз. Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 533 б.

Татар совет театры: очерклар / [А. Әхмәдуллин, Х. Гобәйдуллин, Б. Гыйззәт, Д. Гыйманова, И. Илялова, Х. Кумысников, Һ. Мәхмүтов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 496 б.



***Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми сәркатибе*

УДК 82.091

***Н.Ш. Насыйбуллина***

# ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ – МИРХӘЙДӘР ЧУЛПАНЫЙ

В статье делается попытка раскрыть влияние деятельности и творчества малоизученного татарского поэта Мирхайдара Чулпаныя на мировоззрение Габдуллы Тукая, шакирда медресе «Мутыгия» города Уральска. Помимо Мутыгуллы и Камиля Тухватуллиных, на развитие поэтического таланта Г. Тукая оказал большое влияние и Мирхайдар Чулпаный. Автор аргументирует актуальность данной проблемы, делает краткий обзор биографии и творчества духовного наставника Тукая Мирхайдара Чулпаныя.

**Ключевые слова:** М. Чулпаный, Г. Тукай, поэт, наставник, татарская поэзия, медресе «Мотыгия», г. Уральск.

The article attempts to disclose the influence of the activities and work of the little-studied Tatar poet Mirkhaydar Chulpanyi on the worldview of Gabdulla Tuqay, the shakird of the Mutygiya madrasah in the Uralsk city. In addition to Mutygullah and Camille Tuhvatullina, Mirheydar Chulpaniy also had a great influence on the development of the poetic talent of G. Tuqay. The author argues that this matter is relevant, gives a brief overview of the biography and works of Tuqay's spiritual mentor Mirkhaidar Chulpanyi.

**Keywords:** M. Chulpanyi, G. Tuqay, poet, mentor, Tatar poetry, madrasah "Mutygiya", Uralsk.

Тукайның әдәби мирасы, вакытлар үтүгә карамастан, бөтен тирәнлеге белән ачыла гына бара. Шагыйрьнең көнкүрешен, иҗатын тулырак күзаллау максатыннан, аның белән аралашкан шәхесләр турында мәгълүматлар туплана. Шагыйрьнең егерме җиде еллык гомеренең унике елы Җаекта үтә. Җаекта яшәгән еллары Тукай тормышының үсү, җитлегү, кечкенә Апуштан бөек Тукайга әверелү чоры булып тарихка кереп кала. Габдулла Тукайның шигъри таланты үсешенә Мотыйгулла хәзрәт һәм Камил Мотыйгыйның зур йогынты ясавы барыбызга да мәгълүм. Ә шигъри остазы булган Мирхәйдәр Чулпаный турында мәгълүматлар юк диярлек. «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыган Мирхәйдәр Чулпаный Оренбург губернасының Бозаулык шәһәреннән ерак булмаган Хөсәен авылында мулла вазифасын башкара. 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгаруы билгеле [Хәмидуллин, б. 25]. Шагыйрь турында мәгълүматлар 1900 елда Оренбургта Б.А. Бреслин нәшриятында басылган «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» дип исемләнгән китабында чагылган [Әхмәтҗанов, б. 76]. Чулпаный Тукайны якын күргән, үз шигырьләрен укып, аларның төзелешен аңлаткан. Бу исә Тукайның шигырь белеме өлкәсендә мәгълүматын шактый арттырган.

Җаек шәһәрендә шәкерт Тукай белән якыннан аралашкан Мирхәйдәр Чулпаный турында Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәр аерым

фикерләр язып калдырсалар да, әлеге язмаларда шагыйрьгә бәйләнешле төгәл мәгълүматлар бик аз. Тукай энциклопедиясендә З.З. Рәмиев тарафыннан язылган мәкаләдә шуны күрәбез: «Мирхәйдәр, Бузулук шәһәре (хәзер Оренбург өлкәсе) янындагы бер авыл мулласы, шагыйрь. Яшьлегендә берара «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганлыктан, ул ел саен Уральскига килеп, бу мәдрәсәдә озаклап торып китә торган була. Истәлекләрдә аның Тукайны яратуы, еш кына әңгәмәләшүе әйтелә. Үзе язган шигырьләрен укуы, аларны ничек язуы турында сөйләве Тукайда шигырь язуга омтылыш тудырган (Мотыйгулла хәзрәттән гаруз гыйлеме турында дәресләр дә ала). К. Мотыйгый истәлегендә «бергәләп утырганда аларның «Хәраб итде бези, аһ, бу җәһаләт, / Нәләр янды безә, аһ, бу сәфаләт» дигән шигырьне бергәләп көйләп утыруларын ишет»үе языла. Тукайның исә Чулпаныйдан үрнәк алып, «Мотыйгыя» мәдрәсәсе назыйре В. Хәмидуллинга багышлап язган шигыре дә («Тугъды, көн тугар кеби..» дип башлана) китерелә » [Габдулла Тукай. Энциклопедия, б. 755].

Чулпаный «Тукай турында истәлекләр» китабында (Казан, 1986), «Тукай – ядкярләрдә» җыентыгында басылган «Габдулла мәрхүм Тукай хакында хосусый ядкәр» исемле «Че» тәхәллүсе белән бирелгән автор мәкаләсендә дә телгә алына [Тукай – ядкярләрдә, 2 т, б. 223]. Бу автор турында әлегә мәгълүмат булмавы һәм аның мәкаләсе беренче мәртәбә «Кояш» газетасының 1914 елгы 2 апрель санында, аннан соң авторы Галиәсгар Мөгыйн улы Гафуров-Чыгтайга (1867–1942) нисбәт ителеп, кыскартылган вариантта «Тукай турында хатирәләр»дә, «Че» тәхәллүсе белән «Тукай турында истәлекләр»дә басылуы әйтелә. «Хәйдәр мулла – Мирхәйдәр Чулпаный (сүз Мирхәйдәрҗан бине Сөнгатулла бине Зөлкарнәен әл-Чулпаный турында бара) үз вакытында Җаектагы «Мотыйгыя» мәдрәсәсен тәмамлаган һәм Оренбург губернасындагы (хәзерге Оренбург өлкәсенең Тоцкий районындагы) Хөсәен дигән авылда мулла вазифасын башкарган. Елга бер мәртәбә әлеге уку йортына килеп, берәр ай торып китә торган булган. Шул вакытларда Г. Тукай аның белән аралашкан».

Чулпаныйга кагылышлы беркадәр хәбәрләр күренекле татар язучысы Әхмәт Фәйзи әсәрләрендә [Фәйзи, б. 438], Рабит Батулланың «Апуш-Тукай» кыйссасында [Батулла, б. 75] язылган.

Мирхәйдәр Чулпаный һәм Габдулла Тукай арасындагы үзара танышлыкның барышын язучы Әхмәт Фәйзи «Тукай» романында образлы итеп бирә [Фәйзи, б. 349]. Чулпаныйны ул эзләнүчән, яңалыкка омтылучан, шәкертләрдә дә шушы сыйфатларны тәрбияләргә тырышкан кеше итеп сурәтли.

Әхмәт Фәйзи иҗатын өйрәнеп, аның әдәби осталыгын тикшерүгә багышланган хезмәтендә З. Шәйхелисламов әдипнең архивында Мирхәйдәр Чулпаныйга багышланган кызыклы мәгълүматлар туплануын яза [Шәйхелисламов, б. 83].

Мирхәйдәр Чулпаный хакындагы мәгълүматларны беренче булып фәнни әйләнешкә Ибраһим Нуруллин кертә. Тукай тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтендә ул: «Ел дәвамында Г. Тукай «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыганда шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный белән таныша. Чулпаный «Мотыйгия» мәдрәсәсен тәмамлаган яңа карашлы шагыйрь була. Г. Тукайда шагыйрьлек дәрте уятуга билгеле бер йогынты ясый. Шигырьләрен ул *(Мирхәйдәр),* остазлары Әбелманих Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки кебек үк, «югары стильдә», ягъни авыр аңлаешлы корама телдә язган» [Нуруллин, б. 70], – дип яза.

Бу факт Ф.И. Ибраһимова һәм Ә.Х. Алиева төзегән «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» [б. 15] исемле китапта да урын ала.

Чулпаный муллалык иткән Хөсәен авылы – хәзерге Оренбург өлкәсе Тоцкий районындагы Саиновка авылы. Бузулук елгасы буенда урнашкан авылга 1787 елда беренчеләрдән булып Казан губернасыннан гаиләсе белән күчеп килеп Хөсәен Ишмәтов нигез сала [Хасанова, Искандаров, б. 250]. Соңыннан Тимәш[1] авылыннан, 1795 елда Бөгелмә өязеннән ике гаилә, 1788 елда Спас округы Чәчәкле авылыннан, 1807 елда Казан губернасыннан 30 гаилә килеп төпләнә[2]. 1920 елга кадәр авылда мәчет һәм мәдрәсә эшли, ахун вазифасы (урыны) була. Г.Х. Хәсәнова авыл тарихын яктыртуга багышлаган мәкаләсендә имамнарның тормышын һәм эшчәнлеген яктыртуны максат итеп куймый.

Шагыйрьнең «Мотыйгия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң да Хөсәен авылыннан елына бер мәртәбә мәдрәсәгә килеп берәр ай торып китүе, Оренбургта 1900 елда Б.А. Бреслин матбагасында нәшер ителгән «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе»3 (дастан. – *М.Ә.*) китабының басылуы, Мирхәйдәр дигән исемнең Эстәрлебаш, Юлык якларында популяр булуы – болар аның чыгышы ягыннан Оренбург ягы кешесе булуына ишарә итә, дип язды танылган галим М. Әхмәтҗанов «Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә» исемле хезмәтендә [Әхмәтҗанов, б. 132]. Галим Хөсәен исемендәге авылларның – Дим буенда Әлшәй һәм Дәүләкән төбәгендә булганлыгын ачыклый. Аларны чагыштырып караганда, Әлшәй төбәгендәге Хөсәен авылы Эстәрлебаш һәм Оренбург кебек татар мәдәни үзәкләренә якынрак булганга, Чулпаныйның хезмәт урыны булырга мөмкин дип фикер йөртә [Әхмәтҗанов, б. 56]. Мирхәйдәрнең шигъри таланты турында әлегә бер юл дә мәгълүм түгеллеге турында да телгә ала. Аның Оренбургта билгесез кеше тарафыннан 1900 елда китабы чыгарылуын, Казанда кайбер әсәрләренең басылган булуына да ишарә ясый.

---

[1] Тимәш авылы – Татарстанның Лениногорск районындагы авыл.

[2] ГАОО, ф. 98, оп. 2, ед.хр. 15.

[3] «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» – «Пәйгамбәрнең тууы турында гарәпчәдән тәрҗемә ителгән шигъри хикәя».

«Шагыйрьнең «Чулпаный» дигән тәхәллүсен аның яңа фикерле кеше күзлегеннән чыгып сайлап алган үз образы дип аңларга мөмкин», – дип яза галим һәм «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» әсәренең транслитерациясен ясап хәзерге татар теленә тәрҗемә итә:

Аллаһ, Аллаһ исмене йад идәрем,
Вирде нигъмәт шөкринә бәс нидәрем.
Хәмедне ул вә сани сүзләрем,
«Фазылны дөньйа вә гукьба күзләрем.
Нурпакь әнбийәйә чук сәлам,
Әс-салават вә әссәлам дирем мадам.
Шуйлә нур кем шаэни ирди интикаль,
Мәркәз абә кирамә иттисаль.
Әһле бәйтә эстәдем хакъдин риза,
Һәб сәхабә табигинә иртиза.
Нә гүзәл зикер мәфәхирел-әнам,
Зи кәрам әнсаб үтәди тәмам.
Хак гинайәт әйләсә идем бәйан,
Мәүлидин назыйм хәсән әйлә гәйан.
Кыйл могәттар рух пакен йа сәлам,
Рух аглай салават илә сәлам.

Тәрҗемәсе:

*Аллаһ, Аллаһ исемен искә алырмын,*
*Бирде байлык, шөкер итми нишләрмен.*
*Аллаһыны искә алган сүзләрем,*
*Биргән нигъмәтләрне шөкер йөзеннән нишләрмен.*
*Икенче сүзләрем мактау булыр,*
*Дөнья һәм ахирәттә фазыйләт иясен күзләрмен.*
*Нурлы һәм пакь пәйгамбәрләргә күп сәлам,*
*Дога һәм сәлам диярмен даими.*
*Шулай итеп нур иясе булган җирдән күчте,*
*Хөрмәтле аталарның мәркәзенә кушылды.*
*Аллаһ Тәгаләдән пәйгамбәрнең туганнарыннан*
*Риза булуын сорадым.*
*Ни гүзәл зикер кешеләрнең мактаулысын искә алып,*
*Хөрмәтле нәсеб үтәде тәмам бурычын.*
*Аллаһы Тәгалә ярдәм итсә бәян итәрмен,*
*Шагыйрьнең тууын яхшы күр.*
*Хуш исле рухын пакь ит, я Аллаһ,*
*Бөек рухында дога белән сәлам.*

Шигырьдә без Чулпаныйның борынгыдан килгән язма поэзия традицияләрен дәвам итүен күрәбез. М. Әхмәтҗанов Чул-

паныйның имамлыгына, аның ислам фәлсәфәсен, аның абруй тәрәкъләрен нык саклаучы булганлыгына басым ясый һәм шәхеснең XIX гасыр ахырларында татардагы ислам диненә карата Русия хөкүмәтенең тискәре сәясәтен нык тоеп яшәгәнлеген ассызыклый [Әхмәтҗанов, б. 132].

Мәдрәсә язма иҗат урыннарының берсе булган, шул сәбәпле борынгы поэзиядән килә торган традицияләр монда нык сакланган. Тормышның үзендә булган вакыйгаларга карата да яңа әсәрләр туган. Шул шартларда шәкерт-шагыйрьләр язма поэзиягә яңалыклар алып килгәннәр. Тукай үзе дә «Аң» шигырендә Чулпаный белән «Мотыйгия» мәдрәсәсе бинալары кысасында әңгәмәләр уздырган вакытларын искә алып:

> «Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
> Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел», –

дип яза һәм инде киләчәккә яңа караш, саф йөз белән карый башлау вакыты җиткәнен игълан итә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, Тукай иҗаты – меңьеллык татар шигъриятенең мөһим буыны, традиция һәм яңалык кушылуның күркәм бер үрнәге. Аның әсәрләрендә халкыбыз яшәешенең төрки чынбарлыгы һәм рухи тормышының әһәмиятле мәсьәләләре гәүдәләнеш таба. XX йөз башы татар шигърияте зур үсешкә ирешкән икән, моңа, әлбәттә, Тукай һәм аның остазы Мирхәйдәр Чулпаныйның да өлеше зур дип әйтергә була. Ләкин без Чулпаныйның тормыш юлын һәм иҗатын тирән һәм тулы яктырттык дип әйтүдән ерак торабыз, якын киләчәктә алар үстереләчәк, тирәнәйтеләчәк. Мәкалә әдипнең образын күз алдына китереп бастырырга, ул яшәгән чорның бөеклеген аңларга азмы-күпме ярдәм итә алса, куелган максатка ирешкән булырбыз.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.И.* Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә. 2015. 132 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Габдулла Тукай һәм Мирхайдәр Чулпаный // Түгәрәк уен. 2014. № 2. Б. 56–58.

*Батулла Р.* Апуш-Тукай: кыйсса // Казан утлары. 2011. № 4. Б. 75–86.

Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 271 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З.З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

ГАОО, ф. 98, оп. 2, ед. хр. 15.

*Нуруллин И.* Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр. 1979. Б. 70–71.

Тукай турында истәлекләр / төз. И. Нуруллин, Р. Якупов. Казан: Татар кит. нәшр., 1986. 431 б.

Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төзүчеләр: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр.

*Файзи А.* Тукай: роман. Казань,1985. 528 с.

*Фәйзи Әхмәт.* Әсәрләр. I том. Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. Б. 438–448.

*Хасанова Г.Х* Саиновка (Хөсәен). *Искандаров Р.Ш.* Оренбургские татары: историко-энциклопедический очерк. – Казань: Татар.кн. изд-во, 2009. 271 с.

*Хәмидуллин Л.* Кичке шәфәкъ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 255 б.

*Шәйхелисламов З.Р.* Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай). Казан: Фикер. 2001. 144 б.

***Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-1

***Н.М. Юсупова***

# 1960–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЯШЕРЕН ЭЧТӘЛЕК ҺӘМ АНЫ ҖИТКЕРҮ ЮЛЛАРЫ

Статья посвящена изучению приема иносказательности (эзопов язык) на фоне концепции лирического героя и смысловой трансформации традиционных символов в татарской поэзии 1960 – 1980-х годов. В ходе исследования утверждается, что индивидуально-авторские и традиционные для национальной словесности образы-символы превращаются выразителями «противоидеологической» позиции татарских поэтов. В структуре поэтических произведений они становятся номинациями субъективного отношения татарских поэтов к происходящим событиям, выступают в статусе намеков, недомолвок, использующихся преимущественно в гражданской лирике.

**Ключевые слова**: эзопов язык; татарская поэзия; концепция лирического героя; образ-символ; трансформация; функция.

The article is devoted to the study of the use of allegory (aesop's language) in Tatar poetry against the background of the concept of a lyrical hero and the semantic transformation of traditional symbols in Tatar poetry of the 1960[s] and 1980[s]. In the course of the research, it is stated that individual author's images and symbols, traditional for national literature, are transformed into expressions of the "anti-ideological" position of Tatar poets. In the structure of poetic works, they become nominations for the subjective attitude of Tatar poets to the events taking place, they perform in the status of hints, innuendos, used mainly in civil lyrics.

**Key words**: aesopian language; the Tatar poetry; the concept of the lyric hero; image and symbol; the transformation function.

1960–1980 еллар – татар әдәбиятының тематика һәм сурәтлелек ягыннан киңәю-тармаклану вакыты, ул поэзиядә яңа сыйфат үзгәрешләре белән билгеләнә. Өйрәнелә торган дәвердә татар шигъриятенең эчтәлеге, фикер көче, аны җиткерү формалары, әдәби-эстетик алымнары элгәреге чорлар поэзиясеннән аерылып тора һәм бу үзгәрешләр 1960 елларда башланып китә. Мостай Кәрим сүзләре белән әйтсәк, татар милли поэзиясендәге «шартлау»ның икенчесе (беренчесе – 1920 еллар уртасында) нәкъ менә 1960 елларга туры килә [Галиуллин, 2007, б. 4]. Яңарыш гомумкешелек мәсьәләләренә, мәңгелек темаларга игътибар арту, әдәби эзләнүләрнең объекты итеп моңа кадәр икенчерәк планда торган яисә әйләнеп үтелгән күренешләр алыну, «дөньяны фәлсәфи иңләргә омтылыш көчәю» [Богомолов, 1987, б. 127], яңа сәнгати эзләнүләр белән билгеләнә, шигъриятнең аһәңе һәм структурасы яңара, төрләнә һәм катлаулана, шигъри сүзнең егәрлеге, энергиясе һәм нюанслары, күренеш-детальләрнең мәгънәләре арта, лирик башлангыч көчәя [Юзиев, 1973, б. 25].

Бу чор татар поэзиясе яшерен эчтәлекнең көчәюе, аның төрле алымнар аша актуальләшүе ягыннан да үзенчәлекле кабул ителә.

Эзоп-киная теленең активлашуы, гомумән, 1960–1980 еллар поэзиясенә хас төп тенденцияләрнең берсенә әйләнә. Милли шигърият эзоп теленә моңа кадәр дә даими мөрәҗәгать итеп килә, ләкин өйрәнелә торган дәвердә ул тагын да киңрәк һәм кыюрак төс ала. Рус әдәбият белемендә 1960–1980 еллар поэзиясе үсешен, яңа сыйфат-үзенчәлекләрнең башлангычын «цензурага буйсынмаган» шагыйрьләр иҗаты белән бәйләп аңлату яши [Кукулин, 2001, б. 251]. Әлеге фикерне татар шигъриятенә карата да кулланырга мөмкин булыр иде. Җәмгыятьне, рәсми идеологияне кискен тәнкыйть божрасына алган эзоп теле шигъриятнең сәнгати яктан камилләшүенә – әсәрләрнең теле катлаулануга, образлылыкның, шартлылыкның көчәюенә сизелерлек йогынты ясый, «иҗат культурасын, укучының әдәби әсәрне кабул итү-аңлау зәвыгын да камилләштерә» [Лейдерман, 2003, б. 94].

Өйрәнелә торган чор шигъриятендә эзоп теле, бер яктан, үзенчәлекле лирик герой концепциясе аша актуальләшеп китә. Агымдагы чорда юмористик-сатирик юнәлеш яңа тип – кимчелекләрне күреп тә әйтә алмау газабын кичерүче, шуңа бәйле үз-үзе белән каршылыкта яшәүче лирик герой тибын алгы планга чыгара. Мондый шигырьләрдә яшерен эчтәлек тәнкыйть объектына әверелгән тәртип-кануннар кысаларында яшәп, үз-үзе белән каршылыкта гомер үткәрергә мәҗбүр ителгән лирик герой аша тирәнәйтелә. Әлеге хасият без тикшерү үзәгенә алган чорда иң элек Г. Афзал иҗаты белән бәйле аваз сала: шагыйрь гражданлык лирикасы белән сатирик шигърият чикләрендә үз синкретик язу рәвешен, гаять үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган кеше концепциясен тудыра, үз фикере, тормыш позициясе булган, әмма аны башкаларга җиткерергә яки төзәтергә үзендә көч тапмаган, шуңа бәйле үз-үзе белән каршылыкта яшәүче лирик герой тибы ярдәмендә татар поэзиясенең сурәтләү сферасын үзгәртә [Заһидуллина, 2015, б. 30]. Мисал өчен, Г. Афзалның «Елмаям уйчан гына» (1968), «Тун астында кыюлык» (1969), «Гомер китабы» (1969), «Чабаклар йөзгән Иделдә», «Бигрәк юаш басып йөрдем җирдә», «Канәгатьсезлек хисе» (1979), Р. Фәйзуллинның «Вулканнар бар диңгез төбендә» (1966), Г. Зәйнашеваның «Хаклык диңгезен кичәргә!» (1969), Ф. Яруллинның «Үземә тәнкыйть» (1965), Ш. Анакның «Капма-каршылыклар», Ш. Галиевнең «Кеше турында кайгырту», «Читтән торып», «Куркыныч аюлар», Г. Афзалның «Галимнәр бәянында», «Заман песие», «Чәнечкеле чәчәкләр», «Тәнкыйть сүзе» Ф. Яруллинның «Йөкләп түгел, бөртекләп» (1973), «Ел ахыры» (1975), «Әллә каян күренеп тора» (1977), Р. Мингалимнең «Гел» һ.б. шигырьләрдә лирик геройның «икегә бүленүе» – үз-үзе белән каршылыкка керүе күренә. Диңгезнең төбендә янартаулар булып та, өстенең тыныч халәттә калуы («Вулканнар бар диңгез төбендә»), күңелендә арыслан ятып та, кулында куян булуы («Чабаклар йөзгән Иделдә») кебек образ-сурәтләр лирик геройның эчке халәтенә ишарә ясый:

Акны кара диеп мин дә
Ялган яклап барыйм микән?..
Болганчык су өсләрендә
Тыныч кына агыйм микән?..
Юк, акмаска тыныч кына!..
Ташланырга дулкыннарга!..
[Зәйнашева, 2007, б. 147]

Эзоп теленә, яшерен эчтәлеккә йөз тоткан шигырьләрдә образ-символларның актив кулланылышы гомумбилгеле. Образ-символларга мөрәҗәгать итү, аларны субъектив фикерләрне җиткерү юлында файдалану татар шигърияте өчен традицион алымнардан санала. Билгеле булганча, 1920–1930 елларда бу тенденция аеруча көчәя. Мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә арткы планга күчеп торса да, 1950–1960 еллар чигендә ул кабат яңарып китә һәм иң яратып кулланган алымга әверелә. Шушы юлда авторлар татар шигърияте өчен үз, традицион саналган символлар белән янәшәдә индивидуаль, автор символларын мәйданга чыгара яки традицион образларны яңа мәгънә калыплары белән баета. Татар шигърияте бу яктан агымдагы дәвердә соклангыч экспериментлар мәйданына әверелә дисәк тә арттыру булмас.

Бер яктан, образ-символлар аша милли эчтәлек җиткерелә. Җәмгыять, сәяси вазгыять проблемаларын күтәрү, тормыш турында фикерләшү татар халкының яшәеше, менталитеты хакында уйлануларга алып килә. Милли проблеманың куелышы милләтнең тамырларыннан аерылуы, рухи нигезен югалтуы, иманы дәрәҗәсендә булган телгә мөнәсәбәтенең кискенләшүе хакында сөйләшүгә юл ача. Мондый шигырьләрдә лирик герой үз милләтенең киләчәк язмышы өчен борчылып, аның хокуксызлыгына әрнеп мәйданга чыга. М. Әгъләмов, Р. Харис, Зөлфәт, Р. Фәйзуллин һ.б. шигырьләрендә ат, тулпар, Идел, дала, Сабантуй кебек татар тарихына бәйле образлар киң кулланылышка кереп китә, аерым шигырьләрдә алар милли мәсьәләләр хакында фикер җиткерергә мөмкинлек бирә яки гомумкешелек мәсьәләләре хакында сөйләшүгә алып чыга. Мәсәлән, Р. Хариснең «Ат иярләү» (1983) поэмасының сюжетында икенчел эчтәлек «ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар» гыйбарәсе аша ачыла. Татар фольклорында ир-егетнең иң мөһим атрибуты – ат, җайдак батырлык символы, борынгы гуннар заманыннан килгән семантик схема буларак билгеле. Кәрамның аты белән сөйләшүе асылда үз күңеленең иң тирән төпкелләренә төшүе, үз күңеле белән сөйләшүе буларак аңлашыла.

Икенче яктан, образ-символлар иҗтимагый-сәяси төсмер белән өретелә. Бу тенденция бигрәк тә Х. Туфан, С. Баттал, Г. Афзал, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Рәш. Әхмәтҗанов, Роб. Әхмәтҗанов, К. Сибгатуллин, М. Әгъләмов һ.б. шагыйрьләр иҗатында көчле була. Шигырь-поэмаларда метафора-символлар, эзоп теле аша җәмгыятькә, система тәртипләренә бәя урын ала, кешенең үз-үзен танып-белү мәсьәләсе

төп проблема буларак күтәрелә, әсәрләрнең үзәгенә «без нигә мондый, тормыштагы гаделсезлеккә мин ничек җавап бирәм?» кебек сораулар куелып, тормыш гаделсезлеге тудырган борчылу, үкенү хисе эчтәлеккә үтеп керә. Мәсәлән, Х. Туфан үзенең «Сез кая барасыз, йолдызлар?» (1953–1967) шигырендә битараф йолдыз, җил, кибән, итек символларына күпмәгънәлелек биреп, сәясәт, илдәге тоталитар система образын тудыра:

...Эзне кая, итекне дә хәтта
Күреп булмый... Шундый караңгы.
Күктәгеләр күрми минем хәлне,
Ә мин күрәм, күрәм аларны...

Җемелдәмә, искә төшермә лә!
Ансыз да бит
Хәтердә минем:
Без Казанга «Сау бул» дигән төндә
Син болытлар артында идең,
Болытлар артында...
[Туфан, 2007, б. 74]

Шигырьдә лирик геройның әрнү хисенә үз чорындагы сәяси вазгыять сәбәп булып, болыт образы әсәр тукымасында шул эчтәлектә урын ала. Юану өлешенең булмавы, сызлануның даими дәвамлылыгы шагыйрьнең киләчәк өчен борчылуын, өметсезлеген искәртә. Охшаш фикерләр С. Батталның 1963 елда язылып та, 1994 елда гына дөнья күргән «Батый ханга ачык хат» (1963) әсәрендә дә чагылыш таба. Батый хан образы аша хакимнәргә мөрәҗәгать итеп, лирик герой Сталин, Хрущев чорларына тәнкыйть юнәлтә.

Шундый ук мотивлар К.Сибгатуллинның «Иске ярда уйлану» (1969) шигырендә дулаганнан соң ярларына кайткан елга, аның артыннан егылып авып калган имәннәр образлары ярдәмендә җиткерелә. «Ялган яз» (1969) шигырендә исә яшерен эчтәлек ялган яз символик образы аша тергезелә. Февральдә килгән яз, кешеләрнең алдануы, бер кинәнеп алуы шигырь структурасында 1960 еллардагы ярымдемократик үзгәрешләр кебек укыла. Лирик геройның борчылуы да язның ялган булуына, тиз узуына бәйле:

Иркә җаннар бер җылынып китте,
Бер кинәнеп алды,
Терелеп...
Февраль генә әле,
Ялган язга
әй, ышанган булды тереклек
[Сибгатуллин, 2007, б. 155]

Г. Рәхимнең «Яз» шигырендә дә шундый ук сурәт алга чыга. Беренче укылышта шигырь табигать күренешләре, яз килүе хакында хәбәр итә кебек, ләкин әсәр тукымасында бөре янәшәсенә язгы

табигать матурлыгына хас булмаган төрмә образының урнаштырылуы аны башкача шәрехләү мөмкинлеген дә бирә:

Инде март, инде яңару,
Туктатам димәсеннәр.
Котылырсың инде, яфрак,
Бөреләр төрмәсеннән

[Рәхим, 1986, б. 358]

«Яз» – ачкыч сүзе аша укучы җепшеклекне, халык өметләрен дә таный ала, шушы дулкында дүртьюллык «йокысыннан уянган» фикер хөрлеген туктату мөмкин түгеллеген искәртә.

Р. Фәйзуллинның «Җилфердәүче кerләр җыры» (1965) шигырендә керләр символы кешеләр тормышына, җил һәм кояш образлары аркылы чор хакимиятенә бәя булып аңлашыла [Йосыпова, 2018, б. 425]. «Халык әле кышта яши» (1973) шигырендә исә җәмгыятькә кыш образы ярдәмендә ишарә бирелә. «Уен» (1971) шигырендә яшәеш уен метафорасы аркылы гәүдәләндерелә. С. Хәкимнең «Никадәрле матур булмасыннар...» (1964) шигырендә әлеге вазифа чәчәк метафорик образына йөкләнә:

Никадәрле матур булмасыннар,
Гүзәл булмасыннар чәчкәләр,
Чәчкәләр дә күтәрелеп карый,
Исемнәре белән дәшсәләр…

[Хәким, 1986, б. 215]

Беренче карашка шигырь матурлык турында кебек, ләкин эзоп теле, киная белән С. Хәким кешеләрнең җәмгыятьтә бер-берсенә нисбәтән кешелексезлеге, мәрхәмәтсезлеге турында сүз алып бара. Аның лирик героен кешене шәхес итеп карамау борчуга сала.

М. Әгъләмовның «Без – курпылар» (1964), «Җил дә җил» (1965), «Җилле көндә җилләләр» (1976), «Язгы уяну» (1976) кебек шигъри үрнәкләрендә образ-символлар аша ачылган субъектив эчтәлек җәмгыятьтәге яшәеш кануннарының хаксызлыгын, тормыш-яшәештәге гаделсезлекләрне, авырлыкларны ачып бирүгә юнәлтелә. М. Әгъләмов «татар әдәбияты өчен традицион булмаган символлар уйлап таба, аларны шигырьне оештыручы үзәккә әйләндерә һәм шәхсиләшкән мәгънә юнәлешендә – фәлсәфи, гомумиләшкән эчтәлектә иҗтимагый фикерләр укылырлык итеп көйли. Символлар шагыйрьгә масштаблы фикер йөртергә һәм шуны укучыга җиткерергә мөмкинлек биргән төп алымга әйләнә» [Заһидуллина, 2015, б. 137]. Мисал өчен, шагыйрьнең «Без – курпылар» (1964) шигыре шушы дулкында иҗат ителә. Әсәр үзәгенә күпмәгънәле курпы образ-символы куелып, ул күтәрелгән мәсьәләләрне үз тирәсенә җыя. Бер яктан, ул «бер кат чабылган курпылар»ның берсе – язмыштан кагылу-сугылу күргән кеше буларак кабул ителә. «Без» исеменнән сөйләп, ачыклаулар ярдәмендә шагыйрь икенче мәгънә – «буын» эчтәлеген тудыра:

...Безнең йөрәкләрдә атайлардан
Көчеп килгән яшәү уты бар.
Алар тамырыннан шытып чыктык,
Без алардан калган курпылар.
[Әгъләмов, 1996, б. 32]

Алга таба әлеге мәгънәләргә шушы буыннар кичергән авырлык, фаҗигалар өстәлә, курпы образы инде шәхес культы вакыйгаларын, сугыш авырлыкларын, язмыш сынауларын үз җилкәсендә татыган ил кешеләре буларак гомумиләшеп җитә. Соңгы строфада «нәсел» сүзен кулланып, шагыйрь курпыларның тагын бер мәгънәсен төгәлләштереп куя: ул – милләт уллары. Әнә шулай күп мәгънәле символ аша М. Әгъләмов алдагы буыннар, ил-халык, милләт уллары кичергән фаҗигалар хакында сөйли, аларның фаҗигасы исә иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга, ил өстенә төшкән авырлыкларга бәйле аңлатыла. Кечкенә генә символик детальдән башлап, поэтик образлар ярдәмендә шагыйрь ил, халык, милләт язмышы, аның үткәне, бүгенге хәле, киләчәге хакында укучыны тетрәндерерлек, уйланырга, анализ ясарга мәҗбүр итәрлек гомумиләштерүләр ясауга ирешә.

«Җил дә җил» (1965) шигырендә автор позициясе традицион җил символы аша җиткерелә. Ул тормыш-яшәеш авырлыгы, ил кешеләре кичергән кайгы-фаҗигалар кебек мәгънәләрдә кулланыла һәм алдагы буыннар кичергән авырлыклар, аларның көнитеше турында сөйләү мөмкинлеген бирә. Алдагы строфада җил үзләре бер давыл булып килеп кергән һәм элгәреләр кичергән авырлыкларны «туздырып ташларлык», аларны сынмый-сыгылмый төзәтерлек буын буларак аңлашыла башлый. Шуңа бәйле шагыйрь «лаекмы без бүгенгегә?» соравына җавап эзли, үз буынына яңа мөмкинлекләр даулый, яшәеш кануннарын үзгәртү идеясе белән яна. Өзек-өзек җөмләләр кулланылышы бу фикернең катгый һәм кискен булуын тәгаенли:

Җил дә җил бүген,
Җил дә җил...
Йә юллар җыры булып ул,
Йә толлар җыры булып
Керә дә
Гадәти юлдан
Уйларны китә борып
...Үткән чорлардан яңгырый,
Ишетелә әллә кайдан.
Яңа буын. Яңа заман.
Яңа көч. Яңа мәйдан.
[Әгъләмов, 1996, б. 33]

«Җилле көндәй җиллеләр» (1976) шигырендә җил образы өр-яңа мәгънә калыпларында кулланыла. Беренче укылышта ул җепшеклек сәясәте, XX гасыр уртасындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр булып кабул ителә. Икенче строфада теткәләнгән наратның җан биреп басу уртасына авып төшүе ил халкының якты үзгәрешләргә өмете югалуны

шәрехләргә мөмкинлек бирә. Алга таба җил образы шушы үзгәрешләр дулкынында мәйданга килгән яшь буынны бәяләүгә юнәлтелә:

Кәпәчләрен тезгә салып,
Картлар тора көлемсерәп:
«Файдасызга очынуны
Яшьләргә бер күрү кирәк.
Яшьләргә бер күрү кирәк».
Халык әнә керфекләрен офыкларга теки кабат:
– Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...
[Әгъләмов, 1978, б. 24–25]

Әнә шулай М. Әгъләмов үз буынына бәя бирә, аларның омтылышлары, зур идеаллар белән янып яшәве укучы күңелендә соклану катыш якты бер моң тудыра. Әмма аларның «файдасызга очынуы», җил үткәннән соңгы халәтнең «озаккарак сузылуы» ул өметләрнең аклануына шик тудыра, мондый иҗтимагый вазгыять борчылу уята. «Язгы уяну» (1976) шигырендә шагыйрь үз чордашларын, аларның якты омтылышларын «иртә язда тауда уянган үләннәр», «үзләрендә рәшә уйнаткан үләннәр» итеп тасвирлаган М. Әгъләмов яшәү халәтләрен «вакытлы туңган, тик вакытлы туңган үлән» дип бәяли, якты киләчәккә ышанычларын «якты язга» – якты киләчәккә ышануда күрә.

«Тәрәзәгез булса» (1983) шигырендә дә ул үз буынының яшәү вазифасы хакында сүзне дәвам итә һәм шушы фонда «тәрәзә» образын татар әдәбияты өчен яңа мәгънәләрдә куллана. Гомумән, тәрәзә образ-символын М. Әгъләмов татар шигъриятендә киң кулланылышка кертеп җибәрә дисәк тә ялгышмабыз. Шагыйрь иске йортларның сүтелүе («Яңа урам булыр монда / Бетә иске йортлар»), яңа йортлардагы яңа тормыш («Бүлмәгә куылган суда / Бит чылату? Җиткән!») хакында сөйли. Шигырь структурасында тәрәзә образының, «Ачыгыз тәрәзәләрне / Булса тәрәзәгез!» гыйбарәсенең кабатланып килүе шигырьгә яңадан-яңа мәгънә төсмерләре өсти. Әсәр структурасында аның «өй тәрәзәсе», «күңел тәрәзәсе» «актив тормыш позициясенә тәрәзә», «яңа тормышка тәрәзә» мәгънәләре уйнатыла. Шушы фонда шагыйрь кеше холкына хас булырга тиешле иң төп сыйфатларны ачыклый һәм гражданин лирик герой яшәү мәгънәсен ил өчен яшәүдә, ил белән яшәүдә дип аңлата:

Яшәү ул – шул! Син илеңнең
Авазына кушыл!
[Әгъләмов, 2001, б. 356]

Шушы юлда Зөлфәт империя, кол, император, камчы, кулак кебек киң таныла торган образларны мәйданга алып чыга. Мисал өчен, аның «Тырнак» (1971) шигырендә «Сөргеннән котылган Гарәфи ага Хәсәнов болай сөйләде» гыйбарәсе шигырьне беренче юлларыннан ук иҗтимагый-сәяси дулкынга көйли. Илдәге сәяси вазгыять, шәхес

культы, кешеләрне сөргеннәргә озату, сугыш кебек ил кешеләре кичергән фаҗигалар лирик геройның әрнү хисенә сәбәп төсен ала. Эчке мәгънәгә ия Ачъяңак, Ата Аю, Кыргый Аю образларының бер-бер артлы кулланылышы, аларның баш хәрефләр белән бирелүе һәм ил белән янәшә куелуы шушы сәясәтне уйлап табучыларга ишарәли. Шигырь тукымасында алар Ленин, Сталин, Гитлер образлары кебек кабул ителә башлый:

Ә илемнең
баш түбәсен
Аю
Кубарды да атты бер читкә.
Кара төндә:
«Киен!» – дия-дия,
Кемнәр какты җылы ишеккә?
(...) Бүтән Аю килде ил өстенә,
Кыргый Аю тырнак чыгарды,
Ата җинаятьче
Илнең баш сөяген
Бөек Җиңү өчен кубарды.
Кыргый Аю
Изге үчен алды.
Ә без кем соң, илем? –
Кол гына...
[Зөлфәт, 1990, б. 59]

Кол, баш сөяге кубарылган кешеләр шушы илдә яшәүчеләр төсен ала. «Образлы гыйбарә – «баш сөяген кубару» – нәфрәт, үкенеч, кайгы хисләрен тоташтыра. Бер үк вакытта ул төрлечә укыла: илнең акыллы кешеләрен, лидерларын юк итү; илнең идарә системасын җимерү; гомумән, кешеләрне корбанга китерү кебек мәгънәләрне үз эченә сыйдыра». Ак болытлар образы исә шушы ил кешеләренең бәхетле тормыш хакындагы олы хыялы кебек кабул ителә, аның югары, ерак булуы лирик геройның әрнүен тагын да тирәнәйтә, кискенләштерә. Иң соңгы строфада ул: «мондый яшәү халәте шушы җәмгыятьтә яшәүчеләр күңелендә үзе дә «үчле Аю тырнагы», үч һәм нәфрәт булып укмаша һәм җавап хисе тудыра» дип кабатлый.

Охшаш фикер Зөлфәтнең ил сәясәтенә бәя төсен алган «Империя» (1973) шигырендә дә дәвам иттерелә. Көчле позициягә чыгарылган империя образы патша Россиясе һәм СССР кебек кабул ителә:

Һәм шул килеш, шундый хәлдә килеш
Азат итеп маташабыз тагын
Үзебезнең түгел –
Олы Җирнең
Бездән иреклерәк халыкларын!
[Зөлфәт, 1990, б. 36]

Сәяси вазгыятьнең кабатлануы, дәвам итүе лирик герой күңелендә туган үкенеч хисен тагын да тирәнәйтә. Соңгы строфада үкенеч иң югары ноктага күтәрелә. Шигырь тукымасында империянең «бала тапмас хәлгә килү»е киләчәкнең өметсез булуына ишарәли, ерак йолдыз чынга ашмас хыял төсендә кабул ителә, шушы халәттә яшәүчеләр кол буларак бәяләнә. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, «шуңа күрә бу система – колбиләүче һәм кол мөнәсәбәтләре түгел, монда император үзе дә – әлеге системаның колы. Әлеге фикерне ассызыклау өчен, лирик герой үзен император дип белдерә, чөнки ул да – мондагы колларның берсе! Үзирония соңгы тезмәдә әйләнеп кайткан чарасызлыкны чиктән тыш көчәйтә һәм бу хәлне үзгәртә алу мөмкинлеген бөтенләй юкка чыгара» [Заһидуллина, 2015, б. 147].

Зөлфәтнең «Камчы! Камчы!» (1974) шигырендә сәяси бәя камчы, «Томан» (1975) шигырендә томан образлары аша җиткерелә. «Болдино көзләре» (1981) шигырендә Пушкин чоры лирик герой яшәгән дәвергә бәя бирүгә юнәлтелә.

«Йә, кайсыгыз аңа төзәр пистолетны?
Йә, кайсыгыз анда яңа эполетлы?!»
[Зөлфәт, 1995, б. 108], –

юллары охшаш вазгыятьнең дәвамлылыгына ишарәли.

Шагыйрьнең «Мыскыл» (1978) шигырендә башка күренеш белән очрашабыз, ул ирония алымына таянып иҗат ителә. Г. Тукайның «Көзге җилләр» шигыре белән интертекстуаль бәйләнеш шигырьнең иҗтимагый-сәяси яссылыкта кабул ителүенә этәрә:

Язгы төн... Мин йоклый алмыйм –
Өй түрендә җил көлә!
Юк, җил көлми – шат яшәүнең
Шатлыгыннан ил көлә.
[Зөлфәт, 1990, б. 128]

Алга таба каршы кую алымы ирония тудыра, ул ирония ил тормышының тышкы ясалмалылыкка корылуын, ил яшәешендәге ялганны ачып бирүгә юнәлтелә, шушы яшәеш үкенеч катыш сызлану уята:

Җир өстендә безнең байрак
Әллә ничек җилпенә,
Йоклый алмыйм таңга кадәр –
Бездән бөтен ил көлә!
[Зөлфәт, 1990, б. 128]

Моннан тыш, укучыга тәэсир итү көчен арттыру максатыннан, Зөлфәт объектив сөйләм формасын киң кулланылышка кертә: аерым шигырьләр лирик герой исеменнән түгел, ә шушы фаҗигаларны кичергән кеше тарафыннан сөйләнелә башлый. Бу алым алга таба татар шигъриятенә хас гомумсыйфат буларак үстерелеп китә. Мисал өчен, «Игенче» (1974) шигыре шәхес культы, колхозлаштыру сәясәтенең

кешеләр язмышына тәэсире хакында сөйли. Сөргеннән качкан кулак язмышын, хис-кичерешләрен үзәккә алган бу шигырьдә җилнең елап-улап илерүе, хиснең дәрәҗәсен көчәйтү белән бергә, фаҗиганың асылын да тирәнәйтә:

Танырмы җир – җанкисәгем?
Җил исә елап-улап...
Нәрсә көтә мине анда?
Нигә кайтам мин, кулак?
Оча кантар тузаннары,
Без дә очтык, таралдык,
Ак казлары идек илнең,
Ак каз килеш каралдык.

[Зөлфәт, 1995, б. 205]

Алдагы юлларда, Һ. Такташ шигърияте традицияләрен дәвам итеп, җил – шымчы янәшәлеге тергезелә. Аерым кеше монологының шигырь структурасына кертелүе шул хакта сөйли. Күренгәнчә, җил образы Зөлфәткә чорга бәя бирүдә ярдәм итә. Иң соңгы строфада илдәге тәртипләрнең үзгәрмәве (конвойлы чана эзләре), киләчәкнең өметсезлеге (иртәгә дә, бүген дә) кулак буларак илдән сөрелгән кешенең генә түгел, шагыйрьнең дә сызлануы булып кабул ителә.

Шул рәвешле, 1960–1980 еллар татар шигъриятендә яшерен эчтәлекнең образ-символлар аша актуальләшүе актив алымга әверелә. Алар ярдәмендә җиткерелгән субъектив эчтәлек җәмгыятькә, сәяси вазгыятькә бәя җиткерү мөмкинлеген бирә, татар халкының яшәеше, менталитеты хакында фикер әйтү мәйданына әверелә. Шуңа бәйләп эзоп теле милләтнең тамырларыннан аерылуы, рухи нигезен югалтуы, кеше һәм җәмгыять, кеше һәм сәясәт арасындагы мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе хакында сөйләшүгә юл ача. Мондый эчтәлек үзенчәлекле лирик герой концепциясе аша да көчәйтелә.

**Әдәбият**

*Әгъләмов М.* Исәнме, йөрәк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 159 б.

*Әгъләмов М.* Иман тәрәз шакый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 335 б.

*Әгъләмов М.* Кан тамырын кистем. Казан: Рухият, 2001. 655 б.

*Богомолов Н.* Движение поэзии конца пятидесятых – восмидесятых годов // Современная русская советская литература в 2 ч. Ч. 1. М., 1987. С. 125–185.

*Галиуллин Т.Н., Йосыпова Н.М.* Басынкы елларның дәртле шигърияте // Татар шигърияте: 1960–80 еллар. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 3–26.

*Заһидуллина Д.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. 383 б.

*Зөлфәт.* Адашкан болыт. Казан: Татар.кит.нәшр., 1990. 223 б.

*Зөлфәт.* Ике урман арасы. Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. 287 б.

*Йосыпова Н.М.* Равил Фәйзуллин // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 8. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 412–433.

*Кукулин И.* О русской поэзии 1990-х годов. От перестроечного карнавала к новой акционности // Новое литературное обозрение. 2001. № 5. С. 248–262.

*Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н.* Современная русская литература: 1950–1990-е годы. В 2 т. Т. 1: 1953–1968. М.: Академия, 2003. 284 с.

*Рәхим Г.В.* Үз җиремдә үз җырым: шигырьләр, либреттолар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 447 б.

*Сибгатуллин К.И.* Бер ноктада: шигырьләр, поэмалар, балладалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 559 б.

Татар шигърияте: 1960–1980 нче еллар. Казан: Мәгариф, 2007. 319 б.

*Туфан Х.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. Т. 2: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 463 б.

*Хәким С.Т.* Сайланма әсәрләр. 2 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 366 б.

*Юзиев Н.Г.* Хәзерге татар поэтикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. 352 б.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф*
*Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 82-2

***Г.И. Каюмова***

# РИЗВАН ХӘМИД ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ПСИХОЛОГИЗМ

Статья посвящена анализу нравственно-психологического состояния персонажей в драмах Р. Хамида на фоне социально-общественных явлений, показаны причины, способствующие нарастанию внутреннего напряжения и противоречия, выявлен талант драматурга как тонкого знатока человеческих душ.

**Ключевые слова:** Р. Хамид, драматургия, психологизм, духовный мир, персонаж.

The article analyzes the moral and psychological state of the characters in R. Khamid's dramas on the background of social phenomenon, the causes contributing to the buildup of internal tension and contradiction are shown, the playwright's talent as a subtle connoisseur of human souls is revealed in it.

**Keywords:** R. Khamid, dramaturgy, psychologism, spiritual world, character.

Психологизм, кешенең эчке дөньясын ачу чарасы буларак, әдәбиятта шәхес концепциясе белән тыгыз бәйләнгән. Ул кеше күңеленең серләренә тирәнрәк үтеп керүдә, эмоциональ муллыкта чагыла. В.Е. Хализев фикеренчә, психологизм – «үзара бәйләнештәге, хәрәкәттәге һәм кабатланмас хис-кичерешләрнең индивидуальләштерелгән гәүдәләнеше» [Хализев, 2002, б. 211]. Драма жанрына караган әсәрләр арасында психологизм – аеруча драмага хас күренеш. «Геройларның борчулары, драматизм тулы кичерешләре аша билгеле бер чор аеруча төгәл күзалланса, бу әсәрне психологик драма дип атарга мөмкин» [Жанрово-стилевые искания..., 1988, б. 8]. Драманың әдәби төр буларак үзенчәлеге шунда ки, ул «психологик сурәтнең катгый, кискен һәм гаять дәрәҗәдә ачык булуын таләп итә» [Әдәбият белеме.., 2007, б. 148]. XX йөзнең 1970–1990 елларында һәм XXI йөз башында актив иҗат иткән, чынбарлыкның актуаль проблемаларына үзенчәлекле карашы, бөтен, кабатланмас характерлар тудыра белүе белән аерылып торган Р. Хәмид – психологизм остасы да. Ул әдип иҗатының эстетик асылын билгеләүче хатын-кыз образларын, аларның тирән драматизм белән сугарылган эчке дөньясын яктыртканда, кеше күңелендәге хис-кичерешләр эволюциясен, каршылыкларны сурәтләгәндә аеруча ачык күренә.

Сәхнә әсәрендә теге яки бу персонажның эчке дөньясы, рухи халәте аның кылган гамәлләре, сөйләме, аерым алганда, диалог, монолог, реплика аркылы, шулай ук автор ремаркасы аша яктыртыла. Болар арасында аеруча монолог кеше күңеленең үтә дә яшерен почмакларына үтеп керү мөмкинлегенә ия. Бу уңайдан әдипнең «Олы юлның тузаны» (1986) монодрамасындагы бердәнбер персонаж Нәүхәбәр әби монологы – моның уңышлы мисалы. Әсәрдә Нәүхәбәр гадилеге, самимилеге, өлкән яшьтә булуга карамастан җитезлеге, хәрәкәтчәнлеге,

һәр нәрсәгә игътибарлы булуы, истәлекле әйберләргә сакчыл карашы белән хәтердә кала. Мәгълүм булганча, «матур әдәбиятта психологизмның асылын, төшен уй-фикер һәм тойгы-кичерешләр, эмоцияләр агымы тәшкил итә» [Хатипов, 1976, б. 177]. Безнең игътибар үзәгендәге әсәрдә дә автор карчыкның уйлары, хис-кичерешләре белән бәйле күңел хәрәкәтен җентекләп яктырта. Әсәр сюжеты ялгызлык мотивы белән сугарылган. «Шәхес ялгызлыгы, нигездә, геройның психологик халәтен ачу, күңел каршылыкларын, башкаларга һәм җәмгыятькә мөнәсәбәттә фикер-карашлар төрлелеген бирүгә кайтып кала» [Закирҗанов, 2011, б. 108] һәм бу, гадәттә, әдәби геройның монологы аркылы тормышка ашырыла. Нәүхәбәр монологында героиня күңелендәге хисләр агышы, бер халәттән икенчесенә күчеп, әсәрне психологик яктан баета. Башта ана, язмышы белән килешкәндәй, ашыкмыйча, кабаланмыйча, үткәннәрнең бары тик матур мизгелләрен генә исенә төшерә-төшерә, үзе белән алып китәргә тиешле иң мөһим әйберләрен барлый. Көне буе юлда күтәрелгән тузаннарга карап, улы Тәфкилне көтә, үзенең аңа кирәк булуын тоеп юана; татарча белмәүче оныгын яратып, сагынып искә ала, аны күрәсе килү теләге белән яна, килене турында да начар уйламаска тырыша, ләкин, якты истәлекләре булган әйберләрдән тау өеме арткан саен, аның йөрәге тынычсызлана, күңелендә каршылык та үсә бара. Янында сырпаланып йөрүче мәчесен ара-тирә тиргәп торуы да, башы «чатнавы» да дәлилли бу күренешне. «Ә инде ананың картаймыш көнендә юанычлары булган мәчесе, кәҗәсе, казлары, безне калдырып китәсеңмени дигәндәй, каршысына килеп баскач, әлеге каршылык тагы да үсә» [Закирҗанов, 2004, б. 32]. Мондый вакытта кеше якты уйлар уйлау сәләтен югалта. Бөтен нәрсә аңа күңел кайтаргыч булып тоела башлый. Ананың сагынып көткән улы да, килене дә аның өчен үз җайларын гына кайгыртып йөрүче явыз ниятле затларга әверелә. Кеше күңелендәге мондый үзгәрешләр, ягъни «бер халәттән икенче халәткә каршылыклы күчешләр еш кына диалектик бөтенлек, рухи хәрәкәтнең гадәти агышы» [Хатипов, 1981, б. 93] буларак кабул ителә. Улыннан кайтып ала алмавы, үзенә килергә кушуы турында хәбәр ителгән сискәндергеч телеграмма алгач, аны тормышының иң катлаулы мизгелләре белән бәйле авыр уйлар баса, кайчандыр искиткеч йомшак күңелле улының таш йөрәккә әйләнеп үзгәрүе өчен бәгыре өзгәләнә, ул төшенкелеккә бирелә. «Тәфкилдән аермалы буларак, табигатьнең гөнаһсыз җан ияләре мәче белән кәҗә үзләрен ашатып-эчерткән әбигә тугрылык саклый һәм шуның белән пьесадагы контрастлыкны тагы да тирәнәйтә» [Закирҗанов, 2004, б. 32]. Ә контрастлык, үз чиратында, рухи ялгызлык кичерүче героиня күңелендәге киеренкелекне тагын да көчәйтә.

Гомумән, Р. Хәмид драмаларында ялгызлык һәм бәхетсезлек мотивлары үзәк урынны алып тора, һәм ул персонажларның шәхси тормышларында да, мәхәббәтләрендә дә үзәк өзгеч булып күзәтелә. Әдип пьесаларында персонажлар, аеруча хатын-кызлар, барысы да диярлек мәхәббәттә сынала, һәм аларның күңел дөньясы да шушы

хискә бәйле рәвештә ачыла; персонажлар күңелендә мәхәббәт газапларыннан туган каршылыклы уйлар һәм хисләр көрәше шәхеснең рухи фаҗигасен барлыкка китерүче төп сәбәпләрнең берсенә әверелә. Сугыш афәте нәтиҗәләре үзенчәлекле гәүдәләнеш алган «Диде кардәш» (1985) драмасы – моның ачык мисалы. Пьесада «вакыт – таләпчән һәм зирәк хөкемдар» [Храпченко, 1977, б. 388] сыйфатында характерны сынаучы әһәмиятле, киеренке этапны билгели. Бу – персонажларның очрашу, аралашу һәм аерылышу вакыты. Әсәрдән аңлашылганча, горур табигатьле, гадел, намуслы Фәүзия ирен сугышта югалта. Шулай да ул, аңа тугрылык саклап, кайтырына өметләнеп, көтеп яши. Ире Минзаһит үзе дә шушы авылныкы. Сугышка киткәндә, ирнең әнисе Фәүзия тәрбиясендә кала... Минзаһит, сугышта каты яраланып хәтерен югалту сәбәпле, әнисен дә, хатыны белән баласы барлыгын да оныта. Аны үлемнән алып калган марҗа кызы исемен, милләтен, үткәнен хәтерләмәүче бу кешегә Николай дип эндәшә башлый. Савыккач, ул шул кызга өйләнә. Шактый еллардан соң, ниһаять, әнисен исенә төшергәч, ир хат яза, тик әнисе аның хатын да, үзен дә күрә алмый дөнья куйган була. Минзаһит-Николай якыннарын, авылдашларын күрү теләге белән туган нигезенә кайтып төшә...

Фәүзия аларны – хатыны Оксана белән икесен дә җылы каршы ала, зурлап кунак итә. Үзе исә, дулкынлануын кеше күзеннән көчхәл белән яшереп, ут йотып, никахлы иренең аларны исенә төшерүен көтә. Акыллы, зирәк хатын буларак, турыдан-туры «мин – синең хатының, син – минем ирем» дип ярып салмый. Ирнең үзенең барысын да исенә төшерүен тели. Моңа атаның заманында үз куллары белән ясаган бизәкле бишеге, үзе язган истәлекле язуы ярдәм итәр дип өметләнә, тик көткән нәтиҗә булмый... Күпме тырышып та бернәрсәне дә исенә төшерә алмагач, Минзаһит авылдан китәргә карар кыла. Фәүзия чарасызлыктан ни эшләргә дә белми. Ул дөреслекнең үз ягында икәнен тойса да, дөресен әйтергә дә, әйтмәскә дә белми шактый газап чигә; иренең гаепле түгеллеген дә аңлый, тик аның хәзерге халәте белән дә килешәсе килми. Шул рәвешчә эмоциональ тетрәнү кичергән хатынның акылы белән йөрәге, хисләре арасында көрәш башлана. Әлеге көрәшнең психологик сурәтләнешендә героиняның каршылыклы эчке дөньясы, рухи газаплары ачык күзаллана. Әдәби әсәрдә персонажның үз уйлары, намусы белән эчке көрәше психологик конфликт төшенчәсе белән аңлатыла.

Кешенең тормыштагы урыны аның рухи сыйфатлары белән бәяләнә. Фәүзиянең кадерле кешесен кабат югалту, алай гына да түгел, бөтенләйгә югалту уеннан бәгыре телгәләнсә дә, ул хисләрен йөгәнләргә үзендә көч таба. Хис-кичерешләрен, дулкынлануын тышкы ваемсызлык артына яшерә. Бу шулай ук – психологизм тудыру чарасы. Гадәттә, психологик конфликтта персонаж холкына хас уңай сыйфатлар калку ачыла. Биредә дә шундый күренешкә тап булабыз: никадәр генә авыр булса да, ачы күз яшьләре йөрәген күпме генә яндырса да, Фәүзия, үз бәхетен генә кайгыртып, кеше күңелен җәрәхәт-

ләүгә, аның гаиләсен җимерүгә бармый. Киресенчә, яраткан кешесе, үзенең керсез намусы хакына ул дөреслекне яшереп калырга, рухи фаҗигасы белән килешергә мәҗбүр була. Психологик сынауны лаеклы узган героиня шул рәвешчә рухи үсеш кичерә.

«Кайтыр идем» (1982) пьесасында да сагышлы да, үкенечле дә булган мәхәббәт драмасына юлыгабыз. Әсәрдән күренгәнчә, Сәлимә белән Мотыйкның, рухи газаплар кичереп, күп еллар дәвамында яшерен генә бер-берсен сөюе яшьләрнең каршылыгына очрый. Әлеге каршылык аталар һәм балалар конфликты төсен ала. Гаиләсе булса да, Мотыйк Сәлимәне сөя, хатынның да аңа карата хисләре бар. Сәлимәнең кызы Ирада аларның үзара мөнәсәбәтен сизә һәм моңа бик гарьләнә. Мотыйкка ул «әни янында сасы козгын кебек иснәнеп йөрисең» дип кычкыра. Алар турында имеш-мимешләр дә тарала башлаганга, кыз барысын да күңеленә якын ала.

Балалар хакына дип, аларның күңелләрен рәнҗетмик дип, Сәлимә белән Мотыйк, бергә кавышып, үз бәхетләрен булдыра алмаганнар. Өлкәннәрнең күңел халәте, эчке кичерешләре, теге яки бу хәлләргә инде күптән аек акыл белән дөрес бәя бирә алырлык кешенең уйларында – Сәлимәнең улы Зирәкнең монолог-хатирәсендә гәүдәләнә. Анда ир белән хатын күңелендәге йөрәк хисе һәм акыл көче арасында гомер буе көрәш барганлыгы аңлашыла. Зирәкнең алар белән алып барган «шартлы» диалогында сөюләрен күп еллар кеше күзеннән яшереп саклый алырлык нык ихтыяр көченә ия әнисенә һәм Мотыйк абыйсына тирән хөрмәте күренә.

Берсенә дә бәхет китерми бу мәхәббәт. Сәлимә ире үлеп тол калгач, Мотыйгулла аңа тормыш йөген бергә тартырга тәкъдим иткән була, ләкин акыллы, намуслы ана, ул вакытта бишенче класста укыган олы улы Зирәк белән киңәшләшмичә, бу тәкъдимне кабул итүне гөнаһ саный. Иң элек аны бу мәсьәләдә балаларының фикере кызыксындыра. «Безгә беркем дә кирәкми», – дип кырт кисә шул вакыт Зирәк. Сәлимә, балаларының үз аталарын башка кешегә алмаштырырга теләмәүләрен аңлап, үз язмышы белән килешергә була. Балалар хакын хаклау, алар сүзенә колак салу ананың кешелеклелеген, олы җанлылыгын күрсәтә.

«Майның унбишләрендә» (1983–1984) пьесасында Зәримә белән аның кызы Гүзәл образлары да психологик төгәллек белән ачыла. Зәримә – яшьлегендә Варис картның өлкән улы Закуаннан алданган бәхетсез җан. Закуанның энесе Мәгавига кияүгә ул үзен алдаган егеткә үч итеп кенә чыга... Әсәрдән аңлашылганча, авылда гомер иткән акыллы, төпле Варис карт, авылның киләчәген саклап калу максаты белән, шәһәрдә җаваплы эштә эшләүче улы Закуанны туган нигезенә кайтарырга тели. Улы шәһәрдә абруйлы, хөрмәтле кеше саналганга күрә, авылны саклый алыр, аңа тидертмәс дип өметләнә. Шуны күздә тотып, олы улы өчен бик матур йорт торгыза. Шулай да Зәримә белән бер авылда тора калсалар, элеккеге хисләре яңарып, кабат очраша башлауларыннан курыккан карт кече улы белән килененең колхоз үзәгенә күченеп

китүләрен теле, әмма хатын карыша. «Персонажның сөйләме персонажның психикасына ишек ача» [Айзикович, 1965, б. 13]. Зәриmәнең Варис картка ярсып әйткән сүзләрендә аны кайчандыр хурлыкка калдырып шәһәргә качкан Закуанга көчле нәфрәте, шушы ачы хистән туган рухи фаҗигасе гәүдәләнә. «Закуанның авылга кайтырга хакы юк» дигән сүзләрендә хатын күңелендә аңа карата әле дә үпкә, ачу, рәнҗеш хисләренең бетмәве, үч алу теләгенең үз көчендә булуы сизелә.

Зәриmәнең кызы Гүзәл дә әнисе белән әтисе язмышына битараф түгел. Закуан абыйлары кайткач булырга мөмкин фаҗиганы күзаллап, сабыйның йөрәге әрни. Бала гына дип карасалар да, ул инде күп нәрсәне аңлый алырлык кыз булып үсеп җиткән. Әнисен бәхетсез иткән Закуан абыйсын күралмый ул. Аның авылга кайтуын теләми.

Шулай да Закуан кайту хөрмәтенә өстәл әзерләнә. Яман чир белән авырып ятучы Варис карттан кала, барысы да өстәл артына җыелыша. Бер-берсенә сиздерергә теләмәсәләр дә, әңгәмә барышында рухи киеренкелек атмосферасы күзәтелә. А. Караганов болай дип яза: «Чын драматург пьесага чәй эчү күренешен китереп кертә икән, ул моны көндәлек тормышны күрсәтү өчен генә эшләми дип, ышанып әйтергә мөмкин: чәй артында сөйләшү никадәр генә тыныч узса да, анда, яралгы хәлендә генә булса да, пьесаның драматургиясен барлыкка китерүче драматургик киеренкелек, көрәш сизелеп тора» [Караганов, 1959, б. 155].

Коймаклар пешереп, бераз тоткарланган Зәримә килеп кергәч, әлеге киеренкелек тагын да көчәя. Шулай да берни булмагандай кыланып, авыл хәлләре турында сүз куертып утыручы өлкәннәрне Гүзәл аңламый да, өнәми дә. Аларның ясалма сөйләшеп утыруларын ахмаклыкка саный. Үзе дә алар янында, бигрәк тә Җир йөзендәге иң сөймәгән кешесе – Закуан абыйсы янында утырырга теләми. Кызның горур йөрәге икейөзлелекне, гаделсезлекне күтәрә алмый. Аның күңелендә өлкәннәрнең үз-үзләрен тотышына мөнәсәбәтле эчке каршылык көчәйгәннән-көчәя бара. Кызның, әдәплелек саклаган булып, күңелендәге үпкә-ачу хисләрен сиздерергә кыймаган әтисенә дә, Закуан абыйсы өчен ясанып-киенеп кергән әнисенә дә һәм, бигрәк тә, һәр сүзендә ваемсызлык сизелеп торган Закуан абыйсына ачуы торган саен кабара. Ул яшүсмерләргә хас беркатлылык, ярсулык, кызулык белән өлкәннәргә үзенең нәфрәтен белдерә.

Зәриmәнең Закуан янына, кызы сүзләре белән әйтсәк, «свиданиегә әзерләнгән кебек ясанып керүе» – хатынның кимсетелгәнлек хисен тышкы матурлыгы белән капларга омтылуы гына ул. Аның тыштан үзен тыныч тотуы ир калдырган йөрәк ярасын сиздермәскә тырышудан килә. Әлеге тышкы ваемсыз тынычлыгы артында хатынның әрнүле хисләрдән, гарьлектән, рухи газаплардан туган эчке көрәше сизелә. Закуанга нәфрәте шушы көрәшнең чагылышы булып тора.

Психологик конфликт характерлар бәрелешенә китерә. Әлеге бәрелеш, аталар һәм балалар конфликтына әверелеп, әсәрнең драматизмын көчәйтә. Кызының Закуанга: «Мин сезнең белән сөйләшергә

дә теләмим! Куралмыйм мин сезне!» [Хәмид, 1989, б. 55] – дип, ярсып әйткән сүзләре Зәримәгә гомер буе йөрәк ярасы булып килгән ачы хакыйкатьне фаш итү җаен тудыра. «Ул синең әтиең, Гүзәл кызым» [Хәмид, 1989, б. 55], – ди хатын. Бу сүзләр горур табигатьле кызга бик авыр тәэсир итә, күңелен рәнҗетә. Аның өйдән чыгып йөгерүе эчке кичерешләренең тирәнлеген, чиктән тыш киеренкелеген раслый. Күрәбез: персонажлар диалогында, кылган гамәлләрендә аларның хис-кичерешләре, киеренке мөнәсәбәтләр, эчке көрәштән туган рухи драматизмнар чагылыш таба. Шул рәвешчә, рухи халәтнең персонажларның әйткән сүзләре, эш-гамәлләре аркылы бер-берсенә мөнәсәбәте рәвешендә тышкы чагылышы психологик характеристиканың бер күренеше булып тора.

Символик образлар, детальләр – психологизмның үтемле чаралары. Р. Хәмид драматургиясендә заман билгеләре, шәхеснең рухи дөньясы, характеры, дөньяга карашы шәхес һәм аның йорты белән үзара бәйләнештә ачыла. Йортлар эчендәге төрле хәлләр социаль-иҗтимагый тормыш күренешләре булып күзаллана. Драмаларда сурәтләнгән йортларга бәйле рәвештә автор кешене борчыган, аның яшәү чыганагы булган күп кенә актуаль проблемаларны яктырта. Мәсәлән, «Олы юлның тузаны» пьесасында халкыбызның гасырлар буе сакланып килгән рухи матурлыгы персонаж һәм, әсәрдә искәртелгәнчә, ул «гомер бакый көн иткән йорт», шушы йорттагы әйберләр бәйләнешендә бирелә. Монодрамада йорт әйберләре сюжетны төзүче әһәмиятле элементлар да булып торалар, чөнки Нәүхәбәр әби өендә һәрбер йорт деталенә бәйле берәр якты истәлек сакланып калган. Шул истәлекле хәлләргә мөнәсәбәтле сюжет корыла һәм Нәүхәбәр әби узган олы бер тормыш юлы күзаллана. Өй эчендәге әйбер-детальләр йорт хуҗасының рухи дөньясын ачарга, эчке кичерешләрен, ягъни психологик халәтен бирергә ярдәм итәләр. Нәүхәбәр карчык йорты – аның яшәү рәвешен чагылдырган истәлекләргә бай тарихи хәтер. Ул дөньядан китү белән, хәтер дә юкка чыгачак. Туган туфракны, гореф-гадәтләрне, йола-традицияләрне символлаштыручы әлеге «Йорт»ка хәзер шул яный кебек. «Майның унбишләрендә» драмасында ата-бабалардан мирас булып калган балта һөнәрен үзләштергән һәм эшен бик яхшы белүче Варис картның үзе салган йортына да игътибар итик. «Беләсеңме, без синең белән, улым, нәрсә төзедек? – ди карт оныгына. – Йорт салмадык без – җиһан кордык! Түбәгә игътибар иттеңме? Бөдрә түбә дип атала ул. Авылда башка андый түбә юк. Чөнки түбә түгел ул – күк гөмбәзе! Йолдызлар да, ай да, кояш та, киек каз юлы да бар анда. Гади бизәкләр генә түгел алар. Ә тәрәзә капкачындагы тамгалар – Чулпан йолдызы билгесе. Балаларга бәхет китерә ул» [Хәмид, 1989, б. 37]. Күрәбез: Варис карт күңел җылысын салып эшләгән бу йортны. Ул салган йорт аның үз йөзен дә ача. Йолдыз, ай, кояш, киек каз юлы, – дөрестән дә, гади бизәкләр генә түгел болар, ә халкыбызның күңел бизәкләре. «Балаларга бәхет китерүче» Чулпан йолдызы – өлкән буынның юлын дәвам итүче яшьләрнең бәхетле киләчәге

дигәнгә ишарә. Картның «Йорт салмадык без – җиһан кордык» дигән сүзләрендә тирән иҗтимагый мәгънә ята. Димәк, йорт ул – олы бер җиһан; Варис карт хыялында йөрткән, үзенең милли йөзен саклаган, кешеләргә бәхет кенә китерүче авылның киләчәге, гомумән, кешеләрнең бәхетле киләчәге. Йортның күз явын алырлык бизәлеше – картның матур киләчәк турындагы якты хыяллары да ул, ләкин әлеге хыялларга тормышка ашарга язмаган... Олы улының үзенә дип салынган шушы йортка кайтырга теләмәве, бетүгә таба йөз тоткан авылның киләчәгенә битарафлык күрсәтүе, алай гына да түгел, туганнарның үзара тавыш-гауга чыгаруы Варис картның бөтен өмет-хыялларын җимерә. Күңелендәге каршылыклар көрәшеннән туган чарасызлык хисе аны җитди адымга этәрә: соңгы сулышына кадәр бар көчен биреп, йөрәк җылысын кушып салган йортны карт үзе үк ут төртеп яндыра. Йортның януы, балта остасының үлеме трагик мәгънәгә ия. Бу күренеш авылның киләчәгенә инкыйраз янау, шуның белән бергә халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре дә юкка чыгу кебек аңлашыла.

«Пыяла кыз» (1979) пьесасында яраткан кешесенең башка берәү белән никахын үз куллары белән теркәргә мәҗбүр булган ЗАГС хезмәткәре Тәнзиләнең психологик халәте, драматизм тулы эчке дөньясы кызның никах теркәү журналы урынына ялгыш үлем теркәү журналын чыгаруы детале аркылы гәүдәләнә. Әлеге күренештә тирән мәгънә яшеренгән: җаныңа береккән кадерле кешеңне, каерып алып, чит кулларга бирү – үлемгә, аның башка берәү белән никахын теркәү үлемен теркәүгә тиң булуны аңлата.

«Каен җиле» (1980), «Китәм инде» (1980) пьесаларында персонажлар күңелендәге хис-кичерешләр психологизмның бер чагылышы булган табигать күренеше белән бәйле янәшәлек, ягъни психологик параллелизм алымы ярдәмендә тормышка ашырыла. «Каен җиле» драмасында Гөлбану күңелендәге көчле сагыш хисе каен образы аркылы гәүдәләндерелә, әлеге символик образ тирән психологик мәгънәгә ия: ялгызлык сагышыннан йөрәге өзгәләнгән ана үзе кебек үк ялгыз каенга сарылып көн дә улын көтә. Каен янында озаклап сүзсез басып торуы, еш кына беркем белән дә сөйләшми йөрүе аның әкрен генә эчтән сызуын, шул рәвешчә рухи фаҗигасының тирәнлеген ассызыклый. В.А. Мамонтов билгеләп үткәнчә, «тормышының иң фаҗигалы мизгелләрендә кеше сөйләшүдән, аралашудан ваз кичә» [Мамонтов, 1965, б. 8]. Югыйсә, пьесада алай күзгә бәрелеп торган конфликт юк та шикелле, әмма бу беренче карашка гына шулай. Әсәрнең төп һәм хәлиткеч конфликтын ата-ананың изге теләкләре белән алардан газиз балаларын тартып алган яңа җәмгыятьнең рәхимсез принциплары арасындагы көрәш тәшкил итә. Бу конфликт пьесада, көтеп-көтеп тә улы кайтмагач, ананың ул утыртып калдырган, ничә еллар аның истәлеге итеп үстергән каен агачын чабып аударуы аша җәмгыятькә тугры хезмәт итүче баласы белән күңелендә барган эчке көрәше сыйфатында бирелә. Пьесада пейзаж элементы – драматизмны көчәйтүче күренеш. Бөтен тирә-якны яңгыратып ауган каен төбендә бәхетсез ана үзе

дә йөрәге ярылып үлә. Үләр алдыннан каен агачын чабып аударып, ана кеше тормышында иң изге, иң якын кешеләрен рәхимсез җәмгыять принципларына алыштырган улыннан ваз кичүен белдерә. Мәгълүм булганча, персонажларның кылган гамәлләре аркылы аларның рухи халәтләре, эчке кичерешләре гәүдәләндерелә. Ананың коточкыч гамәле күңелендәге хис-кичерешләрнең, рухи фаҗигасының тирәнлеген ассызыклый. «Китәм инде» драмасында Зәримәнең, сөйгән егетенең гомере кыска булуын сизенепме, үзе дә аңламастан, нәрсә өчендер борчылуы, шомлануы, якынлашып килүче ниндидер зур бәхетсезлекне тоеп өзгәләнүе бер үк вакытта аның өчен әйләнә-тирәнең «кинәт караңгыланып киткән кебек булуы» [Хәмид, 1980, б. 27] белән тәңгәлләшә. «Дәһшәтле яшенле яңгыр алдыннан шулай куркыныч була!» [Хәмид, 1980, б. 27] – ди кыз, ягъни пейзаж да персонажның психологик халәтен яктыртуга хезмәт итә. Күрәбез: героиняның психологик кичерешләре белән табигать күренешләре арасындагы янәшәлек, бер-берсен тулыландырып, трагизмны көчәйтә.

«Ике сәгать – бер гомер» (1984) драмасы – әдипнең «кеше күңеленең нечкә җепләреннән драматизм үрү сәләтен» [Әхмәдуллин, 2007, б. 123] гәүдәләндергән уңышлы әсәрләреннән тагын берсе. Пьеса сюжет үзгәлеге белән аерылып тора. Биредә сугыш темасы психологик призма аша бирелә. Әсәрдә 1942 елның башында Волхов тирәсендә немецлар тылында барган вакыйга яктыртыла. Татар авылыннан чыккан совет солдаты немец офицерын кулга төшерә. Немец егете ирнең үз улы булып чыга... Драматург сугыш тудырган дошманлык хисенең никадәр явыз көч булуын ата белән бала образы, алар мөнәсәбәте аша бирә. Бу хиснең, хәтта туганлык хисләрен дә аямыйча, иң газизләр арасында да бер-берсенә карата нәфрәт хисе уятырга мөмкинлеген ассызыклый. Шул ук вакытта туганлык җепләренең ныклыгын да раслый. Мондый каршылыклы күренеш әсәрнең психологизмын көчәйтә. Бер-берсенә капма-каршы позициядә торган ата белән улны очраштырып, автор икесен дә кискен сынау астына куя: аларның кайсы да булса, кемнең дә булса кулыннан шәһит китәргә мөмкин, чөнки тиздән алар очрашкан алачыкка Кызыл Армия гаскәрләре килеп җитәчәк, шулай ук яшерен каравыл группасы командиры Фридның юкка чыгуы исә немец солдатлары арасында гауга куптарачак. Димәк, аны да эзләп чыгачаклар. Ата да, егет тә үз илләренә, үз халкына тугрылыклы... Ата белән ул күңелендә бурыч хисе белән туганлык хисе арасындагы рухи конфликт психологик киеренкелекне тагын да көчәйтә. Персонажлар күңелендә Ватанга тугрылык һәм туганлык, якынлык хисләре арасында барган көрәш психологик киртә барлыкка китерә. Соңгы сулышларына кадәр ата да, ул да намусларына хыянәт итми. Шул ук вакытта икесе дә бер-берсенең тормышы өчен ахыргача көрәшә. Ата Ватанга тугрылыгын, бала атага тугрылыгын җиргә тамган кызыл каннары белән аклый. Әлеге күренеш аркылы драматург туган илгә мәхәббәт хисе белән ата һәм бала арасындагы туганлык, якынлык хисләренең бер үк дәрәҗәдә көчле булуына басым ясый.

Эчке гармонияне җимерүче тышкы сәбәпләр: социаль-иҗтимагый тормыштагы катлаулы, четерекле үзгәрешләр, кешеләр арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр һ.б. – рухи драматизмны тудыручы алшартларның иң көчлесе. Шулар тәэсирендә өмет-хыялларның җимерелүе «эмоцияләрнең драматик чишелеше»нә [Хатипов, 1981, б. 23] китерә. Әдипнең әсәрләрендә персонажларның кискен, кайвакыт хәтта коточкыч дәрәҗәдә куркыныч гамәлләре, тышкы «ярсыткычлар»га эмоциональ «җавап»лары буларак, шуны раслый һәм рухи фаҗиганың тирәнлеген, эмоцияләрнең иң югары ноктага җитүен ассызыклый. Әйтик, «Китәм инде» пьесасында кайчандыр җан дуслар булып та, колхозлашу елларында юллары аерылган күршеләренең мөнәсәбәте, әнисенең аларны – сеңлесе белән икесен дә әби-бабасы тәрбиясенә калдырып китүе Инзар күңелен яралый, шулай ук шушы картлар өстенә төшкән замана авырлыклары, чор кырыслыгы, сөйгәненнән кире кагылу да эзсез кала алмый: аны явызландыра, рухи ярлыландыра, әхлакый сыйфатларын җимерә. Ул күршеләре Нурәхмәтне, аның улы Гамирны күралмый. Соңгысының барысы да яхшы булуыннан көнләшә. Үзенең бар уңышсызлыкларын, бәхетсезлеген, хыялларының тормышка ашмавын алардан һәм әйләнә-тирәдәгеләрдән күрә. Шул сукыр ачу аны соңгы чиктә җинаятьче дәрәҗәсенә китереп җиткерә. Күршесенә өрмәгән өчен генә этне атып үтерүе, авылның күрке саналган Ташурда кыясына барельеф ясап яткан Гамирга үч итеп, кыяны шартлатуы (шул рәвешчә егетнең гомере өзелү) Инзарның рухи гариплеген күрсәтә. Егетнең кылган һәр гамәлендә рәнҗеш тулы эчке дөньясы чагылыш таба. «Кайтыр идем» пьесасында бер аягына аксый төшкән Ирада, үзенең физик кимчелегеннән, яраткан егетенең читләшүеннән, әнисе белән Мотыйк абыйсының мөнәсәбәтләреннән хурланып, келәттә асылынырга тели. Бу аның чынбарлыкка, гаделсезлекләргә үзенчә каршылык күрсәтүе, ризасызлык белдерүе булып аңлашыла һәм кичерешләренең тирәнлеген раслый. «Пыяла кыз» драмасында Сәлимәнең кече улы Камил, әнисенең керсез намусын гайбәт сүзләрдән саклыйм дип, аның сөйгән кешесен кыядан ташлый һәм гомерен өзә. Әлеге рәхимсез гамәле белән ул әнисенең болай да бәхетсез тормышын бөтенләй җимерә. «Олы юлның тузаны» пьесасында үз көнен үзе күреп, булганына шөкер итеп яшәп ятучы Нәүхәбәр әби дә көтмәгәндә өен сатып алырга килүчеләргә каршы кулына мылтык алырга мәҗбүр була. Алда карап үтелгән пьесаларда да («Майның унбишләрендә», «Каен җиле») өлкән буынның, яшьләрнең – балаларының битарафлыгына юлыгып өметләре киселү аркасында, көтелмәгән гамәлләр кылуын күрдек.

Әдип драмаларында персонажларның күңел халәте, язмышлары төш образы аркылы да гәүдәләнә. Әйтик, «Майның унбишләрендә» пьесасында Варис картның оныгы Гүзәл булачак фаҗиганы төшендә күрә: «Соңгы вакытта төн саен бер үк төш күрәм мин: бөтен тирә-ягымны ут чолгап ала, имеш! Бөтен дөньяны ут баса! Ә каршымда кемнеңдер ачык кабере тора!» [Хәмид, 1989, б. 44]. Закуан абыйсының улы Айдарның фаҗигага юлыгып телдән язасын да төшендә күргән

була кыз. «Китәм инде» пьесасында Гамирны авылларындагы бердәнбер мәһабәт кыяга барельеф ясау хыялын гамәлгә ашыру омтылышына исә бала вакытында күргән төше этәрә, әмма егетнең язмышы шул төшендә күргән «хәрабәләр, борынгы сарай калдыклары» хәлендәрәк хәл ителә: Ташурда кыясы шартлап, егетнең гомере өзелә, шул рәвешчә аның хыяллары тормышка ашмый кала. Р. Хәмид персонажларына күрәзәлек сыйфаты да ят түгел, алар якыннары белән булачак күңелсезлекләрне, бәхетсезлекләрне алдан сизенәләр һәм еш кына эчке дулкынлану, курку хисе кичерәләр. Әсәрләрдә күзгә ташланган плеоназм күренеше аша да персонажның әхлакый-психологик халәте, хис-кичерешләре ачык тоемлана. Әдәби әсәрдә плеоназм «язучы яки персонаж өчен бик мөһим сүз-гыйбарәләрне аерып куя, характер тудыру, психологизм бирү чарасына әверелә» [Әдәбият белеме.., 2007, б. 179]. Әйтик «Китәм инде» пьесасында авыл кыясында барельеф ясап ятучы сөйгән егетенең язмышы өчен борчылган Зәримәнең егет билендәге бауның ныклыгы турында кабат-кабат соравы – шуның ачык мисалы. Кызның һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә борчылуы, күңел тынычсызлыгы, аны югалту куркынычыннан өзгәләнүе сизелә.

Җыр психологик сурәтнең шулай ук үзенчәлекле һәм мөһим бер формасы булып тора. Р. Хәмиднең сәхнә әсәрләрендә урын алган «Нардуган» («Олы юлның тузаны»), «Герман сугышы» («Ике сәгать – бер гомер»), «Әллүки» («Диде кардәш...») һ.б. җырлар «аерым кешеләр язмышы аркылы җәмгыятьнең социаль торышын, рухи-әхлакый йөзен, халыкның моң-зары, теләк-омтылышлары, тирән кичерешләре белән бергә аның тормыш тәҗрибәсен, зирәк акылын, саф хисләрен дә чагылдыралар» [Каюмова, 2018, б. 243].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Р. Хәмид драмаларында кеше язмышлары, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, рухи дөньялары аша заман билгеләре, чор үзенчәлекләре ачык күзаллана һәм, киресенчә, социаль-иҗтимагый үзгәрешләрнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең инсан табигатенә, аның эчке дөньясына йогынтысы гәүдәләндерелә. Югарыда анализланган сәхнә әсәрләрендә персонажлар рухи дөньясының үсеш-үзгәрештә бирелүе, бертөрле хис-кичерешләр һәм уй-фикерләрдән башкалары формалашу, бер күңел халәтеннән икенчесенә күчү, шуңа илтүче сәбәпләр, күңел каршылыгын үстерү юллары ачык күрсәтелә. Бу исә әдәби образларның психологик портретын тулы күзаллау мөмкинлеге бирә һәм әдипнең кеше психологиясен нечкә тоемлаучы сизгер психолог булуынраслый. Р. Хәмиднең үз әсәрләрендә, төрле характерларның күңел хәрәкәтен нечкә тоемлап, укучы игътибарына дөрес һәм үтемле итеп җиткерү осталыгы психологик тирәнлеккә омтылу күренеше белән аңлатыла, һәм бу үз чиратында әдәби әсәрнең рухи-әхлакый кыйммәтен, тәэсир итү көчен, «эстетик энергиясен» (Ф. Хатипов) бермә-бер арттыра.

**Әдәбият**

*Айзикович Я.Г.* Стилистическое мастерство А.М. Горького-драматурга: автореф. дис. … канд. филол. наук. Баку: Азерб. гос. ун-т. им. С.М. Кирова, 1965. 24 с.

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

*Әхмәдуллин А.Г.* Яңарыш чорында татар драматургиясе (тематик төрлелек һәм жанрлар үсеше) // Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: монография. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 95–217.

*Есин А.* Психологизм русской классической литературы: кн. для учителя. М.: Просвещение, 1988. 176 с.

Жанрово-стилевые искания и литературный процесс: Темат. сб. науч. тр. / Редкол. Х. А. Адибаев (отв. ред.) и др. Алма-Ата: КазПИ им. Абая, 1988. 90 с.

*Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 175 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Драматургның сурәтле дөньясы (Ризван Хәмид) // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 104–118.

*Караганов А.* Характеры и обстоятельства: сб. ст. М.: Сов. писатель, 1959. 398 с.

*Каюмова Г.И.* Ризван Хәмид драмаларында җырның идея-эстетик хасияте // Актуальные проблемы регионоведения и науковедения: сборник статей научной конференции / под ред. И.А. Гилязова, М.З. Хабибуллина. Казань: ИТЭР АН РТ, 2018. Б. 223–230.

*Мамонтов В.А.* Драматургия А.Н. Арбузова: автореф. дис. … канд. филол. наук. М., 1965. 20 с.

*Хәмид Р.* Ике сәгать – бер гомер: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 89–110.

*Хәмид Р.* Каен җиле: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 50–88.

*Хәмид Р.* Китәм инде: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 3–49.

*Хәмид Р.* Диде кардәш...: ике бүлекле драма // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 73–108.

*Хәмид Р.* Майның унбишләрендә: ике бүлекле драма // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 32–72.

*Хәмид Р.* Олы юлның тузаны: ике бүлекле драматик хикәя // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 3–31.

*Хәмид Р.* Пыяла кыз: өч бүлекле драматик повесть // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 154–189.

*Хәмид Р.* Кайтыр идем: өч бүлекле лирик драма // Китәм инде: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 5–47.

*Хализев В.Е.* Сознание и самосознание персонажа. Психологизм // Теория литературы: учебник 3-е изд., испр. и доп. М.: Высшая школа, 2002. С. 209–220.

*Хатипов Ф.М.* Күңел дөньясы // Метод, стиль, жанр / фәнни ред. Н. Юзиев, Ф. Мусин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Б. 177–189.

*Хатипов Ф.М.* Духовный мир героя: Психологизм в современной татарской прозе. Казань: Таткнигоиздат., 1981. 296 с.

*Хатипов Ф.М.* Әдәби әсәрнең эстетик энергиясе: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 287 б.

*Храпченко М.Б.* Творческая индивидуальность писателя и развитие литературы. Изд. IV. М.: Художественная литература, 1977. 446 с.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 2-43

*Э.К. Сәлахова*

# МИҢЛЕБАЙ АВЫЛЫ МУЛЛАСЫ ГЫЙЛЬМАН ХӘЗРӘТНЕҢ МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ (1870–1900 еллар)

Статья посвящена духовной истории деревни Миннебаево. Благодаря деятельности знаменитого религиозного деятеля Гильмана Ибрагимова (Карими) Миннебаево становится одним из центров образованности. В публикации автора показана роль и вклад Г. Карими в развитие духовной культуры и образования в Бугульминском уезде. Также рассматривается история мечетей Миннебаево и дается информация о духовных деятелях, служивших в приходе Миннебаево.

**Ключевые слова:** история населенных пунктов, история Миннебаево, история татарского народа, краеведение, образование, медресе, шакирды.

The article is devoted to the spiritual history of Minnibaevo village. Through the activities of the famous religious leader Gilman Ibragimov (Karimi) Minnibaevo became one of the centers of education. The author’s publication shows G. Karimi’s role and contribution in the development of spiritual culture and education in Bugulma County. The history of Minnebayevo mosques is also considered, and information about the spiritual figures who served in the parish of Minnebayevo is given.

**Keywords:** history of settlements, history of Minnibaevo, history of the tatar people, local history, education, madrassas, shakirds.

Әлмәт төбәге XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар рухи тормышы үсешендә аерым урын тоткан. Бу яктагы күп кенә татар авылларының тарихы XVIII йөздән башлана. Бу – татар җәмгыятенең авыр, караңгы чоры. Көчләп чукындыру, иманнан яздыру белән бергә көндәлек тормыштагы авырлыкларны җиңү, көн күрү юлларын эзләгән чорда аерым нәселләр бу якларга килеп төпләнә. Авылларга нигез салына.

Миңлебай авылының да нигезләнү вакыты XVIII йөзнең беренче чирегенә карый [Населенные пункты, б. 52]. Гадәти көндәлек мәшәкатьләр белән яшәүче Миңлебай халкының тормышын Гыйльман хәзрәт үзгәртеп җибәрә. Аның имамлыкка билгеләнүе, 30 ел Миңлебай авылында яшәве, мәгърифәтчел хезмәте Миңлебайны бай рухи тормышлы авыллар рәтенә күтәрә, тарихлы итә.

Гыйльман бине Ибраһим бине Йумәт бине Габделкәрим бине Габделмөмин (1841–1902) тумышы белән шул төбәкнең Түбән Чыршылы авылыннан [Фәхреддин, б. 272–273]. Түбән Чыршылының атаклы мәдрәсәсендә остазы Габделфәттах Габделкаюм улында укыганнан соң, Чистайда танылган мөдәррис һәм дин эшлеклесе Закир Габделваһһаб улы мәдрәсәсендә гыйлем эсти. 1867 елда, укуын тәмамлап, Кичүчат авылы имамы Фәхреддин Сәйфеддин улының олы кызы Мәгъсүмә абыстай белән гаилә корып җибәрә. Мәгъсүмә

абыстай – Ризаэддин Фәхреддиннең бертуган апасы. Гыйльман хәзрәт озакламый Миңлебай авылы имамы итеп билгеләнә. Имам-хатыйп дәрәҗәсенә лаек булу турындагы шәһадәтнамәне 1869 елның 8 маенда Диния назәрәтендә имтихан биреп ала [СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 3068 эш, 89 б–90 кгз.]. Истәлекләрендә ул мулла итеп билгеләнү турындагы губерна идарәсе карары («указ») 1870 елның 9 маенда язылган дип күрсәтә. Аның Миңлебай авылына имам булып килүе, бу авылны сайлавы да очраклы түгел, Миңлебай – Гыйльман хәзрәтнең әнисе – Фатыйма Рәхмәтулла кызының туган авылы. Монда имамлыкка килгәндә хәзрәткә 25 яшь була. Каенэнесе Ризаэддин Фәхреддин истәлекләрендә: «җизни Миңлебай авылына имамлык эшләре белән йөргәч, бу елны мине анардан башка Чистай мәдрәсәсенә җибәрмәделәр», – дип яза [Фәхреддин, б. 15]. Р. Фәхреддин укуын күрше авыл мәдрәсәсендә – Түбән Чыршылыда дәвам итә.

Гыйльман хәзрәт Миңлебайны «бик кечкенә, фәкыйрь һәм бик караңгы авыл иде» [Фатыйх Кәрими, б. 18] дип искә ала. Ул килгәндә авылда бер мәчет эшләгән. Элекке мулла Әхмәджан Мөхәммәдсадыйк улы Әлмәт төбәгенең Кама-Исмәгыйль авылы мәхәлләсенә күчкән. Гыйльман хәзрәт аның урынына җамигъ мәчете имамы буларак килгән. Бу вакытта мәхәлләнең икенче имамы вазифасын (1852 елның 28 мартыннан) Камалетдин Азаматов башкарган.

Миңлебай авылы мәчете нигезләнү датасы рәсми документларда теркәлеп калмаган, җирле халык та мәчет төзелүнең төгәл елын белми. Миңлебай авылы мәчетенең метрика язмалары 1829 елдан башлап сакланган икән, димәк, мәчет инде бу чордан алдарак булган дигән сүз. Гыйльман хәзрәт килгәндә, мәчет инде шактый искергән булу сәбәпле, аңа, иң беренче эш итеп, аның бинасын яңартырга кирәк була. 1877 елда булачак яңа мәчетнең проекты ясала [СӨ ҮДА. 1 ф., 12 тасв., 2794 эш, 1 кгз]. «Мәхәллә әһелләре көче белән матур бер мәчет төзергә ирешсәк тә, Җамалетдин бине Сәгъдетдин исемле мөәзинебезнең чарасызлыгы сәбәбеннән, бер ел эчендә мәчетебез янгын казасына дучар булды», – дип яза Гыйльман хәзрәт. Еллар авыр килүгә карамастан, «ике елдан соң авырлык белән булса да, янә яхшы мәчет бина кылдык», дип искә ала [Фатыйх Кәрими, б. 18]. Бу авырлык белән салынган мәчетнең дә язмышы шулай бетәсен Гыйльман хәзрәт белмәгәндер, мәчет миченең төтен юллары төзек булмау сәбәпле, 1914 елның 6 гыйнварында, янгын чыгып, бу мәчет тә янып бетә. Ул инде бу күңелсез хәлне күрми, соңгы елларын Миңлебайда яшәми, 1902 елда вафат та була. Мәхәллә халкы шул ук елны, яңа мәчет төзетүгә рөхсәт сорап, «приговор» төзи, 1914 елның 6 июнендә проекты раслангач, элекке мәчет урынында яңа бина төзи башлыйлар [СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5540 эш, 10 кгз].

Гыйльман хәзрәт мәчет каршында башлангыч мәктәп ачып, шәкертләр укыту эшен башлап җибәрә. Татар халкында дини уку йортын, нинди зурлыкта булуына да карамастан, мәдрәсә дип атау гадәте бар. Гыйльман хәзрәт ачкан башлангыч дини белем бирә торган

уку йортын – мәктәпне дә авыл халкы мәдрәсә дип атап йөртә. «Һәм дә ошбу авылыбызда кечкенә генә мәдрәсә ачып, уналты ел балалар укыту белән мәшгуль булдым. Бер тарафтан үземнең мохтаҗлыгым, икенче тарафтан шәкертләрнең электән калган тырышсызлыклары, белемсезлекләре, өченчедән, үземнең укыту ысулым һәм балалар тәрбияләү кагыйдәләреннән хәбәрсезлегем аркасында шәкертләрем уку, язу дәрәҗәсеннән артыкка бара алмадылар. Бу хәлне күреп, бик ачынып һәм кыенсынып, мәктәптән һәм балалар укытудан ваз кичтем. Моны бөтенләй ташладым, чөнки үзем дә канәгать түгел идем, балаларның да вакыт вә гомерләре әрәм була, һәммәбезгә зарар гына, дидем». Бу халәт һәр эшенең соңгы нәтиҗәсен күрергә күнеккән, үзгәреш-үсешкә омтылган Гыйльман хәзрәтнең күңелен сызлата, әмма тынгысыз мәгърифәтче болай гына тынычлана торган кеше булмый, уңышсызлыкның сәбәбен эзли. «Мин һәм минем кебекләрнең һәрберсе мондый халәттә булсалар, нәселебез һәм милләт балаларының даими бер золәмәттә калулары ихтимал булганнан күңелем һәм җәберләнеп, күп төрле фикерләргә талып вә хәлебезгә хәйран калып, ни кылырга кирәклеге хакында уйлана башлаган идем» [Фатыйх Кәрими, б. 18].

Гыйльман хәзрәт шул заманның атаклы дин белгече, мөгаллим, кадимче, Чистай мәдрәсәсендәге Закир хәзрәт шәкерте булса да, балаларга белем бирүдә кадимчелек юлы белән баруның уңышка илтмәячәген аңлаган хәлдә, шул заманда җәмгыятькә яңа идея буларак керә башлаган Исмәгыйль Гаспринский карашлары белән таныша, Бакчасарайда чыга башлаган «Тәрҗеман»ны да укый. «Тәрҗеман» безнең өчен дөньяга бер тәрәзә ачучы булды, дип яза ул истәлекләрендә. Әмма шулай булса да, Гыйльман хәзрәт Исмәгыйль бәкнең бар фикере белән дә килешеп бетми, аның белән еш кына бәхәсләшә. «Бәхәсебез бик озакка китте вә мин берничә мәртәбәләр үзенә, элеккечә каты сүзләр илә, хатлар язып, үз фикеремне яклadым. Ниһаять, үзем Бакчасарайга барып, Гаспринский белән күрешеп, һәр икебез максат һәм фикеремезне аермачык, җентекле рәвештә аңлатканнан соң, мәсьәлә хәл ителде, һәр икебезнең максаты шул: бичара һәм белемсез милләтебезнең мәдәният һәм мәгариф юлына кереп, дөньяда, ахирәттә бәхетле булуы, үз фикеремне хасыйл иткән даирәнең бик тарлыгы аңлашылып, шул вакыттан башлап үткән форсатлар өчен үкенеп, һич югы моннан соң, кулдан килгәнчә, уку-укыту юлларын җиңеләйтү вә мәгариф юлына керү өчен тырыша башладым» [Фатыйх Кәрими, б. 19].

Уңышсыз тәҗрибәсеннән соң Гыйльман хәзрәт үзе бүтән укыту эшенә алынмый, әмма ахун буларак, 136 татар авылы мәхәлләсенә җаваплы булганда, җәдиди мәктәпләр ачтыруга бар көчен куя, бар күңелен биреп эшли. Шундый җәдиди мәктәпләрне ул үз авылында да, башка тирә-як авылларда да ачтыра, аларга укыту программаларын эшли, белемле мөгаллимнәр табып, аларны авылга китертүне дә үз өстенә ала. Җәдитчә укуның кирәклеген, киләчәк нәкъ менә

белемдә булачагын гади халыкка аңлату – үзе күп көч һәм сабырлык сорый торган эш икәнен дә исәпкә алсак, мәгърифәтче хәзрәтнең үз өстенә зур һәм изге йөк алуы аңлашыла. Ул җәдиди мәктәпне 1890 елда Миңлебайда ачтыра. Биредә Миңлебай һәм күрше Чупай авылы балалары – барысы 17 шәкерт (шулар арасында уллары Гариф белән Камил дә) белем алган. Бу шәкертләр ике ел дәвамында укырга-язарга да өйрәнәләр, иман, тәҗвид, тарих, география буенча дәресләр дә алалар. Биредә сыналган уку программасы төбәктә ачылган башка җәдиди мәктәпләр өчен дә тәкъдим ителә. Хәзрәт кызлар укытуны да гамәлгә куя. Шунысы кызык, ул бу чор татар җәмгыятендә бөтенләй булмаганча, малалайлар белән кызларны бер бүлмәдә утыртып укытуны кертә. Әлбәттә, кадимчеләр бу яңалыкларны кабул итәргә теләмәсәләр дә, җәдиди мәктәпләр күрсәткән нәтиҗә аларны уйланырырга мәҗбүр итә. Хәзрәт өмет күрсәткән шәкертләргә укуларын дәвам итәргә дә ярдәм иткән, Гаспринский мәдрәсәсенә киткән Нургали исемле шәкертнең уңышларына сокланып, бу егет Самара төбәге мөселманнарының горурлыгы булачак, дип Исмәгыйль бәк Гыйльман хәзрәткә рәхмәтләр җиткергән хат юллаган [Фатыйх Кәрими, б. 42].

Гыйльман хәзрәт Самара губернасы мөселманнарына гына түгел, ә, гомумән мөселман дөньясында танылa. Аның вафатыннан соң берничә ел дәвамында дөньяның төрле почмакларыннан хатлар, телеграммаларның явуы да шул хакта сөйли.

1897 елның гыйнвар аенда Россия империясендә халык санын алуның авырлык белән баруы, халыкның бу вакыйгадан куркып каршылыклар күрсәтүе мәгълүм. Муллалар, имамнар да аны төрлечә кабул иткән [Загидуллин, 423 с.]. Бер өлеше муллалар халык санын алучыларга каршылык оештырсалар, икенчеләре, киресенчә, халыкка бу гамәлнең кирәклеген һәм дә татар-мөселман җәмгыятенә аның куркыныч тудырмаганлыгын аңлатырга тырышкан. Әлмәт – Бөгелмә төбәгенең 130 татар авылында халык санын алу тыныч узган икән, бу – Гыйльман хәзрәтнең тырышлыгы нәтиҗәсе, ул һәр авылга барып, халыкка вазгыятьне аңлатып йөргән. Гомумән, ул дәүләт кешеләре белән яхшы мөнәсәбәттә булырга тырышкан, шул ук вакытта халык та аны хөрмәт иткән, зурлаган.

Гыйльман хәзрәтнең хәйриячелек эше аерым бер игътибарга лаек: ул – мөмкинлегеннән чыгып, мәчет төзелешенә, мәктәп ачуга хәләл малын хәйрия иткән хәзрәт. Миңлебайда яшәгән елларында ике дисәтинә карабодай чәчтереп, шуннан кергән табышны Петербург мәчете төзелешенә җибәрә. Шулай ук Әстерхан шәһәре хәйрия җәмгыятенә дә малын иганә итүе билгеле. 1898–1899 елларда иген уңмау сәбәпле, Бөгелмә өязе имамнары матди яктан авыр хәлдә калган, чөнки дин әһелләре, нигездә, мәхәллә халкы иганәсенә яшәгән. Руханилар чарасызлыктан, матди ярдәм алып булмасмы дип, Гыйльман хәзрәт аша Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать иткәннәр. Җавап хаты озак көттермәгән, мохтаҗлык кичергән муллаларның тиз арада исем-

леге булдырылган, бурычка акча бирүне оештыруны вәгъдә иткән хат килгән.

Имамлык эше үз җае белән барган вакытта Гыйльман хәзрәт, Миңлебай авылында 30 ел гомер иткәннән соң, имамлык Указын нәзарәткә кайтарып, Оренбург шәһәренә күчеп киткән. Әмма тынгысыз йөрәкле хәзрәт анда да кул кушырып утырмаган, 1900 елның 28 октябрендә кечерәк кенә басмаханә сатып алып, китаплар нәшер итә башлаган. Бу эшкә җаваплы итеп үзенең олы улы – әдип, журналист, педагог Фатыйх Кәримине билгеләгән.

Гыйльман хәзрәт имамлык иткән елларында Ибраһимов фамилиясен йөрткән, бар документларда да ул Гыйльман Ибраһимов буларак теркәлгән. Гыйльман хәзрәт Бөгелмә өязендәге Түбән Чыршылы авылын нигезләүчеләрдән булган Кәрим бабасының исемен фамилия итеп, ике ел буе дәүләт оешмалары белән язышып, бюрократик киртәләрне үтеп чыккач кына кайтара алган. 1898 елның 18 ноябреннән ул Кәрими фамилиясе белән йөри [Фатыйх Кәрими, б. 114].

Хәзрәт авылдан киткәч мәчет һәм мәхәллә белән идарә итү имам-хатыйп, мөгаллим Мөхәммәдханиф Габделгалимовка күчә (Указы 1900 елның 11 августыннан) [СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5870 эш, 15 б–16 кгз]. Ул тумышы белән шул ук өязнең Түбән Чыгтай авылы (хәзерге Чирмешән районы) кешесе. Аның белән бергә имам һәм мөгаллимлек вазифасын Асылгәрәй Җамалетдинев үтәгән, мәзин булып Җамалетдин Сәгъдетдинев хезмәт иткән [СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5870 эш, 15 б–16 кгз].

Әйткәнебезчә, 1914 елны Миңлебай авылы мәчете яна, әмма бу – авылда рухи тормыш сүрелеп торуга сәбәп булмый. Мәхәллә халкына җыелып дога кылу, намаз уку өчен шул авылның хәлле крестьяны Шириздан Камалетдин улы Даутов үзенең 6 тәрәзәле, иңе-буе 9 аршин, биеклеге 4 аршинлы йортын бирә, шушы йорт вакытлыча мәчет вазифасын үти. Аннан ике Даутов – Шириздан Камалетдин улы һәм Сабит Шәрәфетдин уллары – мәчет салдыру эшенә алыналар, дәүләт органнары белән язышучылар да, мәчет төзелешен җитәкләүчеләр дә алар була. Бу авыл тарихында Даутовлар – билгеле фамилия, әлеге авылның күп кенә кешеләре үзләрен Даутовлар нәселенә нисбәтле саный. Шул нәселнең бер әгъзасы – Нурмөхәммәд Даутов (1895–1987) Беренче Бөтендөнья сугышында хәрби мулла булып хезмәт итә. Нәсел башы Дауд Бебишев – Пенза ягы җирбиләүчесе, 1742 елда Миңлебай авылына күчеп килә һәм аның нәселе бу җирлектә яшәп кала [Әлмәт таңнары].

1917 елгы мәгълүм вакыйгалар Миңлебай авылына да үзгәрешләр алып килә. Миңлебайның инкыйлабка кадәр гөрләп торган рухи тормышының тамырларына балта чабыла, иң элек муллаларга каршы көрәш башлана. 1925 елда хәзрәтләр Мөхәммәдханиф Габделгалимов, Асылгәрәй Җамалетдинев, Җамалетдин Сәгъдетдинев һәм аларның гаилә әгъзалары сайлау хокукыннан мәхрүм ителәләр [ТР ДА.

2010 ф., 1 тасв., 32 эш, 67 б кгз]. Мулла, руханиларның күбесенә төшкән язмыш камчысы аларга да тия.

Кайчандыр бай рухи тормыш белән яшәгән, төбәкнең гыйлемлелек һәм зыялылык үзәкләренең берсе булган Миңлебай авылы, инкыйлаб һәм аннан соңгы вакыйгалар нәтиҗәсендә дә, көндәлек мәшәкатьләр белән көн күрүче гап-гади авылга әйләнеп кала. Әмма шулай булса да, ул башка авыллар арасында аерылып тора, чөнки үзенең тарихы, бөек шәхесләре белән данлыклы. Миңлебай авылы – татар җәмгыятенең, аның үсешенең мөһим бер өлеше.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М. И.* Татар шәҗәрәләре: II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 239 б.

Байлар ягы Миңлебай // Әлмәт таңнары. – 2014. – 19 декабрь.

*Загидуллин И. К.* Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 423 с.

Населенные пункты Республики Татарстан. Казань: Академия наук РТ, Институт Татарской энциклопедии, 1997. 389 с.

СӨ ҮДА (Самара өлкәсе Үзәк Дәүләт архивы). 1 ф., 1 тасв., 3068 эш.

СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5540 эш.

СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5540 эш.

СӨ ҮДА. 1 ф., 1 тасв., 5870 эш.

СӨ ҮДА. 1 ф., 12 тасв., 2794 эш.

ТР ДА. 2010 ф., 1 тасв., 32 эш, л. 67 об.

Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык = Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. 320 б.

*Фәхреддин Р.* Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 598 б.

*Ризаэтдин Фәхретдин:* Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 1999. 224 б.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Татарстан Республикасы халыкларының тарих-мәдәни бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.21

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Г.Р. Хөсәенова*

# ПЕРМЬ ТӨБӘГЕ ӘКИЯТЛӘРЕ: ОХШАШ СЮЖЕТЛАР ҺӘМ МӘДӘНИ КЫЙММӘТЛӘР
## (Пермь төбәгендә җыелган фольклор материаллары нигезендә)

В статье авторы рассматривают материалы по сказочному эпосу, собранные в разные годы во время экспедиций в населенных пунктах Пермского края и хранящиеся в фондах Центра письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. В Пермском крае тюркские народы, в том числе и татары, имеют тысячелетнюю историю компактного проживания. В процессе фольклорных экспедиций в данном регионе учеными были записаны многие образцы сказочного эпоса. Ценность записанных из уст информантов национальных сказок с каждым годом растет, они требуют к себе тщательного внимания.

**Ключевые слова**: Пермский край, экспедиция, материал, сказка, сюжет, вариант.

IIn the article the authors consider fairy-tale epic materials collected over the years during the expeditions to settlements of the Perm Territory and stored in the funds of the Center for Written and Musical Heritage of the G. Ibrahimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. In the Perm region, Turkic peoples, including the Tatars, have a thousand-year history of compact residence. During the folklore expeditions in this region, researchers recorded many examples of a fairy tale epic literature. The value of national fairy tales written from the mouth of informants is growing every year, they require careful attention.

**Keywords:** Perm Territory, expedition, material, fairy tale, plot, variant.

Халыкның иҗтимагый фикер үсешен өйрәнүдә, мәдәни үзенчәлекләрен ачыклауда, башка халыклар белән төрле яклап бағланышларын һәм әлеге бағланышларның милли мәдәнияткә йогынтысын барлауда әкиятләр бик зур роль уйный. Пермь өлкәсендә яшәүче татарлардан язып алынган милли әкиятләрдә дә борынгы катлам белән беррәттән үзара бәйләнеш билгеләре чагылыш тапкан.

Пермь крае – төркиләрнең тарихи ватаны. Тарихчылар нигезләвенчә, борынгы бабаларыбызның үзенчәлекле этник төркеме элек-электән биредә нигез корып яшәгән. Ә XVII гасырдан, Идел буеннан күченеп килгән татарлар исәбенә, аларның саны тагын да арткан. Бүгенге көндә Березники, Гремячинск, Губаха, Кизел, Пермь, Чайковский шәһәрләре, шулай ук Барда, Берёзовка, Куеда, Көнгер, Октябрь, Орда, Оса, Пермь, Суксу, Өя, Чайковский, Чернушка һәм Чус районнары Пермь краенда татарлар иң күп тупланып гомер итә торган торак пунктлар дип санала [Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации, с. 121].

Тор, Ирән, Сөлил, Сеп, Шауба, Бөрмә, Тол елгалары буендагы җирләрдә төпләнгән татарларның теле, авыз иҗаты, этнографиясе бик үзенчәлекле. Монда яшәгән халыкны гайнә татарлары һәм көнгер татарлары дигән ике төркемгә бүлеп карау мәгълүм. Бүленешнең сәбәпләре тарихи вакыйгаларга, Казан ханлыгы алынып, ханлык карамагындагы җирләр рус дәүләте составына кертелгән вакытта административ үзәкләрнең төрле булуына бәйләп аңлатыла. Казан ханлыгы җимерелгәч, Көнбатыш Урал рус дәүләте кул астында кала һәм Пермь татарлары яши торган Түбән Агыйдел-Оса җирләре Казан Приказына кертелә, ә территориянең калган өлеше Себер Приказына (башта Чәрдән өязенә, аннан соң Көнгер өязенә) карый башлый [Пермь татарлары].

Халык нигездә аучылык, балыкчылык, умартачылык белән шөгыльләнгән, иген иккән. Казан алынгач, чукындырудан качып, җир эзләп, бирегә татарлар Идел буеннан да килеп урнашканнар, Пермь татарлары составы яңарган. Тел, дин, кәсеп берлеге, утрак тормыш Урта Идел һәм Урал алды татарлары арасындагы этник бәйләнешләрне көчәйткән. Татар хуҗалыклары бирәдә гомер-гомергә руслар белән алыш-бирештә катнашканнар, сәүдә иткәннәр. Татарлар бал, балавыз, балык, кыйммәтле җәнлек тиреләре сатып көн итә торган булганнар [Мөхәммәтҗанова, б. 241].

Пермь татарларының тормыш-көнкүреше дә, гореф-гадәтләре, йолалары да, рухи мәдәнияте һәм сөйләш үзенчәлекләре дә Казан татарларныкына бик якын. Шул ук вакытта күрше халыклардан коми-пермяк, ханты-манси, башкортлар белән тыгыз аралашып яшәү бу төбәктә яшәүче милләттәшләребезне татарларның Идел буенда яшәүче төп массасыннан күпмедер дәрәҗәдә аермалы, үзенчәлекле итә. Идел буеннан читтәрәк яшәү, табигать үзгәлеге, хуҗалыкта, тормыш-көнкүреш итүдәге үзенчәлекләр һәм башкаларга бәйле рәвештә әдәби-мәдәни һәм тел тәэсире тәэсире азая төшә.

Пермь татарлары фольклоры – белгечләрдә зур фәнни кызыксыну уята торган өлкә. Бу якларда яшәүче татарлардан халык иҗаты үрнәкләре шактый күп җыелган. Әлеге үрнәкләрнең күбесе «Татар халык иҗаты» җыентыгының академик томнарына кертелгән. Әйтик, «Дастаннар» (1984), «Әкиятләр» (1977, 1978, 1981) томнарында бу якта яшәүче милләттәшләребез авызыннан язып алынган эпик истәлекләр шактый. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында әле дөнья күрергә өлгермәгән материаллар да җитәрлек.

Казан фәнни үзәкләре, аерым алганда, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан бу төбәк фольклоры шактый еллар дәвамында өйрәнелә. Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында XX йөзнең уртасыннан алып бүгенге көнгә кадәр уздырыла килгән фәнни экспедицияләрдә Пермь татарларыннан язып

алынган авыз иҗаты үрнәкләре язмалары һәм күчермәләре саклана. «Эпик фольклорның зур өлешен алып торуы, әдәби процесста актив катнашуы ягыннан гаять әһәмиятле» [Мухаметзянова, Хусаинова, б. 84] романик характердагы дастан вариантларын («Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Ләйлә – Мәҗнүн» һ.б.) шактый күп биргән төбәк буларак та мәгълүм Пермь крае. Дастани эпостан тыш, Пермь крае авылларында яшәүче милләттәшләребездән төрле елларда фәнни экспедицияләр вакытында күп кенә әкиятләр дә язып алынган, эпик истәлекләр буларак әлеге әкияти эпос аеруча кызыклы һәм бай.

Әйтик, Салам-Торхан турындагы әкиятләргә тукталсак, Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында «Салам-Торхан әкияте»нең 1952 елда Пермь өлкәсенең Югары Мул районы Куян авылында Х. Муратовадан З. Зәйнетдинов язып алган [Салам-Торхан] бер варианты саклана. Бу сюжетның иң әүвәл В. Радлов себер татарларыннан язып алган «Саламия батыша» [Саламия батыша, 1872] әкиятендәге сюжет белән аваздашлыгын искәртү мөһим. Радлов вариантында әкиятнең башлам-бетем өлешләрендә үзенчәлек шактый, әмма охшашлыкны да инкяр итеп булмый. Башка халыклар әкиятләрендәге сюжетлар белән охшашлык ягыннан исә «Салам-Торхан»ның («Лиса-сваха») «Рәхмәтле төлке» («Благодарная лиса», төрек), «Салахбай белән төлке» («Салахбай и лиса», казакъ, башкорт), «Лисица и мельник» (памир халыклары) һ.б. әкиятләр белән уртаклыгы зур.

Салам-Торхан исемле ярлыдан ярлы бер бәндәне бай кызына өйләндереп, йортлы-җирле иткән акыллы һәм хәйләкәр төлке маҗараларына багышланган әлеге әкият татар фольклорчылары тарафыннан иң беренче мәртәбә 1936 елда теркәлгән. Шушы елдан башлап, аны галим Г. Толымбай, атаклы фольклорчы Х. Ярми, язучылар Ш. Маннур, Г. Бәширов ул вакыттагы Бондюг (хәзерге Менделеев) районының төрле авылларында татар телле информантлардан язып алганнар. Бу әкият татарларда иң әүвәл Татарстан террриториясендә (Бондюг районы Псәй авылында (1936), шул ук районның Камай, Турай авылларында (1940), Столбище (хәзерге Лаеш) районының Хәерби авылында (1959), Пермь өлкәсе Берёзовка районы Чокыр (Копчиково) авылында (2001) теркәлгән. Шулай ук Новосибирск өлкәсенең Уба районы Яңа Кучум авылында (1967), Омск өлкәсенең Тара районы Шыклар авылында (1969) себер татарларыннан язып алынган вариантлар да әһәмиятле. Кайбер детальләр, әкиятченең тел үзенчәлекләре, текстның тулылыгы-кимлеге мәсьәләсендә аермалар да күзгә чалына, әмма Салам-Торханның төлке аркасында көнгә чыгу вакыйгасын тасвир иткән, төрле төбәктә язып алынган бу әкиятләрнең сюжеты бер үк дип санарга нигез бар. Пермь краенда 1952 елда язып алынган «Салам-Торхан» исә композициясе, сюжет элементлары белән Татарстан авылларында язып алынган вариантларга якын тора.

Казакъ халык әкиятләре арасында «Три девушки и прожорливая старуха» сюжетына аваздаш «Мустан башлык» әкиятенең ике варианты 1952 елда шулай ук Пермь краенда язып алынган. Әкиятләрнең

Югары Мул районы Куян авылында Р. Кузяевтан З. Зәйнетдинов тарафыннан язып алынганы «Убырлы карчык һәм кызлар» исеме белән теркәлгән [Убырлы карчык һәм кызлар], ә «Өч кыз» дигән исем белән теркәлгән тагын бер текст аерым папкада саклана [Өч кыз]. Бу – үз тукымасында мифологик күзаллау элементларын һәм әкияттәге традицион мотивларны (кайрак ташлый – тау-ташка әйләнә, тарак ташлый – тычкан үтмәс урман була, көзге ташлый – төпсез дәрья барлыкка килә) саклаган борынгы әкиятләрнең берсе. Татар фольклористикасы тарихында бу әкиятнең моннан тыш вариантлары төрле информантлардан 1969 елда Омск өлкәсендә (бу вариант академик томга кертелгән [Мустан батыр, 1978]), 1971 елда Иркутск өлкәсендә, 1977 елда Калмык республикасында («Мус кортка») язып алынган. Һәр текстның үз үзенчәлеге, шуңа да һәркайсы аерым вариантны тәшкил итә. Әкиятнең Пермь краенда язып алынган «Убырлы карчык һәм кызлар» исеме белән саклана торган күчермәсенең башлам өлеше башка төрдәшләреннән нык аерыла. *«Борын-борын заманда, үрдәк урәтник, саескан сотник, песнәк писер булган заманда бар иде ди бер кеше, чыгып китте ди, күлгә җитте ди, күрде ди ике сукмак, ике сукмакның икесендә дә ике куак, куакта утырып торадыр иде ди бер чүрәки, бер үрдәк. Үрдәккә атты, үрдәк очты китте, чүрәкигә тиде, бер пот мае чыкты»* дип башланып, әкиятнең эчтәлеге белән турыдан-туры бәйләнмәгән өлеш әлеге сюжетка башка әкиятләр арасында очрамый. Әкиятнең шушы рәвешле башлануы әкиятченең оста һәм җор телле булуы белән бәйле. Әкиятче, тыңлаучыны җанландырып җибәрү максаты белән, төп сюжетка җиткәнче, үзенең сүзен такмаза-чуалтмыштан гыйбарәт керештән (присказка) башлый, бу өлеш кайвакыт шактый күләмле дә булып китә. «Әүвәл заманда, кәҗә команда, сарык солдат чакта, булган икән ди...» кебек башланып китә торган кечерәк күләмле башламнарны татар әкиятләреннән «Уника егет», «Ярлы егет белән патша кызы» кебек әкиятләрдә очратырга була, ә менә «Мустан башлык»ның Пермь татарларыннан язып алынганындагы кебек чагыштырмача озын башлам – татар әкиятләрендә гомумән сирәк очрый торган күренеш. Моңа охшаш күләмле башламны татар әкиятләреннән «Алтын кош» текстында гына очратабыз.

Сюжет охшашлыгы белән фарсы, Дагстан халыкларында очрый торган, «Корова с белой меткой на лбу», «Красная корова» әкиятләре белән бер типологик рәттәге «Үги кыз белән патша малае» әкияте 1952 елда Пермь өлкәсенең Суксун районы Таулы авылында Р. Габделхәевтән З. Зәйнетдинов тарафыннан язып алынган. Текстның күчермәсе Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана [Үги кыз белән патша малае]. Әкиятнең башка татар вариантлары татар вакытлы матбугатында («Ак юл», 1913) әдәбиләшкән-язма формада, шулай ук Татарстанның Лениногорск районында информант авызыннан язып алынган формада очрый.

«Алтынбай» – «Мустан башлык», «Үги кыз белән патша малае» әкиятләре кебек үк тылсымлы әкиятләр төркеменә керә тор-

ган мәгълүм әкиятләрдән. Пермь өлкәсенең Барда районы Кармак авылында Н. Нурбаков фамилияле информанттан язып алынган варианты «Көтүче» исеме белән билгеле, текст Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана [Көтүче]. Моннан тыш аның Омск, Тобольск, Оренбург өлкәләрендә, Татарстанда табылган вариантлары мәгълүм. Үлеп терелү, терек суы (зәмзәм суы) һ.б. маҗаралы элементларга бай бу әкиятнең Кармак авылында язып алынган варианты сюжеты, образлар системасы белән дөнья күргән вариантка бик якын, әмма биредә мәкерле Хәтфә белән исемнәре алышынган Алтынбайның бай көтүен көтү мотивы бар, шуңа да әкият «Көтүче» исеме белән теркәлгән.

Көнкүреш әкиятләре төркеменә карый торган әкиятләрдән Пермь крае информантларыннан үз вакытында «Фикерле кыз», «Белүче карга», «Тай» әкиятләре теркәлгән. «Фикерле кыз» исеме белән мәгълүм әкият «Ыспай кыз Хәдичә һәм усал хатын турында» дигән исем белән – Пермь өлкәсе Барда районы Сараш авылында Мостафа Ишбулатовтан, «Белүче карга» – Октябрь районы Сәип Әхмәдиевтән, «Тай» – Октябрь районы Ишим авылында Мирзаяф Шәриповтан язып алынган. Күчермәләр Үзәктә яхшы хәлдә саклана [Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге]. Пермь татарларыннан язып алынган текстлар да, бу сюжетка башка вариантлар кебек үк, зирәклек, гаделлек, тискәре сыйфатлардан (мәсәлән, аңгыралыктан) көлү темаларына карый. Көнкүреш әкиятләренең таралыш ареалы бик зур. Югарыда саналган әкиятләргә охшаш, хәтта тәңгәл килә торган әкиятләрне үзбәк, казакъ, уйгур, төрекмән, кыргыз халыклары репертуарында очратырга мөмкин. Шунысы игътибарга лаек: телгә алынган үрнәкләрнең татар телендәге башка вариантлары күпчелек очракта Татарстан территориясендә теркәлгән, язып алыну вакыты 1940–1970 еллар арасы. Гыйбрәтле, табышмаклы, маҗаралы-көлдергеч көнкүреш ситуацияләрен чагылдырган бу әкиятләр барысы да сатирик әкиятләр төркемчәсенә керә. Пермь краенда язып алынган көнкүреш әкиятләре дә – тылсымлы әкиятләр кебек үк, татар мәдәниятенең күркәм сәхифәләреннән берсе.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Пермь өлкәсендә (краенда) төрле елларда фольклор экспедицияләрендә язып алынган әкиятләр – халкыбызның кыйммәтле рухи байлыгы. Бүгенге буын фольклорчылары алдында үз вакытында информантлардан язып алынган бу әкиятләрнең һәрбер вариантын барлык тулылыгы белән бастырып чыгару һәм төрле яклап өйрәнү бурычы тора. Уртак сюжетлы әкиятләрнең һәрбер милли варианты үз үзенчәлеге белән аерылып тора. Аларда – халык хыяллары, омтылышы, холкы, гамәлләре. Пермь краенда язып алынган милли әкиятләр, шушы ук һәм бүтән сюжетка корылган бик күп әкиятләр кебек үк, халкыбызның бетмәс-төкәнмәс иҗат байлыгын чагылдыра.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. ФФ, 1946. Колл. 35, п. 1, сак бер. 1; ФФ, 1976. Колл. 35, п.2, сак. бер. 1; ФФ, 1976. Колл. 35, п. 3, сак. бер. 1

Көтүче // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1952. ФФ, колл. 45, п. 1, сак. бер. 5а.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Пермь татарлары эпик фольклоры // Традиционная культура народов Поволжья. Материалы V Всероссийской научно-практической конференции с международным участием, посвященной 95-летию со дня рождения известного этнографа Р.Г. Мухамедовой. Республиканский центр развития традиционной культуры. 2019. С. 241 – 248.

Мустан батыр // Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап). Казан: Татар. кит. нәшр. 1978. Б. 228–231.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Хөсәенова Г.Р.* Татар эпосында романик төр дастаннар // Фэнни Татарстан. 2017. № 4. С. 79 – 85.

Өч кыз // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1952. ФФ, колл. 46, п. 1, сак. бер. 16.

Пермь татарлары.URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Пирем_татарлары. Мөрәҗәгать итү датасы: 17. 09. 2019.

Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред. Л.М. Айнутдинова, Б.Л. Хамидуллин. Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. 336 с.

Саламия батыша // Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, собраны В.В. Радловым. Ч. IV. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1872. С. 289–292.

Салам-Торхан // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1952. ФФ, колл. 45, п. 1, сак. бер. 2.

Үги кыз белән патша малае // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1952. ФФ, колл. 45, п. 1, сак. бер. 7.

Убырлы карчык һәм кызлар // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1952. ФФ, колл. 45, п. 1, сак. бер. 5.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Хөсәенова Гөлнира Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*

УДК 316.647.5+811.512.145

***Р.К. Сәгъдиева***

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТОЛЕРАНТЛЫК

Статья посвящена постановке воспитательных целей и задач, а именно развитию качеств толератности на уроках родного (татарского) языка. Речь идёт о роли фактического материала, контекста в образовании.

**Ключевые слова:** толерантность, родной язык, микротекст, уважение, сравнение.

The article is devoted to the formulation of educational goals and objectives, namely the development of the qualities of tolerance in the lessons of the native (Tatar) language. We are talking about the role of factual material, context in education.

**Keywords:** tolerance, native language, microtext, respect, comparison.

Еллар-гасырлар үтеп, заманалар үзгәрсә дә, гомум кешелек сыйфатлары белән бәйле кануннар буыннан-буынга күчеп сакланып килә. Сабыр булу, бер-береңне хөрмәт итү, аңлау кебек төшенчәләр гомер-гомергә кеше яшәешендә иң алдан бара. Әлеге вазифа, ягъни балада толерантлык тәрбияләү, иң беренче чиратта, гаиләдә ата-ана җилкәсенә төшә. Икенче яктан, укытучының төп бурычларыннан берсе дә әле ул. Бу юкка гына түгел, чөнки әлеге орлыклар баланың күңеленә нәкъ менә мәктәптә салына.

Толерантлык ул – башка халыкларга, аларның гореф-гадәтләренә, диннәренә карата түземлелек, башка кешеләрнең карашларын хөрмәт итү, сабыр, кешелекле, шәфкатьле булу. Ул дуслык, татулык төшенчәләре белән бәйле [Ефимов, 2019, с. 55; Корякина, 2018, с. 34]. Укыту системасында теләсә кайсы предмет бу юнәлештә эш алып бара, әлбәттә. Туган тел һәм әдәбият дәресләре исә, башка фәннәргә караганда, күпкә үтемлерәк «ысул» куллана. Бу предмет укытучыларының коралы – әдәби әсәр, фактик материал. Укучыларга үз ана телләре, мәдәниятләре аша дөньяви кыйммәтләргә, мәдәнияткә, сәнгатькә юл ачыла. Бу очракта гына, төрле милләт халыклары өчен дөнья күләмендә үзара тату гомер кичереп, бер-берсен аңлап, җылы мөнәсәбәттә аралашып яшәргә ныклы нигез формалаша дияргә мөмкин.

Туган тел дәресләрендә укучыларда толерантлык хисләре тәрбияләү өчен, һичшиксез, уңышлы материал туплау зарур. Һәрвакыт бала теге яки бу мәгълүматны кабул иткәннән соң, уйланырга, фикер йөртергә тиеш. Аның үз фикерен башкаларның карашы белән чагыштырып, тиешле нәтиҗәгә килүе дә мөһим. Укучыларны коллективта эшләргә һәм башкаларның карашын хөрмәт итәргә өйрәтүгә дә, үзара тату эшчәнлек булдыруга да йөз тотыла. Баланың дәрестә теге яки бу теоретик материалны үзләштереп калуы гына түгел, ә киң

карашлы, тәрбияле, зыялы шәхес буларак та формалашуы әһәмиятле. Шул очракта гына укытучы үз максатына ирешкән булып санала.

Һәр дәрес нинди дә булса бер тәрбияви максатны үз эченә ала, мәсәлән, ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә хөрмәт, туган илне ярату, хайваннарны рәнҗетмәү, дуслык хисләре булдыру, мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм итү, сәламәт яшәү рәвеше булдыру һ. б. Татар теле дәреслекләрендә әлеге мәсьәләләр аерым микротекстлар ярдәмендә тормышка ашырыла. Ләкин, кызганычка каршы, авторлар бер дәрестә төрле теманы чагылдырган текстлар бирәләр. Татар теле дәреслекләрендә бер дәрескә 5–6 күнегү бирү каралса, аларның һәммәсенең шул бер максатка юнәлдерелгән текстлардан гыйбарәт булуы шарт. Алар шул ук вакытта төрле жанрларга карарга тиеш: проза әсәреннән өзек, шигырь, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклардан һ.б. Шул рәвешле укучы бер проблеманы таба һәм шуны төрле яклап хәл итәргә омтыла. Укучылар үзара фикер алышалар, бәхәсләшәләр, үз карашларын дәлилләргә омтылалар. Укучылар татар теле дәресендә кагыйдә ятлау белән шөгыльләнмиләр, ә сөйләшергә, аралашырга өйрәнәләр.

Татар телен өйрәткәндә, татар халкының тарихын, мәдәниятен яктырту укучыларның теманы үзләштерү сыйфатын яхшырта, танып-белү активлыгын һәм кызыксынуын көчәйтә. Уку планы белән бәйле теге яки бу дәрес темасын үткәндә, грамматик категорияләрне аңлатканда, татар теленә хас күренешләрне рус теле яисә башка чит тел белән янәшә куеп аңлату да нәтиҗәле була, телләрне үзара чагыштырып карарга, аларның охшаш һәм үзенчәлекле якларын билгеләргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, укучы кайсы гына төркемдә һәм нинди генә гомуми белем бирү оешмасында укымасын, аңа килеш категориясен аңлатмыйча мөмкин түгел. Килеш кушымчалары телдә сүзләрне бер-берсенә бәйли торган чара булып исәпләнә. Әлеге теманы үткәндә, балаларга түбәндәге мәгълүматны тәкъдим итү уңышлы:

«*Эстония укучылары 14 килешне истә калдырырга тиеш, ә Финляндия балалары – 15 не. Венгрия грамматикаларында 22 килеш бар.*

*Дагстанда яшәүче кайбер халыкларның телендә килешләр саны 50 дән артык. Килешләрнең саны буенча алар чемпион.*

*Кытай телендә исемнәр килеш белән төрләнмиләр. Аларда килешләр юк. Сүзләрне ярдәмче сүз төркемнәре бәйли*» [Сәгъдиева, 6 с-ф, 2015, б. 25].

Укучылар, әлеге информация белән танышканнан соң, үзләре өйрәнә торган инглиз, алман яисә француз телләрендәге килешләрнең санын искә төшерәләр, рус телендәге килеш категориясе хакында фикер алышалар. Шул рәвешле бала берничә телне үзара чагыштыра, дәрестә предметара бәйләнеш мәсьәләсе дә уңай хәл ителә.

Хәзерге көндә татар теле дәресләреннән укучы кызыклы мәгълүматлар да алып чыгарга тиеш. Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен өйрәткәндә, «*Испаниядә элек-электән өндәү һәм сорау билгеләрен җөмлә алдыннан һәм җөмлә беткәч куйганнар. Испан укытучылары фикеренчә, бу – укучыларга җөмләне нинди интонация*

*белән укырга кирәк икәнен "әйтеп" тора*» дигән хәбәр бәян ителә [Сәгъдиева, 8 с-ф, 2016, б. 161].

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары тел һәм мәдәният бәйләнешен күрсәтергә, татар халкының тарихын, тормышын, гореф-гадәтләрен чагылдырган сүзләргә, әсәрләргә, текстларга игътибар итәргә тиеш. Яңа заман мәктәпләрендә татар теленә өйрәтү процессы татар, рус һәм башка халыкларның бер-берсе белән мөнәсәбәтен көчәйтүгә һәм мәдәниятен үзара баетуга нигезләнгән. Укучы үз халкының тарихын өйрәнү белән беррәттән, башка халыкларның мәдәниятен өйрәнеп, үзендә аларга карата хөрмәт тәрбияләргә тиеш. Билгеле бер тема белән бәйләп, балаларны танылган шәхесләрнең фикерләре белән таныштырып китү уңышлы:

«*Эшчәнлек – белемгә бердәнбер юл.* (Бернард Шоу)

*Эш беткәч кенә тантана ит.* (Иоганн Гёте)

*Эшләргә теләгән эшеңне яхшы белү кыюлык һәм җиңеллек китерә.* (Дени Дидро)

*Эшкә ашыкмыйча кереш, әмма бер тотынгач ут уйнат.* (Биас)

*Башкарган һәр эшеңне картлык көнеңдә горурланып искә алырлык булсын.* (Марк Аврелий)

*Эшләргә теләгән чарасын таба, эшләргә теләмәгән сәбәбен таба.* (Сергей Королёв)» [Сәгъдиева, 9 с-ф, 2017, б. 133].

Балалар һәр авторның әйтергә теләгән фикерен аңлаталар, үзара фикер алышалар. Күргәнегезчә, әлеге шәхесләр – төрле ил, милләт кешеләре. Бу очракта укучылар аңлы рәвештә төрле милләт кешеләренең фикерләре бер икәнлеген кабул итәргә тиеш. Укучылар исә үзләре дә татар әдипләренең әлеге тема белән бәйле фикерләрен проект эше итеп, презентация формасында иптәшләренә тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Мондый биремнәр яшьләрдә толерантлык, башка халыкларга карата хөрмәт төшенчәләрен тәрбияләү белән тыгыз бәйләнгән.

Коммуникатив компетенцияне үстерү максатыннан исә, туган (татар) теле дәресендә түбәндәге текстны да куллану уңышлы:

«*Поляклар көн дә салат ашыйлар. Салкын бәрәңге боламыгына яшел суган, петрушка, укроп, салат, сельдерей, чөгендер, редиска турыйлар, пешкән йомырка өстиләр. Тоз, үсемлек мае кушалар һәм болгаталар.*

*Англия халкы солы боткасы, редиска һәм яшел петрушкадан әзерләнгән бутерброд ярата, чәйне сөт яки сөт өсте белән эчәләр.*

*Немецлар иртән томат согы эчәләр, май, тәмләткеч үләннәр, сыр, казылык һәм тозлы кыярдан ясалган бутерброд ашыйлар, сөтле кофе эчәләр.*

*Шведлар бодай, кукуруз, солы ярмасына шәфталу, банан һәм кура җиләге, сөт кушалар*» (Календарьдан) [Сәгъдиева, 8 с-ф, 2016, б. 79]. Текст белән бәйле теге яки бу грамматик биремне башкарганнан соң, укучыларга «Сезнең гаиләгез иртәнге ашта нәрсә ашый?» дигән сорау куела. Шул рәвешле төрле халыкларның көндәлек тормышлары, көнкүрешләре үзара чагыштырыла. Бу дәрес вакытына

туры китереп, «Милли ашлар көне» дип аталган дәрестән тыш чара да үткәрергә мөмкин. Һәр мәктәптә дә төрле милләт балалары белем алганга, алар үзләренең милли ризыклары белән таныштыралар, үзара рецептлар алышалар, бер-берсенең кучтәнәчләреннән авыз итеп карый алалар.

Татар теле дәресләрендә укытучылар һәрвакыт тәрҗемә эшләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Иң мөһиме: текст катлаулы булмаска, һәм шул ук вакытта укучыларның сүзлек байлыгын арттыру максаты да алгы планга чыгарга тиеш. Балаларга мәкаль-әйтемнәр, сынамышларны тәрҗемә итү бер яктан җиңел, икенче яктан кызыклы [Сагдиева, 2019, с. 178]. Мәсәлән, түбәндәге очракта мәкальләрне татар теленә тәрҗемә итеп язу сорала. Ярдәмче фигыльләрнең кулланылышына да укучыларның игътибарын җәлеп итү мөһим:

*«* Когда голова думает, язык отдыхает.*

** Мал язык, да всем миром владеет.*

** Ешь суп с грибами, держа язык за зубами»* [Сәгъдиева, 7 с-ф, 2015, б. 93].

Сөйләм телен үстерү максатыннан, ике яисә өч телдәге охшаш текстларны файдалану да уңышлы бер алым булып тора. Мәсәлән, түбәндәге текст бирелә:

*«Иртән уянган Әхәт тәрәзәгә карады. Урамдагы күренешкә гаҗәпләнде. Кичә генә урамда яңгыр коя иде. Бүген кыш җиткән. Күлдәвекләрне көмештәй боз каплаган. Урам яктырган. Кояш болытлар арасыннан җиргә карый. Ул Әхәтне эзли шикелле.*

*Әхәт тиз генә ашады да өстенә җылы бишмәтен, башына кызгылт башлыгын киде. Аякта – итекләр. Урамга йөгереп чыкты. Урамда салкынча, күңелле».* (Факил Сафиннан) [Сәгъдиева, 7 с-ф, 2015, б. 44–45].

Укучылар әлеге өзекнең эчтәлеген сөйлиләр, фикер алышалар, билгеле бер грамматик бирем дә тәкъдим ителә ала. Аннары аларга эчтәлеге белән охшаш рус телендәге текст бирелә:

*«Голая земля промёрзла, а зимы ещё не наступила. Но вот потеплело, и к вечеру пошёл снег. Крупные снежинки закружились в воздухе. С каждой минутой их становилось больше, и наконец снег повалил хлопьями.*

*Я накинул на плечи полушубок и вышел на крыльцо… Воздух был чистый, свежий. Кругом было совсем тихо… Я стоял и следил за тем, как из вечернего неба сыпал и сыпал на землю белый пух зимы».* (Георгий Скребицкийдан) [Сәгъдиева, 7 с-ф, 2015, б. 45].

Укучылар ике текстны үзара чагыштыралар. Рус телендәге өзекне татар теленә тәрҗемә итәләр. Бу очракта алдагы татар телендәге текст балаларга ярдәмлек функциясен башкара.

Югары сыйныфларга шундый ук бирем өчен катлаулырак, фәлсәфирәк тема сайлап алырга кирәк. Ул укучыларны уйландырсын, яшәү мәгънәсен аңларга юнәлеш бирсен. Мәсәлән, әлеге очракта да ике телдәге текстны узара чагыштыру алымын куллану сорала:

*«Бәхет дөнья гизеп, үз юлында очраганнарның барлык теләген үтәп, кешеләрнең барысына да бәхет өләшеп йөргән. Шулай берчак ул саксызлык белән тирән бер чокырга төшеп киткән һәм аннан, күпме генә тырышса да, чыга алмаган. Чокыр янына теләкләренең тормышка ашуын үтенгән кешеләр килә торган, китә торган. Бәхет аларның теләкләрен үтәгән. Бервакыт чокыр янына яшь кенә бер егет килгән. Ул, бәхетне күрсә дә, аннан берни таләп итмәгән. Киресенчә, үзе: "Син, бәхет, ни телисең?" – дип сораган. "Әлеге чокырдан чыгар идем", – дигән Бәхет. Егет аны тартып чыгарган да үз юлы белән киткән. Ә бәхет бер адым да калмый аның артыннан йөгергән. Димәк, без бәхетне түгел, бәхет безне таба».* (Кыйсса)

*«Счастье всегда связано с радостью и благополучием окружающих, и если спросят меня, может ли один человек быть счастлив, когда остальные страдают. Я отвечу: "Нет!"*

*Счастье как будто нарочно убегает от каждого, кто слишком старается заполучить его, и само приходит к тому, чья цель высока и прекрасна, кто совсем не думает о счастье для себя лично.*

*Ведь оно не существует само по себе, отдельно от цели, к которой идешь.*

*Значит, и стремиться надо не к счастью, а к достойной цели. Тогда и узнаешь, какое оно – счастье».* (По Николаю Погодину) [Сәгъдиева, 11 с-ф, 2017, б. 118–119].

Башка илләргә сәяхәт аша да туган төбәгеңә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләргә мөмкин. Нәкъ менә туган (татар) тел дәресләрендә укучы үз ана теле аша башка илләрнең көнкүреше, яшәеше белән танышсын иде.

*«Исландия – дөньядагы иң чиста ил. Халкы бик хәрәкәтчән. Яше-карты физкультура, гимнастика белән шөгыльләнә.*

*Япон халкы ашый торган һәр ризык сәнгать әсәренә тиң. Алар – дөньяда балыкны, диңгез суүсемнәрен, сояны иң күп ашаучылар, яшел чәйне күп эчүчеләр. 80 % ризыкны ашагач, 10 минут ризыкка кагылмыйча утыралар, дәвам итәргәме-юкмы дип уйлыйлар. Күп очракта тамагы туйганын аңлыйлар. Японияңең Окинава префектурасында 100000 кешегә – 50 йөзьяшәр. 110 яшькә җиткәннәр дә шактый. Алар фикеренчә, сәламәтлек һәм озын гомернең бердәнбер сере – үзләрендә үскән җиләк-җимеш, яшелчә, диңгез суүсемнәрен бик күпләп ашап торуларында.*

*Швециядә һәм Яңа Зеландиядә дә экология бик чиста. Халык саф һавада хәрәкәтләнергә ярата. Яшел таулар, калкулыклар-үрләр, салкын сулы күлләрнең искиткеч матурлыгы һәркемне сокландыра. Швед халкы майны күп кулланмый, ризыкны кыздыру белән мавыкмый. Яңа Зеландия халкы сыйфатлы, натураль азык-төлек куллана.*

*Сардиния – Италиянең автоном өлкәсе. Йөзгә җитүчеләрнең күбесе монда яши. Халык үзара бик тату, бер-берсенә карата хөсетлек юк, олылар ялгыз түгел, зур гаиләләр булып, балалар, оныклар*

*бергә яшиләр. Ирләрнең күбесе – көтүчеләр, көн саен 8 чакрым йөреп кайтучылар.*

*Әлеге илләрнең һәркайсында да экологиягә дәүләткүләм әһәмият бирелә. Кешегә стресс аз булсын, эш һәм ялда уңай баланс саклансын өчен тырышалар».* (Календарьдан) [Сәгъдиева, 11 с-ф, 2017, б. 80–81]. Билгеле булганча, дөрес туклану, экология мәсьәләсе дә Россия халкына чит тема түгел. Шуңа күрә югарыдагы текст белән танышканнан соң, укучыларның игътибарын әлеге мәсьәләгә юнәлтергә кирәклеге көн кебек ачык.

Башка илләрдәге яшәеш көндәлек матбугатта гына түгел, ә хәтта татар язучыларының әсәрләрендә дә урын ала. Андый текстларны куллану үзенә күрә тагын да үтемлерәк бер форма булып санала:

*«Бомбей матур шәһәр. Аның халкы "Кемал парк"ын бик ярата. Океан буеннан күтәрелеп паркка кергәч, бакча эчендә зур итек күзгә ташлана. Итекнең үкчәсеннән кереп китеп, эченнән баскыч буйлап менсәң, өстә кофе эчәргә мөмкин.*

*Имеш, Бомбейның яшьләре, өйләнешкәч, шушы паркка киләләр, итек эченә кереп, өскә күтәреләләр һәм шунда кофе эчәләр икән. Имеш, шул итек эченә кереп кофе эчкән яшьләр тату гомер итәләр икән.*

*Һинд зыялысы гаиләсе белән паркка килә дә чирәм өстенә түгәрәкләнеп утыра. Анда чирәм – утыру, яту, уйнар өчен. Һиндлар аз сүзле, үзара җай гына гәп коралар. Аз сөйләшү яки сөйләшмичә табигать ямен күзәтү – ял. Һинд халкы үләнгә, агачка, еланга, юлбарыска һ.б. үсемлек-хайваннарга мәңгелек тереклекнең кирәкле кисәге дип карый. Паркта табигатьне күзәтеп утырганда, һинд тирән уйга чума. Монда динамиклар да, кычкырып көлгән, җырлаган кеше дә юк. Монда бары тик тынлык һәм әдәпле әңгәмә генә. Ә балалар әтиәниләре алдында йогаларның төрле күнегүләрен ясыйлар: чирәмдә баш белән торалар, озак-озак торалар».* (Мөхәммәт Мәһдиевтән) [Сәгъдиева, 11 с-ф, 2017, б. 109].

Татар теле дәресләрендә укучыларны әдәбият, сәнгать әсәрләре белән таныштыру мөһим. Татар халкының рухи байлыгын дөньяви казанышлар үрнәгендә күрсәтү интегральләштерелгән дәресләр үткәргәндә тормышка ашырыла. Укытучы кабаттан М. Мәһдиев иҗатыннан алынган өзекне файдалана ала: «*Ватикан музее – сәнгать әсәрләре тупланган иң бай биналардан берсе. Аның 1400 залы бар. Бу залларда скульптура, рәсем сәнгатенең дөньякүләм әһәмиятле әсәрләре куелган. 1973 елның җәендә Ватикан музее яңа экспозиция күрсәтте. Бу экспозициягә мәшһүр сәнгатькярләр Гойя, Роден, Модельяни, Гоген әсәрләре тупланган. Әлеге галереягә 250 авторның 700 ләп рәсем һәм скульптура әсәрләре керә. Аларда соңгы заман сәнгатькярләре Леже, Пикассо, Сикейрос, Манцу әсәрләре дә бар. Әлеге экспозицияне сәнгать дөньясының иң яхшы җыелмасы дип бәялиләр*» [Сәгъдиева, 11 с-ф, 2017, б. 22]. Укучыларның бер төркеме, текст белән танышканнан соң, әлеге сәнгатькярләрнең берсен сайлап алып, аның турында мәгълүматны Интернеттан табып, реферат язарга һәм сый-

ныф алдында проект эше итеп тәкъдим итәргә тиеш. Икенче төркем бала үз милләтенең дөньякүләм танылган шәхесләре иҗаты белән бәйле иҗади эш башкара.

Татар теле дәресләрендә укучылар үз дөньясы белән генә чикләнмичә, башка халыкларның мәдәниятен, сәнгатен аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсенә ирешергә тиеш. Аерым халыкларга хас гореф-гадәтләрнең, бәйрәмнәрнең гомумкешелек кыйммәте булуына төшенсеннәр иде дигән теләктә яшибез. Укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә файдаланыла торган материаллар төрле халыкларның тормыш үзенчәлекләрен чагылдырырга тиеш, чөнки алар балаларның тел һәм аралашу компетенцияләрен генә түгел, ә этномәдәни компетенциясен булдыру, үстерү, туган ил турындагы белемнәрне формалаштыру чарасы да булып тора.

**Әдәбият**

*Ефимов Н.Э.* Толерантность как проблема современного общества // Взаимодействие науки и общества: проблемы и перспективы. Сборник статей по итогам Международной научно-практической конференции (Самара, 28 февраля, 2019 г.). Уфа: Агентство международных исследований, 2019. С. 55–59.

*Корякина А.А.* Роль поликультурного образовательного пространства в формировании толерантности // Мир науки. М.: Мир науки. 2018. Т. 6. № 6. С. 34.

*Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х.* Татар теле дәресләрендә фольклор әсәрләрен максатчан файдалану // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах). Сборник материалов международной научно-практической конференции. Казань: Изд-во ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. 2019. С. 177–179.

*Сәгъдиева Р.К.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 11 нче с-ф. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. 159 б.

*Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен): 6 нчы с-ф. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 191 б.

*Сәгъдиева Р.К., Кадирова Э.Х.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен): 9 нчы с-ф. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. 143 б.

*Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф., Сабирҗанова Л.К., Нуриева М.Ә.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен): 7 нче с-ф. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 215 б.

*Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен): 8 нче с-ф. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2016. 223 б.

***Сәгъдиева Рамилә Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 371.381.3+746.346

*Л.М. Шкляева*

# УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ МИШӘРЛӘРЕНДӘ УКАЛАП ЧИГҮ

## (Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ экспедициясе нәтиҗәләре буенча)

В статье раскрываются истоки возникновения и стилевые особенности золотного шитья татар-мишарей Ульяновской области по результатам экспедиции 2018 года. Образцы рукоделия мастеров прошлого свидетельствуют как о самобытности узорной отделки, так и общих тенденциях ее развития. Стилевые особенности золотной вышивки у мишарей отражают общую для татар систему духовных ценностей, питавших художественные формы декоративного искусства, первоисточником которого послужила булгарская городская культура периода Золотой Орды, а затем Казанского ханства. У данной локальной группы мишарей устойчиво воспроизводились стилеобразующие элементы золотной отделки компонентов национального костюма. Сделано предположение о городском происхождении далеких предков указанной группы сельских татар-мишарей Ульяновской области.

**Ключевые слова:** золотное шитье, татары-мишари, народное искусство, стилевые особенности.

The article reveals the origins and stylistic features of the gold embroidery of the Tatars-Mishars of the Ulyanovsk region according to the results of the 2018 expedition. Samples of needlework by masters of the past shows both the originality of patterned decoration and general trends in its development. The stylistic features of the gold embroidery among the Mishars reflect a common system of Tatars' spiritual values that nourished art forms of decorative art, the primary source of which was the Bulgarian urban culture of the Golden Horde period, and then the Kazan Khanate culture. This local group of Mishars steadily reproduced the style-forming elements of the gold trim of the components of the national costume. An assumption is made about the urban origin of the distant ancestors of this group of rural Tartar Mishars of the Ulyanovsk Region.

**Keywords:** gold embroidery, Tatars-Mishars, folk art, style features.

Егерменче гасырның беренче чирегеннән башлап, тикшеренүчеләрнең игътибарын үзенчәлекле татар чигү сәнгате җәлеп иткән. П.М. Дульский [Дульский, 1925], Ф.Х. Вәлиев [Валеев, 1984], Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова [Валеева-Сулейманова, 1995], Ф.Ф. Гулова [Гулова, 1980] һ.б. әлеге сәнгати иҗат юнәлешен ачканда, нигездә Казан татарларының чигү үрнәкләренә таянганнар. Әлеге мәкаләдә моңарчы өйрәнелмәгән Ульяновск өлкәсе мишәрләре локаль төркеменең укалап чигүенә хас стиль үзенчәлекләре карала.

## Урта Идел буенда яшәүче татарларның укалап чигү эшенең үсеш үзенчәлекләре

Татар телендә алтын җепләр белән чигү «ука» дип атала – бизәлеш сәнгатенең бу төре башка төрки телләрдә дә шулай ук яңгырый [Рамазанова, с. 235]. Тикшеренүчеләр фикеренчә, аның килеп чыгышы грек «оккасы»на – алтын тәңкәгә нисбәтле [Әхмәтьянов, б. 343]. Билгеле булганча, эшләнмәләрне бизәү осталары алтын җепләр белән беррәттән металл җепләрдән дә – аз гына көмеш кушылган «мишура»дан (гарәпчә «mozavvir»дан – ясалма) файдаланганнар. Хәзерге фәнни публикацияләрдә алтынга яки көмешкә охшатып ясалган җепләр белән эшләнгән чигешләрне укалап чигү дип атыйлар.

Идел буе татарларының этник ата-бабаларында алтын белән чигү һәм укалап чигү Урта гасырларда аеруча киң тарала. Бу чорда ул һөнәри кәсепчелек рәвешендә үсеш ала, һәм Җучи олысының зур шәһәрләрендә, ә аннан соң Казан ханлыгында яшәүче аксөякләр арасында мондый эшләнмәләргә ихтыяҗ зур була [Валеева-Сулейманова, 2005, с. 490]. Казан ханлыгын Явыз Иван гаскәрләре яулап алганнан соң, шәһәр татарларының бер өлеше авыл җирлегенә күченеп китсә дә, алар шәһәр этник культурасы элементларын саклауларын дәвам итәләр, авылча яшәү шартларында да әлеге чигеш үрнәкләре тотрыклы рәвештә туып кына тора [Исхаков, с. 22]. Шул рәвешле, укалап чигү сәнгате үзенең тамырлары белән «крестьян мохитенә дә, шәһәр һөнәрчеләре иҗатына да барып тоташа» [Валеева-Сулейманова, 1995, с. 9]. Ул бербөтен сәнгать ансамбле буларак XVIII гасыр урталарыннан XIX гасыр урталарына кадәр формалашкан классик татар костюмының традицион элементлары бизәлешендә кулланыла [Валеева-Сулейманова, 2002, с. 114]. Татарларда баш киемнәре, камзуллар, күкрәкчәләр һәм аяк киемнәре укалап чигү белән бизәлә. Аның аналоглары Кырым һәм Әстерхан татарларында күзәтелә, белгечләр бу күренешне Алтын Урдадан соңгы ханлыкларның [Суслова, 2009, с. 283] укалап чигү сәнгате белән бәйлиләр. Ул берничә гасыр дәвамында тигезсез, әмма тотрыклы үсеш кичергән. Г.Ф. Вәлиева-Сөләйм526ованың архив мәгълүматларына нигезләнгән тикшеренүләре дә шуны раслый: «XIX гасыр башыннан Казанда читек-кәләпүш кәсепчелеге составында укалап чигү җитештерүе барлыкка килә, аның составында 1 меңнән артык хатын-кыз кәсепче осталар эшли» [Валеева-Сулейманова, 2005, с. 490]. Бу фактка таянып, әлеге эшләнмәләргә сорау зур булган, ягъни ука белән чигеп бизәлгән әйберләрне яратып кию традициясе яшәгән, дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Әлеге һөнәрнең XIX–XX гасыр башына караган матур үрнәкләре Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музеенда күрсәтелә. Казан татарларының хатын-кыз баш киемнәрендәге (калфакларда) чәчәк-үсемлек бизәге композициясендә асимметрия принцибы кулланыла. Мондый бизәү алымнарын Түбән Новгород мишәрләренең милли костюм предметларында очратырга мөмкин [Султанова, с. 85]. Көньякта мишәр хатын-кызларының күкрәк япкычларына кулдан укалап чигеп бизәк

төшерелгән, ул күлмәкнең түштәге уемына салынган [Мухамедова, 1997, с. 179]. Мондый бизәлеш Казан татарларының укалы тасма (позумент) белән бизәлгән Күрәкле (күрәк сыман) күкрәкчә-изүеннән аерылып торган [шунда ук, б. 175].

## Ульяновск өлкәсе мишәрләренең укалап чигеше эволюциясендәге локаль үзенчәлекләр

Безнең мәкаләдә хәзерге Ульяновск өлкәсенең көньягында яшәүче кузнецк-хвалын төркеме мишәрләре укалап чигүенең аутентик үрнәкләре карала. Материал дүрт районның (Павловка, Николаевка, Яңа Малыклы һәм Чардаклы) егерме авыл торак пунктын колачлаган экспедиция барышында, мишәрләр локаль төркеме вәкилләре тупланып яшәгән өч авылда җыелды [Мухамедова, 2008, с. 88–95, 201–208] Монда авыл халкының барысын да диярлек мөселманнар тәшкил итә [Кадыров, с. 132]. Аерым белгечләр фикеренчә, аларның борынгы бабалары, Казан татарлары һәм керәшеннәрдән аермалы буларак, кайчандыр Җучи олысы территориясендә яшәгән башка төрки кабилә берләшмәләренә караганнар [Трофимова, с. 48, 120]. Аларның атамасы баштан ук үзләре төпләнеп яшәгән Ука елгасы районындагы урын исеме белән бәйле булган [Габдуллин, с. 222]. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, XIV–XVII гасырларда мишәрләрдән «йомышлы татарлар» хәрби сословиесе формалашкан, анда төрле-төрле феодаль аксөякләр вәкилләре кергән [шунда ук, б. 223]. Хезмәтләре өчен аларга җирләр (шул исәптән хәзерге Ульяновск өлкәсе территориясендә дә) биргәннәр. «Петр I нең 1713 елның 3 ноябрендәге указы буенча чукынырга теләмәгән кешеләрне салым түләргә тиешле катлау (дәүләт крестьяннары) иткәннәр» [шунда ук, б. 226].

Экспедиция материаллары күрсәткәнчә, Ульяновск өлкәсенең мишәрләр яшәгән авылларында үзенчәлекле гамәли-бизәлеш сәнгатенең авыл тормышы өчен характерлы төрләре күптәннән чәчәк аткан. Тукучылык, бәйләү, корама мозаика һәм Самара [Шкляева, 2015], Оренбург [Шкляева, 2016] өлкәләренең мишәр осталары чигүенә охшаш мулине белән чигү хатын-кызларның йорт шөгыле булып саналган. Ульяновск мишәрләренең дөньяга карашы һәм, димәк, бизәлеш системасының эстетик принциплары формалашуга мөселман үзәкләреннән ераклашу һәм шулай ук мордва, рус һәм чувашлар белән тыгыз күршеләр булып яшәү белән бәйләнгән этносара элемтәләр дә йогынты ясаган. Әлеге вазгыять мишәрләрдә диндарлыкның югары дәрәҗәсен тәэмин итеп кенә калмаган, ә милли традицияләрне саклау омтылышын да көчәйтә төшкән [Закиров, с. 39]. Укалап чигешнең стиль үзенчәлекләре Алтын Урда чорындагы шәһәр мәдәнияте, соңрак Казан ханлыгы чорындагы гомумтатар стиль үзенчәлекләренә нигезләнеп үсеш алган.

Татар хатын-кызлары костюмының укалап чигү белән бизәлгән элементлары тикшерелә торган егерме авылдан өчесенең генә (Павловка районының Татар Шомалагы, Йәүли һәм Николаевка районы-

ның Татар Сайманы) музей фондларында табылды. Туган якны өйрәнүчеләр һәм әлеге авыл музейларының мөдирләре укалап чигелгән үрнәкләрнең нәкъ менә шушы җирлектә эшләнүләрен хәбәр иттеләр[1]. Бирелдә өске күкрәкчәләрнең локаль үзенчәлекләрен күрсәтү зарур: укалап чигеп чәчәк-үсемлек орнаменты төшерелгән эшләнмәләр турыпочмак рәвешендә булып, респондентларның барысы да аларны «күкрәкчә» дип атады. Димәк, әлеге төркемнең [Суслова, Мухамедова, с. 138] формалашуына нигез булган этномәдәни традицияләр сакланган [Суслова, Мухамедова, с. 138]. Халык эстетикасы кануннарының гасырлар дәвамында формалашуын һәм һәм саклана баруын исәпкә алсак, бүгенге көндә Татар Шомалагы, Йәүли һәм Татар Сайманы авылларында яшәүчеләрнең ерак бабалары шәһәрдән чыкканнар дип уйларга тулы нигез бар. Бизәлеш сәнгатенең бу төрен яшәтү өчен халыкның чагыштырмача мал-мөлкәтле булуы, технологияләрне белүче осталарның булуы һәм милли бәйрәм киемен бизәүдә аны куллану традицияләренең саклануы кебек шартларның үтәлүе таләп ителә.

Бу очракта укалап чигү үсешенең озын юлы Гражданнар сугышы (1918–1921) һәм тоташ күмәкләштерү вакыйгаларына бәйле рәвештә өзелсә дә, нәселдән килгән авыл чигүчеләре кулы белән гаҗәеп оста итеп чигелгән эшләнмәләр гаиләләрдә сакланган һәм буыннан-буынга тапшырылган. Аларның бер өлеше хәзер мәктәп, клуб һәм китапханә музейлары тупламаларында. 1956 елда этнографлар Р.Г. Мөхәммәдова һәм С.В. Суслова үзләренең хезмәтләрендә Татар Сайманы авылындагы укалап чигелгән күкрәкчәләрне күрсәтәләр [Суслова, Мухамедова, с. 107]. Бу төр гамәли сәнгатьнең яшәве җирле халык җырлары текстларында да раслау тапкан: «Укалы күкрәгемне терәп биимен» [шунда ук, б. 222]. Галимнәр җыелган материалларны анализлап, тасвирламаларын эшләгәннәр, ләкин Ульяновск өлкәсенең әлеге мишәр авылларында укалап чигүнең барлыкка килү тарихын (кагыйдә буларак, ул шәһәр кәсепчелеге булып саналган) ачмаганнар.

Әлеге һөнәрнең саклануы татар хатын-кыз костюмы бизәлешенең күчә бару принцибына нигезләнүе белән аңлатыла. Җирле халык элек затлы саналган шөгыльнең таралуын металл җепкә бәяләрнең әллә ни кыйммәт булмавы белән аңлата. Респондентлар раславынча, аларны ясау өчен ватык самавырлар, тәңкәләр, кашыклар һәм хәтта сугышчан бүләкләр дә файдаланылган: һәвәскәр осталар металл җеп ясауның борынгы ысулын кулланганнар. Шул ук вакытта түбәндәге технологик чылбырны катгый рәвештә үтәгәннәр: беренче этапта металлны кирәкле сыгылмалылыкка ия юка кәгазь бите хәленә килгәнче чүкеп юкартканнар, аннан соң – аны бик тар озынча кисәкләргә кискәннәр, кыздырып, махсус җайланмадагы кечкенә

[1] Респондент – нәселдән килгән чигүче *Ямаева Зәйнәп Имади кызы* (1923) күкрәкчәне күлмәк өстеннән, шулай ук чигеп бизәк төшерелгән камзул астыннан кияләр иде дип сөйләде: «Күкрәкчәне алтын җепләр белән бизиләр, әмма моны бөтен хатын-кызлар да булдыра алмый. Минем әнием Бәдиян кул эшенә бик оста булып, күкрәкчәләрне дә, калфакларны да үзе чигә иде».

тишекләр аша үткәргәннәр, нәтиҗәдә ул үтә нәзек тимер чыбык рәвешен алган. Оста хатын-кызлар аны башка ныклы җеп (еш кына ефәк) белән кушып кулдан ураганнар, анысының төсе металл җепнекенә туры китереп сайланган. Процесс тәмамлангач, аларны эрләнгән җеп дип атаганнар.

Мондый алтын яки көмеш кәнител без өйрәнгән авылларның осталары тарафыннан да файдаланылган. Аларның чигүле эшләнмәләрендә чәчәк-үсемлек декоры рельефлы бизәк барлыкка китерү өчен җеп астына тукыма яки кәгазь куялар, аның өстеннән башта җитен яки ефәк, сары яки ак җепләр белән чигәләр, ә аннары – бернинди ара калдырмыйча, тигез рәтләр белән укалап чигү башкаралар. Һәр җеп астан сизелмәслек итеп элмәк ясап беркетелә. Әлеге ысул атламлап беркетеп чигү дип атала. Бу техника тыгыз нигез таләп иткән, шуңа күрә бәрхет һәм атлас эшләнмәләрнең сул ягы өйдә тукылган тукыма белән ныгытылган.

## Ульяновск өлкәсе мишәрләр локаль төркеме укалап чигү сәнгатенә хас стиль үзенчәлекләре

Татар Шомалагы, Йәүли һәм Татар Сайманы авылларының мәктәп музейларында урын алган укалап чигелгән күкрәкчәләрнең югарыда бәян ителгән техникада эшләнгән үрнәкләренең бизәлеш стиле үзенчәлекле: ул горизонталь буенча да, вертикаль буенча да һәр рәткә өчәрләп урнашкан тугыз элементтан торган чәчәкләр яки гөлләмә рәвешендә төзелгән композициягә ия. Көзгедәге кебек катгый симметрияле гөлләмәләр чигү XVIII гасырның икенче яртысы өчен типик күренеш санала. Бу яктан алар фарсы һәм Үзәк Азия тукымаларындагы бизәк бәйләмнәренә якын торалар [Валеев, 1984, с. 29].

Алты экспонат XVII гасыр ахырында нигез салынган Татар Шомалагы авылының мәктәп музеенда күрсәтелә. Музей тупламасы 1982 елда формалашкан һәм җирле халык бүләкләре хисабына даими рәвештә тулыланып тора. Экспонатларның берсе – турыпочмак рәвешендәге зәңгәр бәрхет кисәгеннән торган күкрәкчә, ул өйдә тукылган киндер өстенә тегеп куелган, аңа өч вертикаль һәм горизонталь рәтләргә тезеп, симметрияле бизәк төшерелгән. Композициянең үзәгендә ике яктан да парлы таҗ яфракчыклар белән капланган гөлләмә утыра. Аның өстендә һәм астында стильләштерелгән үсемлекләрдән төзелгән бертөрле раппортлар урнашкан.

Әлеге авыл музее экспозициясендә шулай ук җирле локаль стиль үзенчәлекләрен саклап, оста итеп чигеп бизәлгән алсу атлас күкрәкчә дә күрсәтелгән. Аның үзенчәлеге – очлары куш яфраклы (ислими) сабакларның гаҗәеп нәфис итеп бирелешендә. Нәзек һәм шома сызыклар уралмалары гөлләмәләргә йомшак назлылык өсти, бу сыйфат гадәттә үзенә җәлеп итүчән хатын-кыз образына якын. Розеткалар рәвешендәге чәчәк бөреләре һәм укмаш чәчәкләр тормыш башлангычын символлаштыра, ул җиләк-җимешләрнең өлгерүен һәм нәсел

дәвамлылыгын вәгъдә итә кебек. Элеккеге дөньяга караштa моңа зур әһәмият бирелгән [Шкляева, 2017, с. 26].

Атламлап беркетеп чигү техникасында эшләнгәннәргә охшаш бизәкләр белән Ульяновск өлкәсенең чигү осталары күкрәкчәләр генә түгел, калфаклар да чиккәннәр. Әйтик, мәктәп музее күргәзмәсендә укалап чигелгән аскы кайтармасы сакланган кара бәрхет калфак куелган. Аның бизәлешендә металл җепләрдән тыш, йомшак түгәрәк кәнител белән чигү кулланылган, аның иң нәзек бөтеркәләре алтынсыман тимер чыбыкны стерженьгә урауны үз эченә алган махсус технология буенча әзерләнгән. Чигүче осталар калфакны алтынсу пайеткалар белән өстәмә рәвештә бизәгәннәр.

Тупламадагы бүләк салу өчен тегелгән бәрхет капчыкның бизәлеше техник яктан әллә ни отышлы түгел: аның кара фонында рельефлы үсемлек бизәге бик нык аерылып тора. Аның композициясе вертикаль рәвештә бер рәткә урнаштырылып, реалистик гәүдәләндерелгән өч чәчәктән гыйбарәт. Өстәгесе һәм астагысы бер-берсенә симметрияле урнашкан, үзәктәгесе – асимметрияле һәм зуррак итеп бирелгән. Катлаулы итеп төзелгән укмаш чәчәкләр канәфер һәм яки күкчәчәкләр белән ассоциацияләнә.

Павловка районы осталарының укалап чигүенә хас локаль стиль үзенчәлекләре Татар Шомалагы эшләнмәләренең сәнгатьчә чишелешендә генә түгел, XVIII гасыр башында нигез салынган Йәүли авылы мәктәп музеенда сакланган экспонатлар бизәлешендә дә чагылыш таба. 1970 елда ачылган музей күргәзмәсенә костюм комплексы элементлары, шул исәптән күкрәкчәләр дә кергән.

Аларның берсенең кара хәтфә фонында алтынсыман җепләр белән чигелгән бизәк бик нык аерылып тора. Тыгыз һәм тигез атламнар белән беркетеп чигелгән чигү үрнәге зәркәнчелекне хәтерләтә. Үсемлекләрнең традицион композициядә урнашкан нәфис сабаклары бөтерелгән розеткаларга охшап китә. Декорның кызыклы элементлары асимметрияле үзгәртеп бирелгән. Стильләштерелгән укмаш чәчәкләр лаләләр рәвешендә ачыла. Иртә номадларның борынгы дөньясы эстетикасы белән бәйле әлеге образ татар милли сәнгате декоратив системасының тотрыклы элементы булып тора. Тормыш яңарышын чагылдыручы лаләләрне төрле буын татар осталары орнаменталь мотивларда, барлык төр үзенчәлекле һөнәрчелек үрнәкләрендә файдаланалар [Шкляева, 2017, с. 27–28].

Экспозициягә куелган икенче күкрәкчә лаконик рәвештә, бизәк төшерүнең авылда кабул ителгән композицион чишелешенә нигезләп эшләнгән. Аның симметрияле урнашкан элементлары бер үсемлекнең фрагментлары рәвешендә бирелгән, алар арасында чигүче оста дүрт ярымай урнаштырган. Бу образ мәҗүсилек чорында төрки халыкларда гаилә учагын, хатын-кызларны һәм балаларны яклаучы Умай алиһәне гәүдәләндерә [Гюль, с. 137].

Укалап чигүнең алдагы үрнәкләре Татар Сайманы авылының 1994 елда төзелгән мәктәп музее тупламасында табылды. Биредә өч

күкрәкчә саклана, аларның берсенең бизәлешендә җирле стиль үзенчәлекләре сакланмаган, ул тугыз түгел, ә бер генә дискрет элементтан тора. Ак фонда кабарынкы яфраклы матур чәчәк чигелгән, ул ак нигезне тулаем тутырып тора. Үсемлекнең дүрт нәфис сабагында асимметрияле рәвештә бөреләр һәм алты таҗлы биш укмаш чәчәк-розетка урнашкан. Сурәт хатын-кыз башлангычын чагылдыручы стильләштерелгән тормыш агачы буларак кабул ителә.

Зәңгәр бәрхеттән эшләнгән икенче күкрәкчә татар укалап чигү осталарына хас традицион композиция буенча эшләнгән: биш чәчәктән һәм яфраклы дүрт сабактан торган үсемлек бизәкләре эшләнмәнең почмакларына урнаштырылган. Декоратив сызыкларның матур бөгелешләре бизәлешкә нәфислек өсти. Өченче күкрәкчәдә үсемлекләр төрле төстәге тамбур белән чигелгән. Чигүче оста композиция үзәгендә алтынланган җепләр белән стильләштерелгән үсемлекне гәүдәләндергән, ул һәр яктан парлап урнашкан дүрт яфрактан, чәчәк бөресе белән тәмамланган сабактан тора. Җирле чигүчеләр, гадәттәгечә, тамбур чылбырын металлдан эшләнгән кечкенә ыргак белән башкарганнар, бу техника, укалап чигү кебек үк, Урта Азия осталарында да киң таралган була [Холикова, Нуриддинова, с. 298]. Әлеге фактны төрки халыкларда уртак мәдәни кануннарның чагылышы дип карарга мөмкин.

## Этномәдәни традицияләре якын булган халыкларда укалап чигү сәнгатен саклау тәҗрибәсе һәм аны куллану перспективалары

Милли сәнгатьнең өзелгән үсешен яңадан торгызу тәҗрибәсенә хәзерге Кырым татарлары ия [Акчурина-Муфтиева, с. 9]. Узган гасырның 40 нчы елларында депортация шартларында югала башлаган укалап чигү традициясе бүгенге көндә кабат яңарыш кичерә. Җуелган кыйммәтләрне һәм традицияләрне кайтару процессы XX гасырның 90 нчы елларында башланды. Бакчасарайда «Орнек» үзәге ачылды, анда хатын-кызларны укалап чигү сәнгатенә өйрәтәләр, Симферопольдә дә шундый ук курслар оештырылган, анда үзенең осталык серләре белән рәссам З. Бекирова (ул вакытта традицион ике яклап чигү техникасын саклаучы бердәнбер белгеч) уртаклашкан [Соболева, с. 12].

Ульяновск татарларының борынгы бабалары Болгар чорыннан ук Урта Азиядән килгән сәүдәгәрләр белән сәүдә иткәннәр. Вакытлар узу белән, үзара хезмәттәшлек өлкәсенә күпсанлы үзбәк һәм татар һөнәрчеләре, шул исәптән – бер-берсенең иҗатын баеткан, тулыландырган укалап чигү эше осталары да кергән. Укалап чигү сәнгате Үзбәкстанда бүгенге көндә дә үсеш кичерә, чигүче осталарның эшләнмәләре шәхси куллану өчен дә, сувенир продукция сыйфатында да файдаланыла. Әйтергә кирәк, Бохара шәһәренең (Үзбәкстан) укалап чигү үзәгендә гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, хәзерге вакытта Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2018) Л. Фәсхетдинова белем алды. Аның әсәрләре әлеге төрнең Казан

татарлары локаль төркеменең заманча бизәлеш сәнгатендә булуын дәлилли. Казан татарларының XIX гасыр уртасы – XX гасыр башына караган чигү үрнәкләре останың иҗади эзләнүләренә чыганак булып хезмәт итә. Аларның күбесе Татарстанның музей тупламаларын бизи яки шәхси коллекцияләрне тулыландыра.

Мишәрләрнең укалап чигешенә сәнгати анализ ясау чагыштырма аспектта Казан татарларының укалап чигүе белән кайбер параллельләр үткәрергә һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирде. Ульяновск мишәрләренең хатын-кыз костюмында нигездә күкрәкчәләргә укалап чигеп бизәк төшергәннәр, ә Казан татарларының костюм комплексында укалап чигү еш кына баш киемнәрен бизәгән, шул ук вакытта аларның күкрәкчәләренә, кагыйдә буларак, алтын тасмалар тегелгән. Мишәр чигүче осталарының бизәк композициясендә, кагыйдә буларак, симметрия принцибы төгәл үтәлгән, бер типтагы бизәлеш тугыз мәртәбә (өчәрләп өч тапкыр) кабатлана торган чәчәкләрне яки гөлләмәләрне үз эченә ала. Казан татарлары исә асимметрияне артыграк күрәләр. Бизәлештә кулланыла торган чәчәк-үсемлек орнаментының тотрыклы элементлары ике локаль төркемдә дә үзара охшаш. Декорда төрки халыклар эстетикасына хас чәчәк-үсемлек орнаменты кулланылган: лаләләр, розеткалар һәм ике яфрак белән очланган сабак уралмалары. Коръәндәге Җәннәт бакчасын чагылдырган бизәкләр алтынланган җепләр белән атламлап беркетеп чигеп башкарылган. Мишәрләрнең сакланып калган үрнәкләрендә башка техникалар (аерып чигү, таратып чигү һәм үреп чигү [Сергеева, с. 21]) кулланылмаган. Осталар тигез чигүгә өстенлек биргәннәр [27, б. 169]. Югарыда санап үтелгән стиль үзенчәлекләрен укалап чигүне кабат торгызганда һичшиксез исәпкә алырга кирәк.

Ульяновск мишәрләре локаль төркеменең укалап чигүе аларның ерак бабаларының шәһәр чыгышлы булуын раслый. Хәзерге вакытта бу төр бетүгә йөз тота. Үлгән кешеләрнең иске әйберләрен яндыру гадәте булу сәбәпле, XX гасыр башында җирле чигүчеләр тарафыннан укалап чигелгән бик сирәк үрнәкләр генә сакланган. Традиция нигезендә осталык серләре буыннан буынга 1920 елларга кадәр генә тапшырыла килгән. Эшләнмәләрнең бизәлеше татар гамәли сәнгатенә хас локаль стиль үзенчәлекләре белән аерылып торган.

Ульяновск өлкәсе татарларында сәнгати иҗатның әлеге төрен торгызу өчен, үзенчәлекле үрнәкләрне фәнни әйләнешкә кертү генә түгел, аларны реконструкцияләргә, шулай ук белгечләр чакырып, мастер-класслар да оештырырга кирәк. Мәчетләр яки клублар каршында, яшь буенча бернинди чикләүләр куймыйча «Укалап чигү» түгәрәкләре ачарга кирәк. Заманча сәхнә костюмының зарури элементлары буларак та, сувенирлар, һәр татар гаиләсендә булырга тиешле милли мәдәният компонентлары (декоратив сөлгеләр, Коръән савытлары, калфаклар, түбәтәйләр һ. б.) буларак та укалап чигелгән эшләнмәләргә ихтыяҗ зур.

**Әдәбият**

*Акчурина-Муфтиева Н.М.* О декоративно-прикладном искусстве крымских татар XV – первой половины XX вв. Симферополь, 2008. 392 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: [= Этимологический словарь татарского языка]: Ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 1 т. (А – Л). 2015. 543 б.; 2 т. (М – Я). 2015. 567 б.

*Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 188 с.: ил.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). Казань: ФЭН, 1995. 191 с.: ил.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Золотое шитье // Татарская энциклопедия. Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2005. С. 490 – 492.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Татарское национальное искусство: к проблеме этно-культурного единства // Единство татарской нации. Материалы научной конференции АН РТ «Цивилизационные, этнокультурные и политические аспекты единства татарской нации» (Казань, 7 – 8 июня 2002 г.). Казань: Фэн, 2002. С. 112 – 118.

*Габдуллин И.Р.* К вопросу об этносословной эволюции тюркского населения Уфимского уезда (губернии) в XVII–XIX вв. // Единство татарской нации. Материалы научной конференции АН РТ «Цивилизационные, этнокультурные и политические аспекты единства татарской нации» (Казань, 7 – 8 июня 2002 г.). Казань: Фэн, 2002. С. 214 – 237.

*Гулова Ф.Ф.* Татарская народная вышивка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 80 с.

*Гюль Э.* Сады небесные и сады земные. Вышивка Узбекистана. Скрытый смысл сакральных текстов. М.: Марджани, 2013. 208 с.

*Дульский П.М.* Искусство казанских татар. М.: Центр. изд-во нар. СССР, 1925. 58 с.: ил.

*Закиров Р.З.* Ульяновские татары чтят традиции и обычаи своего народа. Самара, 2005. 87 с.

*Исхаков Д.М.* О традиционно-народной и национальной сторонах культуры татар // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 150-летию со дня рождения педагога-просветителя художника Ш.А. Тагирова (Казань, 17 – 18 апреля 2008 г.). Казань, 2009. С. 21 – 27.

*Кадыров Р.В.* «Понятие «служилые татары в Русском государстве XVI начала XVIII вв. Теоретико-методологические подходы» // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Вып. 1. Казань. 2010. С. 130 – 132.

*Мухамедова Р.Г.* Татарская народная одежда. Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 224 с.

*Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: историко-этнографическое исследование. Казань: Магариф, 2008. 292 с.: ил.

*Рамазанова Д.Б.* Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. Казань: Мастер Лайн, 2002. 352 с.

*Сергеева Н.Г.* Гомер агачы=Древо жизни. Казань: Магариф, 2008. 79 с.: ил.

*Соболева Е.Л.* Искусство Крыма: история и возрождение // Искусство крымских татар. Каталог выставки. Октябрь-ноябрь 2013. Казань: Заман, 2013. С. 11 – 15.

*Султанова Р.Р.* В умелых руках все спорится. Традиционные ремесла и прикладное искусство // Из сокровищницы научных экспедиций. Нацио-

нально-культурное наследие: Нижний Новгород. Казань: Медине, 2011. С. 209–236.

*Суслова С.В.* Костюм крымских татар: к вопросу об этнокультурных параллелях с Волго-Уральскими татарами // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов. Серия «Искусство тюркского мира». Вып. 1. Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 150-летию со дня рождения педагога-просветителя, художника Ш.А. Тагирова (Казань, 17–18 апреля 2008 г.). Казань, 2009.

*Суслова С.В., Мухамедова Р.Г.* Народный костюм татар Поволжья и Приуралья (середина XIX – начало XX в.). Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань: Фэн, 2000. 312 с.

*Трофимова Т.А.* Этногенез Татар Поволжья в свете данных антропологии. Москва: Изд-во АН СССР, 1949. 263 с.

*Фасхутдинова Л.Ф.* Золотное шитье татар-мишарей: особенности техники и орнамента // Этнографическое обозрение № 4. М., 2019. С. 169–176.

*Холикова Н.Ш., Нуриддинова М.У.* Золотошвейное искусство Бухары // Молодой ученый. 2014. № 8. С. 298–301. URL http://moluch.ru/archive/67/11433 (дата обращения: 14.05.1019).

*Шкляева Л.М.* Вышивка татар Оренбургской области (по результатам экспедиции в июне 2015 года) // Традиционная культура народов Поволжья: материалы III Всероссийской научно-практической конференции с международным участием (9–11 февраля 2016 г.): в 2 ч. Ч. 2 (М–Я). Казань: Ихлас, 2016. С. 378–383.

*Шкляева Л.М.* Искусство вышивки татар Самарской области (по результатам экспедиции в июне-июле 2014 года) // Материалы II Всероссийской научно-практической конференции с международным участием «Традиционная культура народов Поволжья» (10–12 февраля 2015). Казань: Ихлас, 2015. С. 659–666.

*Шкляева Л.М.* Народное искусство домовой резьбы у татар Среднего Поволжья середины XX – начала XXI века. Семантика и стилевые особенности. Казань, 2017. 141 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 78

***Э.М. Галимова***

# СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ ҺӘМ МУЗЫКА

Творческое наследие поэта, переводчика и общественного деятеля Сагита Сунчелея бесценно. В данной статье автор раскрывает особенности музыкального и композиторского таланта Сагита Сунчелея, интересные факты из личной жизни поэта, который смог овладеть нотной грамотой и разработать собственные «упражнения» по теории музыки. Необходимо отметить, что Сагит Сунчелей был активным общественным деятелем и всегда имел свое принципиальное мнение, касающееся всех областей культуры и искусства.

**Ключевые слова:** Сагит Сунчелей, поэт, переводчик, общественный деятель, композиторское творчество, культура, искусство.

The creative heritage of the poet, interpreter and public figure Sagit Suncheley is priceless. In this article, the author reveals the features of Sagit Suncheley's musical and compositional talent, interesting facts from the poet's personal life, who was able to master musical notation and develop exercises on the theory of music. Sagit Suncheley was an active public figure and always had his own fundamental opinion concerning all areas of art.

**Keywords:** Sagit Suncheley, poet, interpreter, public figure, composer creativity, culture, art.

Габдулла Тукайның фатихасын алган Сәгыйть Сүнчәләй әсәрләре XX гасыр башы татар әдәбияты казанышлары рәтендә бик хаклы рәвештә үз урынын били. Әйтергә кирәк, С. Сүнчәләйнең иҗади мирасы – ул, һичшиксез, күпкырлы әдәби күренеш һәм бүгенге көндә ул әле бик аз өйрәнелгән.

Күренекле татар шагыйре, тәрҗемәче, драматург, җәмәгать эшлеклесе С. Сүнчәләй белән Г. Тукайны дуслык җепләре бәйләве турында күп кенә чыганакларда искәртеп үтелә. Бу аралашуның С. Сүнчәләй иҗатына, дөньяга карашларына, фикер йөртүенә уңай йогынты ясаганлыгы көн кебек ачык. Г. Тукайга мөрәҗәгать итеп язылган «Азан», «Хат кисәге», шагыйрьнең вафатыннан соң иҗат ителгән «Тукай хатирәсе», «Инеш», «Г. Тукаев», «Мәрхүм Тукаевка», дип исемләнгән шигырьләре С. Сүнчәләйнең Тукайга олы хөрмәтен һәм аның иҗатын эчкерсез яратуын чагылдыра. Гомумән алганда, Сәгыйть Сүнчәләй әсәрләре лирика белән сугарылган көндәлекне хәтерләтә. Аның иҗатында табигать матурлыгы белән хозурлану чагыла. Шул ук вакытта ул мәхәббәтнең иң тирән хис булуын, һәр кешегә дә яшәү мәгънәсен табу зарурлыгын ассызыклый. Шигъриятендә төп лирик геройны ялгызлыктан интегүче шәхес итеп күзаллый һәм шул фикерне уздыра да.

Ә сәнгатьне С. Сүнчәләй аерым бер сихри көчкә ия булган дөнья итеп күз алдына китерә. Сәгыйть скрипкада һәм мандолинада оста

уйнаса, абыйсы бик яхшы гармунчы була. Истәлекләргә күз салсак, Риза Ишморат ике бертуганның Сараштa (Пермь өлкәсендәге татар авылы) яшәү вакытларын сурәтләгәндә, Шәрифҗан һәм Сәгыйть тормышында җыр һәм музыканың зур урын алып торуы хакында яза. Гомумән, кече Сүнчәләй гомере буе музыкага гашыйк булып яшәгән, үзе уйнап, үзе җырлау белән генә канәгатьләнмичә, сәнгать өлкәсенә кагылышлы оештыру эшләрендә бик теләп катнашкан [Сүнчәләй, 2005].

Мисалга 1921 елның 11 гыйнварында улы Таһирга язган бер хатыннан өзек китерик: «Хәзер мин бөтен Кырым татарларының китапханәләрен, халык йорты, клуб, театр-фәләннәрен карау өстенә, зурлар өчен һәр җирдә уку йортлары ачарга, китаплар бастырырга тиешлемен. Татарча театрлар да уйната башладым. Драма мәктәбе, музыка мәктәбе ачтырдым. Үзем яхшы гына бер бүлмәдә торам. Бүлмәмә пианино алдыртырга торам әле, кичләрен уйнарга вә сине сагынырга. Мондагыларның театрлары әлегәчә гел биюдән гыйбарәт булган дияргә мөмкин. Мин үземнең «Иман», «Музыкант», «Рахиль – күз яше» кебек пьесаларымны төрекчәгә әйләндереп уйнатырга хәзерләшәм һәм бастырырмын да, бәлки».

Әйтергә кирәк, 1918 елның 25 мартында Уфада чыккан «Көрәш» газетасы С. Сүнчәләй рәислегендә «Татар әдәбияты һәм музыкасы җәмгыяте» төзелү хакында хәбәр итә. Шул ук вакытта, С. Сүнчәләйнең 20 нче елларда сәнгатькә, музыкаль тормышка бәйле җаваплы вазифалар башкаруы да аның күп кырлы шәхес булуы хакында сөйли.

Чыганакларда күрсәтелгәнчә, С. Сүнчәләй – композиторлык сәләтенә ия булган, ноталар яза белгән һәм ул заман татар шагыйрьләре арасында үз сүзләренә көйләр язып, аларны халыкка яңгыраткан бердәнбер иҗат кешесе.

С. Сүнчәләй беренче хатыны Сәлимәгә багышланган шигыренә көй дә иҗат иткән. Риза Ишморат сүзләренә караганда, ул җырны татарның беренче романсы дип тә атаганнар. Сәгыйть аны бик моңланып җырлаган һәм скрипкада бик яратып уйный торган булган. Музыкага, сәнгатькә гашыйклыгы аның инструменталь әсәрләренә дә үтеп кергән. Шуның бер дәлиле – «Сәнгатьчеләр» пьесасы. Шулай ук «Таң алдыннан», «Скрипка моңнары» дип исемләнгән сәхнә әсәрләренең эмоциональ-эстетик дөньясы да музыкага нисбәтле мотивлар, алымнар белән чагылдырылган. Истәлекләргә, хатлардан алынган мәглүматларга караганда, Соловкида вакытта С. Сүнчәләй лагерьдагылар өчен уздырыла торган концертларда чыгыш ясаган, кайчак рояльдә үзе язган көйләрне уйнаган, татар, башкорт җырларын башкаручыларга аккомпаниаторлык иткән. Истәлекләрдә Сүнчәләйнең «Моңсыз үтте яшьлегем» җырын яхшы һәм моңлы итеп башкаруы турында әйтелә.

С. Сүнчәләйнең музыкага, татар җырчыларының иҗатына булган мөнәсәбәте, мәдәният өлкәсендәге иҗтимагый эшчәнлеге аның тарафыннан язылган мәкаләләрдә дә чагылыш таба.

Мәсәлән, С. Сүнчәләй «Музыкабыз» исемле мәкаләсендә (Йолдыз. 1914. 11 апр.) граммафон язмалары, ир-ат җырчылар һәм хатын-кыз җырчылар турында сүз алып бара һәм үтә нык тәнкыйть күзлегеннән карый. Аерым алганда, Мәрьям Искәндәрова, Мәхмүзә Булатова, Нәфисә Пуснякова, Мирфәйзә Бабаҗанов, Камил Мотыйгыйлар иҗаты турында кызыклы фикерләрен җиткерә.

Истәлекләрендә Мәхмүзә Булатова һәм аның иптәшләренең тавышлары ямьсез, һич уйнатырлык, җырлатырлык түгел дип, татарның газиз көйләрен хур итеп, мыскыллап җырлаулары хакында яза. Бигрәк тә ул «Тәфтиләү», «Сакмар», «Тәскирә», «Кара урман», «Әллүки», «Ашказар» җырларын ярата. Хатын-кыз җырчылардан көмеш тавышлы Мәрьям Искәндәрова һәм нәрсә җырлаганын белеп җырлаучы «музыкальный ханым» – Нәфисә Пуснякованы мактый.

Ир-ат җырчылар арасында С. Сүнчәләй Мирфәйзә Бабаҗанов турында хатын-кызларга хас нечкә тавыш белән җырлый, дип билгеләп үтә: «Шул ук вакыта Бабаҗанов тәкъдир ителерлек җырчы ул. Аның «Фазлуш», «Карлыгач» вә бүтән көйләрен, «Фани дөнья» атлы мөнәҗәтен ихтыярсыз кат-кат тыңлыйсы килә. С. Сүнчәләйнең Камил Мотыйгый турында да бик кызыклы фикерләре бар: «Аның тавышында татар моңы гомумән юк, татар аһәңе юк. Ул урысчага тарта. Озын көйләребезне бозып җырласа, кыска көйләребезне гаять ямьсез җырлый. Аның бәгъзе бер урысчадан урлаган көйләре бар, мәсәлән: «Нәрсәдә ләззәт?», «Кемне сөяргә» (Тукай шигырьләре). Бу шигырьләрне урысчарак көйләргә тартып җырлый. Аңардан күп нәрсә көтә алмыйбыз», – дип нәтиҗә дә чыгарып куя.

С. Сүнчәләй әйтүенчә, музыкага өйрәнергә беркайчан да соң түгел, ул бу фикерне кызы Таһирәгә язган хатларында да җиткерә. С. Сүнчәләй язган нота кульязмаларына күз салсак, анда да кызыклы гына мисаллар бар. Музыка теориясен үзләштерү өчен язылган «Өйрәнчекләр» (Упражнения), «Ихтилал», «Пионерлар маршы», «Таһир» исемле улына атап язылган җыр, скрипка һәм мандолина өчен көйләр әдипнең музыка өлкәсендә ныклы белемгә ия булуы хакында сөйли. С. Сүнчәләй тарафыннан язылган әлеге җырларны һәм нота-ларны анализласак, аларның татар халык җырларының йөзек кашы булган «озын көй» жанрына стилистик яктан якынлыгы ачык күренеп тора. Билгеле ки, С. Сүнчәләй һәм композитор С. Сәйдәшев бер дәвердә иҗат иткәннәр. Шуңа күрә С. Сәйдәшев музыкасы әдипкә зур йогынты ясаган. С. Сүнчәләй язган җырларда, музыкаль әсәрләрдә интонация, ритм төзелеше, гармония кулланылышында «Сәйдәшев алымнарын» сиземләргә була. Классик музыканың төп жанрларыннан «Марш», «Вальс» стилендә С. Сүнчәләй тарафыннан иҗат ителгән инструменталь көйләрнең шактый булуы ачыкланды. Шулай ук, С. Сүнчәләйнең кульязма ноталарын барлагач, алар арасыннан революция чорында бик актуаль булган «Интернационал» һәм матәм маршы буларак билгеле «Вы жертвою пали» җырлары табылды. Әлеге матәм маршын революционерлар һәлак булган иптәшләрен соңгы

юлга озатканда җырлаганнар. Шулай ук, тарих битләренә күз салсак, әлеге «Вы жертвою пали» җыры 1906 елда Кронштадт фетнәсендә катнашкан матрослар тарафыннан атып үтерелү алдыннан башкарылган. Димәк, С. Сүнчәләй әлеге революция чоры җырларын нотага салган, һәм аккомпаниатор буларак, аларны уйный да белгән.

XX гасыр башының танылган шагыйре, ялкынлы публицисты, тәрҗемәчесе, җәмәгать эшлеклесе С. Сүнчәләйнең тормыш юлы һәм иҗаты белгечләребездә зур кызыксыну уята. Бүгенге көндә әдипнең әдәби һәм музыкаль мирасын барлау, фәнни яктан тирәнтен өйрәнү эшен дәвам итү һәм киң җәмәгатьчелеккә таныту зарур.

**Әдәбият**


Вакыт. Оренбург, 1906–1914 еллар.

*Галиуллин Т.Н.* Егерменче еллар татар шигърияте // Мирас. 1997. № 5. Б. 5–27.

*Ишморат Р.* Сәгыйть Сүнчәләй // Яшь ленинчы. 1977. 15 январь.

*Камалиев Т.С.* Поэмы Сагита Сунчалея // Материалы IV конференции молодых научных работников. Казань, 1976. С. 68–70.

*Мусабәкова Р.Р.* Сәгыйть Сүнчәләй иҗатында ялгызлык мотивлары // Словесность. Приложение к «Вестнику Башкирского государственного педагогического университета. Серия гуманитарных наук». Вып. 2. Уфа, 2000. С. 87–93.

*Мусабәкова Р.Р.* Тукай һәм Сүнчәләй // Идел. 2001. № 4. Б. 29–30.

*Рәмиев З.* Тукай чордашы // Шәһри Казан. 1999. 13 август.

Сәгыйть Сүнчәләйнең иҗат мирасын туплау // Совет Татарстаны. 1958. 14 октябрь.

Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 90 ел // Казан утлары. 1979. № 8. Б. 77–78.

*Сүнчәләй С.* Әсәрләр һәм хатлар / төз., текстларны, иск. һ. аңлатмаларны әзерләүче Зөфәр Рәмиев; ТР ФА, Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 367 б.



***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 7. 041.5

***Е.Ф. Савченко***

# РӘССАМНАР ИҖАТЫНДА СӨЕМБИКӘ ПОРТРЕТЛАРЫ

Статья посвящена портретам царицы Сююмбике. В исторической справке: правление, низложение с трона и дальнейшая судьба. Доводы исследовавших, в пользу того, что парсуна XVII века не является портретным изображением царевны и ее окружения убедительны. Так, отсутствие изображения, выполненного «с натуры» (т.е. при жизни и объективно отражающего физический облик), или копии такового, создает явление, что в каждом случае портрет Сююмбике – это художественный вымысел. И мастер-портретист бессознательно наделяет ее образ чертами своего эстетического идеала. Проанализированы некоторые работы авторов: Б. Урманче, И. Зарипова, Н. Хазиахметова, А. Хамидуллина. Выбор их не случаен, так как эти художники наиболее оригинально и высокохудожественно справились с задачей изображения женщины, ставшей не только центральной фигурой давно прошедшей эпохи, но и в наши дни порождающей легенды.

**Ключевые слова:** портрет, Сююмбике, исторический портрет, татарская культура, эстетический идеал, художники Татарстана.

The article is dedicated to portraits of tsaritsa Suyumbike. In historical reference: reign, dethronement and further destiny. The arguments of the researchers, in favor of the fact that the 17th-century parsuna is not a portrait image of the tsaritsa and her entourage are convincing. Thus, the absence of an image painted “from nature” (that is, during life and objectively rendering the physical appearance), or a copy of it, creates the phenomenon that in each case the portrait of Suyumbike is an artistic fiction. And a portrait painter unconsciously gives her image the traits of his own aesthetic ideal. Some works of the authors were analyzed: B. Urmanche, I. Zaripova, N. Khaziahmetova, A. Khamidullina. Their choice is not accidental, as these artists in the most original and highly artistic manner have dealt with the task of depicting a woman who has become not only the central figure of a bygone era, but also nowadays generating legends.

**Keywords:** portrait, Suyumbike, historical portrait, Tatar culture, aesthetic ideal, artists of Tatarstan.

Сөембикә – Сафагәрәй хан хатыннарының берсе. Сөембикә-ханбикә образы, гасырлар узса да, сәнгать әһелләрен дулкынландырудан туктамый, төрле бәхәсләр һәм тикшеренүләр өчен темалар тудыра, сәнгати уйдырма өчен зур потенциал биреп тора. Сөембикәнең портретын иҗат итү темасына әле нокта куелмаган, һәм вакытлар узу белән яңадан-яңа «карашлар» һәм аның образын яңача аңлау зарурлыгы актуальлеген югалтмый.

Легендага әверелгән һәм халык хәтеренә мәңгелеккә уелган татар ханбикәсе портретын рәссамнар ни рәвешле язалар соң?

Берничә тикшеренүченең позицияләрен карап үтик. Й.Г. Нигъмәтуллина, Карл Густав Юнгның (1875–1964) хезмәтләренә, аерым алганда, архетиплар теориясенә таянып, милли һәм гомумкешелек тормышының, тарихның иң борынгы чыганакларын ачыкларга омтылу, үткәннең һәм хәзергенең бердәмлеген тою идеясен алга сөрә. Бу тенденция архетиплар һәм мифемалар (мифологемалар) [Нигматуллина, с. 57] эзләү белән янәшә бара, ди ул.

Архетип – соңгы антик философиядә – прообраз, идея. Шуларның берсе анима – ир-аттагы гүзәллек башлангычы архетибы: «…в бессознательном мужчины, – дип аңлата К. Юнг, – существует унаследованный коллективный образ женщины, с помощью которого он постигает природу женщины». Анимус же – архетип «внутреннего мужского начала» в женщине, «есть своего рода осадок суммы опыта, полученного предками женщины по поводу мужчины» [Нигматуллина, с. 59]. Шул рәвешле, автор рәссамның артык аңсыз рәвештә портретлаштырылучы образларга билгеле бер сыйфатлар спектры бирүен нигезли.

Ханбикәнең тарихта сакланган сурәтләре булмавын исәпкә алып, әлеге фикер белән килешергә дә мөмкин. Билгесез рәссамның XVII гасырга караган «Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән» дип аталган парсунасы гына бар. Ул киндердә майлы буяулар белән башкарылган. Шулай ук теге яки бу дәрәҗәдә парсунаның сюжет һәм композициясен кабатлаган берничә сурәт – парсунадан күчермә, литография, офорт барлыгы билгеле.

Л. Девятых парсунада сурәтләнгән фигуралар – Сөембикә, шагыйрь Мөхәммәдьяр, Сөембикәнең кызы һәм Җангали, ә дүртенче фигура – сөт анасы дип фараз кыла [Девятых, с. 34–35]. Ә Маргарита Завьялова исә: «ситуация с позированием Сююмбике для портрета, представляется крайне нереальной», – дип раслый [Завьялова, с. 39]. Моны Л. Девятыхның хәзерге эмансипацияләнгән хатын-кызларның үз-үзләрен тоту нормаларын Сөембикәгә кайтарып калдыруы белән дәлилли, үз чиратында, ханбикә Урта гасырлар дәверендә яшәгән «…и была обязана и являлась в силу своего воспитания и положения примером мусульманской нравственности, в противном случае ее имя не сохранила бы история» [Девятых, с. 35], дип яза. Завьялова шулай ук, әсәрнең детальләрен анализлап, автор рус рәссамы булган, дип саный, әсәрне язу вакытына ул инде Казанда шактый озак яшәгән, һәм мөселман халкын «рухи нәкыш»не [Завьялова, с. 40] кабул итәргә өйрәтү өчен, җирле легендар ханбикәне сурәтләгән дигән фикердә.

Урта гасырларда ислам динендә һәртөрле портрет сурәтенең, мөселман хатын-кызларына йөзләрен һәм гәүдәләрен күрсәтүнең тыелуын исәпкә алсак, мәкалә авторы белән килешергә кирәк: портрет натурадан язылмаган, ягъни татар ханбикәсе рәссам алдында билгеле бер позада басып тормаган, димәк, парсуна гөман ителгән төркем портреты булып санала ала.

Рәссамнар тарафыннан гәүдәләндерелгән татар ханбикәсе образы сәнгатьчә уйдырма булып тора, һәм һәр автор Сөембикә портретын үзе күз алдына китергәнчә яза, вакытлар узу белән ул үзгәреш кичерә, глобаль стилистик тенденцияләр йогынтысын татый һәм методик яктан төрлечә якын килеп башкарыла. Башкару шулай ук күптөрле – чиста фантазияләрдән, һәм көчле гомумиләштерүдән алып үткәндәге чынбарлыкны яңадан торгызу өчен кирәкле детальләрне җентекләп сайлауга кадәр.

Аңсыз эшләнгән архетиплардан тыш, һәр уйлап табучы-рәссам үзенчә күз алдына китереп портрет язганда (Сөембикә портретлары да шундыйлардан) аңа эстетик идеал сыйфатлары да бирә дип расларга мөмкин.

А.И. Морозов эстетик идеал төшенчәсен түбәндәгечә аңлата: «Попытка воплощения идеала в любом случае требует от художника – ну, скажем предложить зрителю гипотезу относительно того, что должно восторжествовать в коллизиях действительности. Причем, конечно, раскрытие подобной жизненной перспективы тоже есть «путь познания». И здесь творческое воображение направляется объективными факторами. Эстетический идеал эпохи не рождается искусственно, он завоевывается, формируется открытием многих и многих качеств действительности, с той или иной стороны отвечающих представлениям времени о совершенстве. Именно поэтому мы говорим о поисках идеала, – говорим о широком процессе, в ходе которого идеальное постепенно воплощается различными гранями. И современный портрет также участвует в этом процессе, своими средствами раскрывая и обобщая ценностные представления нашей эпохи» [Морозов, с. 85].

Чыганакларга таянып, нәтиҗә ясыйбыз: эстетик идеал – объект турында бик әһәмиятле күзаллау, аның әһәмиятлелеге әсәр иҗат ителгән чорга карата билгеләнә.

Бакый Урманче тарафыннан 1978 елда агачтан ясалган «Сөембикә» сынын карап үтик. Бу скульптура турында төрле фикерләр бар. Й.Г. Нигъмәтуллина аның образын анима архетибы нигезендә анализлый һәм авторның образга «сизелер-сизелмәс монголоид билгеләре булган төрки хатын-кызларның антропологик билгеләрен» салуы турында әйтә [Нигматуллина, с. 60]. Т.Н. Кривошеева портретны классик принципларны импрессионистик эзләнүләр белән берләштергән скульптурага кертә [Кривошеева, с.115].

Б.И. Урманче скульптурасының нигезендә цилиндр формасы, аның бер өлешендә үтә нәфис хатын-кыз йөзе чокып ясалган, сынчы өслекнең зур өлешенә кагылмаган: бу – импрессионистик алым. Т.Н. Кривошеева билгеләп үткәнчә, мондый алым скульптура иҗат ителгән чорга хас һәм башка авторлар – С.Т. Коненков, Степан Эрзи, А.С. Голубкина иҗатында очрый [Кривошеева, с. 115].

Сөембикәнең йөзе детальләп һәм йомшак эшләнгән, йөзеннән ераклашкан саен, өслек агачның баштан ук табигатьтән бирелгән

шома төшенә омтыла, стека салган рельефлы, ачык беленеп торган киртекләр бит тирәли вибрацияләүче ритм тудыра, шул ук вакытта тамашачыга костюмны фаразларга мөмкинлек бирә. Баш киеме гаҗәеп зиннәтле, ныклап карасаң, анда үсемлек орнаментын һәм гарәп язуын да күреп була. Сөембикә, гүя, табигатьнең бер халәтен гәүдәләндереп йокыга талган, әмма аның йөзенә текәлебрәк карасаң, тыныч йокыдан тыш, кашларының аз гына җыерылуын күрәсең, җиңелчә җыерчыклар аның тирән борчулы уйларга батуына ишарәли.

Сөембикә еш кына улы белән бергә сурәтләнә – И. Зариповның эше дә әнә шундыйлардан. Шактый тыныч портрет. Ул рәссамның типик тасвирлауга якын килүен чагылдыра: яссы стильләштерелгән формалар, гомумиләштерелгән затлар, киндер өслегенең ачык күренеп торган фактурасы, кызгылт-көрән төстәге колоритның еш кулланылуы, арткы планда – архитектура фрагменты.

Н. Хаҗиәхмәтовның «Казан каласы – таш кала» график сериясендә кулына ак чәчәк тоткан Сөембикә төрле төсләргә кереп ялтыраган чынаяк кирпечләр фонында сурәтләнгән. Рәссам пумала ярдәмендә күптән үткән чорлар атмосферасын тудырып, әйләнә-тирә мохиткә аеруча зур игътибар бирә. Һәрбер яфрак җентекләп һәм югары техник осталык белән эшләнгән, анда очраклы детальләргә урын юк. Әмма «Үтәмешнең йокысы» картинасы үзенә бер төрле, ул бер үк вакытта символика белән өретелгән детальләрнең үтә нәфис эшләнеше белән аерылып тора. Композиция тыныч һәм статик, гомуми караңгы тон малайның йокы бүлмәсе атмосферасына алып керә, йокыга талган кеше өстендә – тәрәзә, аның артында шәһәр күренә. Тәрәзә артындагы киңлек – гүя балалар хыялы. Рәссамның мондый композицион чишелешне сайлавын символик рәвештә – беркайчан да хан булмаячак хөкемдарның йокысы, дип аңлатырга мөмкин.

Хәмидуллин А.Г иҗатында да дүрт полотнодан торган Сөембикәгә багышланган серия бар. Аларның икесе – тарихи портрет.

Картиналарның берсендә яшь хатынның алкасын салган вакыты сурәтләнгән. Сөембикәнең прототибы булып безнең замандашыбыз булган яшь кыз тора. Ханбикәне язар алдыннан рәссам аның берничә портретын ясаган. Ул якты йолдызлары һәм ае балкып торган төнге күк фонында утыра, фигураның артында сул якта да, уң якта да үтә күренмәле чаршаулар. Ул татар костюмы кигән, өстәлдә сулда – бизәнү әйберләре салынган ачык шкатулка һәм шәрык чүлмәге. Композицион үзәкне картина яссылыгы үзәгеннән бераз уңга һәм өскәрәк күчкән йөз тәшкил итә, ул «алгы ягы белән» тамашачыга борылган, әмма җиңелчә генә сулга авышкан.

Героиняның ачык якты йөзле булуы тәэсирле дә һәм үзенчәлекле дә, йөзе нәфис, ияге тар, бигрәк тә күз формасы үзгә – Шәрык гүзәлләренекен хәтерләтә. Күз карашы тыныч, борчулы, тамашачыга төбәлгән. Йөзен өлешчә юка ак тукыма каплаган, укалап чигелгән һәм мех белән каймаланган баш киеме маңгаена ук төшеп тора. Баш киеме калфак формасында. Ул түгәрәкләнеп очланган һәм баш

түбәсенә мөселманнарның традицион символы булган ярымай куелган. Костюмның калфак кебек әлеге детале архитектура белән костюм арасындагы үзара бәйләнешне ассызыклый һәм тышкы яктан мәчет манараларының һәм легендар Сөембикә манарасының башын хәтерләтә.

«Сөембикә. Алтын читлектә» портреты исеменнән үк күренгәнчә, символик мәгънәгә ия. Гомуми тон ачык һәм яктырак булуга карамастан, бу портрет героиняның язмышы турында сөйли кебек. Бәян символлар – «сөйләүче» детальләр ярдәмендә тормышка ашырыла. Әйтик, Сөембикәнең ярымгәүдәсе һәм натюрмортның аны әйләндереп алган предметлары очлаеп тора торган арка эчендә бирелгән. Бу – мөселман корылмаларындагы тәрәзә формасы, шулай ук мөселман кабер ташларының традицион формаларыннан берсе. Арка тирәли зооморф орнамент уза: елан – җир һәм хатын-кыз башлангычы символы; бөркет – кошлар һәм күк стихиясе патшасы, шулай ук богаулардан азат булуны белдерә; каплан – җәнлекләр патшасы; соляр билге һәм үсемлек орнаменты. Аларны патшаларга хас билгеләр буларак аңлатырга мөмкин.

Натюрморттагы әйберләр героиняның алдагы тормышы турында сөйли: алтын читлек – муллык һәм тоткынлыкта булу символы, шкатулкадагы тавис – патша кошы сурәте, әмма ул, бөркеттән аермалы буларак, ирекле түгел, ә бизәк ролен генә башкара. Җиләк-җимеш салынган вазада яулап алу билгесе – уклары белән җайдак силуэты ясалган. Бу «сөйләүче» детальләр барысы да Сөембикәнең киләчәк язмышын бәян итәләр.

Л. Зингерның хезмәтенә мөрәҗәгать итик, биредә индивидуальлек һәм типиклык проблемасы карала, автор рәссамнарны «портретчыларга» һәм «портретчы булмаганнар»га аера [Зингер, с. 70]. «Если первый тяготеет к созданию более или менее индивидуализированного типа, то второй скорее склонен изображать более или менее типизированную индивидуальность. Это не игра слов, но отражение истинного состояния вещей, ибо если в непортретном образе ярче проступает начало типическое, то в портретном, наоборот, – индивидуальное…

Автор собирательного образа идет от общего к частному – от типического к индивидуальному. Сначала у него возникает отвлеченное представление о том или ином персонаже своего произведения как о типе…

А уже затем, в результате целенаправленных жизненных наблюдений и работы с натуры, этот персонаж конкретизируется, обретая более или менее четкую индивидуализацию…» [Зингер, с. 70]. Н. Хаҗиәхмәтов һәм Б. Урманченың тарихи портретта тулаем типик башлангычка караган әсәрләре шундыйлардан.

«У портретиста работа идет в обратном порядке – от частного к общему, от индивидуального к типическому. Вначале он представляет себе изображаемого человека лишь как данную конкретную, реально

видимую личность. И уж потом, …, сообщает образу некие общие, типические черты, делая его силой своего творческого воображения не только вполне определенной личностью, «этим», но вместе с тем и типом» [Зингер, с. 70]. А. Хәмидуллинның нәкышь сериясендә ике полотно типик башлангычка мөнәсәбәтле, мәкаләдә сүз барган тагын ике картина индивидуаль башлангычлы.

**Әдәбият**

*Девятых Л.* История одного портрета // Казань. 1988. № 7–8. С. 34–35.

*Завьялова М.К.* Красноречивые детали. Портрет глазами этнографа // Казань.1988, №7–8. С. 39

*Зингер Л.С.* Очерки теории и истории портрета. М.: Изобразительное искусство, 1986. 328 с.

*Кривошеева Т.Н.* Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиция. Казань: Отечество, 2013.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002.

*Морозов А.И.* Художник и мир личности. М.: Советский художник, 1981.

Эстетика: Словарь / под общей редакцией А.А. Беляева и др. М.: Политиздат, 1989.

***Савченко Екатерина Федоровна,***
*ТР ФА Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге аспиранты*

УДК 930.271

*А.М. Гайнетдинов*

# КАЗАННЫҢ ДАРЫ БИСТӘСЕ ЗИРАТЫ ТАШЪЯЗМАЛАРЫ

В статье представлен краткий анализ эпиграфических памятников, выявленных на кладбище Пороховой слободы города Казани. В ходе экспедиции, организованной Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ в 2017 г., автору удалось выявить и изучить 146 сохранившихся арабографичных намогильных камней, датируемых периодом с 1841 по 1933 гг. В статье публикуются тексты и переводы некоторых из них, которые представляют наибольший интерес.

**Ключевые слова:** татарская эпиграфика, памятники, некрополи, Казань, Пороховая слобода, кладбище.

The article presents a brief analysis of the epigraphic monuments identified in the cemetery of the Porokhovaya settlement in Kazan. During the expedition, organized by the Institute of History named after S. Mardzhani of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2017, the author was able to identify and study 146 preserved Arabographic gravestones dating from 1841 to 1933. The article publishes texts and translations of some of them that are of the greatest interest.

**Keywords:** Tatar epigraphy, monuments, necropolises, Kazan, Powder settlement, cemetery.

Башкалабыз Казандагы татар зиратларында сакланган ташъязма истәлекләр галимнәр тарафыннан ни өчендер тулысынча һәм тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, бигрәк тә Окольная урамында урнашкан Дары бистәсе зиратына бер эпиграфистның да кулы тимәгән иде. Шуның өчен андагы безнең көннәргә кадәр сакланып калган бөтен эпиграфик истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен, 2017 елда ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан фәнни экспедиция оештырылды.

Дары бистәсендәге татар зираты XIX йөз башында барлыкка килгән. Мәгълүм булганча, 1788 елда биредә Казан дары заводы төзелгән. Әлбәттә, анда бик күп эшчеләр кирәк булган. Шул сәбәпле, татарлар да шунда эшкә кергәннәр һәм биредә яши башлаганнар. Бигрәк тә Казан арты ягында, төгәлрәк әйткәндә, Биектау, Әтнә төбәгендә яшәүче татарлар бу бистәгә бик күпләп күченеп килгәннәр. Кеше саны күбәйгәннән соң, монда аерым бер торак пункт – Дары (Пороховой) бистәсе барлыкка килгән, ягъни аның атамасы шул ук Дары заводы белән бәйле. Бу торак пунктны шулай ук «Баруд яки Барудия бистәсе» дип тә йөрткәннәр, чөнки «баруд» сүзе гарәп телендә – «дары», ә «барудия» – «дарылы» дигәнне аңлата. Шуңа күрә атаклы дин галиме, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нәшир, журналист Галимҗан Мөхәммәдҗан улы Галиев (1857–1921) үзенә

Баруди псевдонимын алган, чөнки әлеге бистәдә үскән, шәхес буларак формалашкан.

Бистәдә татарларның саны арткач, әлбәттә, биредә мөселман зираты булдыру ихтыяҗы туган, чөнки мәетләрне Казанның ерактарак урнашкан башка татар зиратларына алып бару мәшәкатьле булган. Шул рәвешле, XIX гасыр башларында хәзерге Окольная урамында зират пәйда булган. Анда биредә яшәүче татарларны, Дары заводында, шул тирәдәге башка предприятиеләрдә һәм якындагы сәүдә пристанендә эшләүчеләрне, гаскәриләрне җирләгәннәр. Шул вакытларда мәчеткә дә нигез салынган. Мәрҗани язганча, бистәдәге әүвәлге мәчетне һиҗри белән 1222 елда, ягъни милади белән 1807–1808 елларда хәзерге Әтнә районы Олы Мәңгәр авылыннан Муса Монасыйп улы Адәмов салдырган [Мәрҗани, б. 118]. К. Насыйри исә биредә шул шәхес тарафыннан мәчет бераз соңрак – 1809 елда төзелгән, дип язган [Насыйри, б. 219].

Кызганычка каршы, Дары бистәсе зиратында XIX гасырның 40 нчы елларына хәтле куелган эпиграфик истәлекләр табылмады, ләкин бу факт әле аларның булмавы турында сөйләми. Беренчедән, бу чорда ташбилгеләр әле бик аз куелган, чөнки ташка язу сәнгате, өч гасыр диярлек торгынлык кичергәннән соң, үсә генә башлаган. Икенчедән, ул дәвердәге кабер ташлары табигатьнең кырыс шартларында ватылуга, җимерелүгә дучар булганнар, чөнки алар Казан ханлыгы чоры ташбилгеләре кебек нык һәм калын булмаган. Өченчедән, кайбер кабер ташлары авып, яфраклар, үләннәр белән капланып, туфрак астында калырга мөмкин.

Экспедициябез барышында Дары бистәсе зиратын эпиграфик планда җентекләп тикшергәннән соң, бу зиратта безнең тарафтан XIX гасырдан алып 1928 елга хәтле куелган гарәп язулы 146 борынгы кабер ташы (шул исәптән фрагментлар) табылды һәм өйрәнелде.

Бистә зиратында сакланган иң борынгы эпиграфик истәлек 1841 елга карый. Ул Әхмәди Габдерәхим улы каберенә куелган. Таштагы текстның укылышы:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Румиййә берлән меңдә сигез йөз кырык
2) беренче йылда гыйнварның тукызынчы көне
3) Әхмәди Габдеррәхим углы кырык йәшендә
4) даре фәнадан даре бәкайә васыйл улды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

1) «Милади белән мең сигез йөз кырык
2) беренче ел гыйнварының тугызынчы көнендә
3) Әхмәди Габдерәхим улы кырык яшендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга иреште».

Таш үлчәмнәре: 55×33×14.

Шулай ук 1843 елда вафат булган Маһи Рәхмәтулла кызына куелган кабер ташы да иң борынгылардан саналырга хаклы. 1845 елда

үлгән Муса Яхъя улына, 1846 елда бакыйлыкка күчкән Хөснеҗамал Ихсан кызына куелган эпиграфик истәлекләрнең табылуы да безнең өчен куанычлы булды, аларның текстларына әле артык зыян килмәгән. Бәхеткә каршы, XIX гасырның 50 нче елларында куелган кабер ташлары да чагыштырмача күп сакланган. Тик менә шул ук йөзнең 60 нчы елларында ни өчендер каберләргә сыйфатлы итеп эшләнгән ташлар кую гамәле сүлпәнәеп киткән, әмма 70 нче еллардан бу традиция, тагын көчәеп, зират ябылганчыга, ягъни XX йөзнең 60 нчы елларына кадәр дәвам иткән. Соңыннан, каберләр белән тулу һәм аны зурайту мөмкинлеге булмау сәбәпле, каберстан ябылган һәм анда җирләү тыелган. Хәзерге көндә зиратның территориясе 6,76 гектар тәшкил итә. Җирле халык сөйләвенчә, элегрәк ул күпкә зуррак булган, йортлар төзү сәбәпле генә кечерәйгән. Сугыш вакытында зират янында хастаханә эшләгән һәм анда вафат булучыларны, милләтенә карамыйча, шул мөселман зиратына җирли торган булганнар. Шуңа күрә аның көнчыгыш ягында рус, яһүд h. б. милләт кешеләренең каберләрен күп очратырга мөмкин.

Дары бистәсе зиратында атаклы дин әһелләренә куелган кабер ташлары да табылды. Мәсәлән, 1874 елда бакыйлыкка күчкән Габдерәкыйб Габделмөэмин мулла улына куелганы шундыйлардан. Таштагы текстның укылышы:

1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мөхәммәдүр-расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
2) саахибү һәзәәл-кабри би-хүкми...
3) гафүввә Раббиһи Габдеррәкыйб бине мулла Габделмөэмин
4) вә кад интәкалә мин дәәрил-фәнәәъи иләә дәәрил-бәкааъи җәннәтилләәһ
5) дәәрүл-вәфәәъи... сәнәтә ихдәә вә тисгыйнә
6) вә миъәтәйни вә әлфин мин һиҗрати мән кәәнә ләһү биҗәмәәлил-гыйззи
7) вәш-шәрәфи вә кәәнә гумруһү әрбәга вә сәбгыйн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:

1) «Аллаһтан башка табынуга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен).
2) Бу кабер иясе [Аллаһ] хөкеме белән...
3) Раббысы кичерүенә Габдерәкыйб бине мулла Габделмөэмин,
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга, Аллаһ җәннәтенә,
5) тугрылык йортына... камил дәрәҗәдәге олылык һәм тулы хөрмәт иясе булган зат [Мөхәммәд пәйгамбәр]
6) һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән] соң мең ике йөз туксан беренче елда
7) күчте, гомере 74 яшь иде».

Таш үлчәмнәре: 100×34×17.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габдерәкыйб бине Габделмөэмин бине Габдерәхим бине Габдрахман [Фәхретдин, 2 том, б. 143] бине Мөхәммәд [Мәрҗани, б. 298]. Чыгышы хәзерге Әлмәт районы Габдрахман авылыннан. Ш. Мәрҗани аның вафат булу датасын төгәл ачыклаган: һиҗри 1291 елның 8 җөмадиәл-әүвәле, ягъни 1874 елның 23 июне (иске стиль белән) дүшәмбе көн, әмма, 70 яшендә үлгән, дип бераз ялгышкан [Мәрҗани, б. 120].

Бәйрәкә авылындагы мәдрәсәдә гыйлем алганнан соң, Габдеррәкыйб хәзрәт 1826 елның 11 ноябрендә указ (№ 32452) нигезендә үз авылында мулла һәм мөхтәсиб итеп билгеләнгән. Соңрак 1838 елның 29 июленнән башлап Дары бистәсе мәчетендә имам-хатыйп вазифаларын үти башлаган. Яхшы хезмәте һәм тырышлыгы өчен патша хөкүмәте Габдерәкыйб мулланы 1843 елда – көмеш, 1862 елда алтын медаль белән бүләкләгән. Сүз уңаеннан, Русия мөселманнарының икенче мөфтие Габдессәлам Габдерәхимов аның атасының бертуганы булган.

Дары бистәсенең иң мәшһүр муллаларының берсе булган дамелла Нургали хәзрәтнең кабер ташы, кызганычка каршы, табылмады, аның каравы, улы мулла Әхмәдҗанныкы сакланып калган. Таштагы текстның укылышы:

1) «Би-хүкмилләәһ
2) беренче мәхәлләи Барудиййәдә имам хафиз-
3) -ел-Коръән Әхмәдҗан дамелла Нургали
4) хәзрәт углы 42 йәшендә даре бәкайә күчде
5) рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ
6) җөмадиәл-ахирнең йидесендә
7) 1330 һиҗриййә / миладиййә 1913
8) майның 10 сында».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) беренче Баруд мәхәлләсендә имам, Коръәнне
3) яттан белүче Әхмәдҗан дамелла Нургали
4) хәзрәт улы 42 яшендә
5) (Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын)
6) һиҗри 1330 [елның] җиденче
7) җөмадиәл-ахирендә, миладиййә 1913 [елның]
8) 10 маенда мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 96 (104)×31×13.

Әлеге кабер иясе 1871 елның 12 ноябрендә туган. Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Әхмәдҗан бине Нургали бине Габдерәкыйб бине Габделмөэмин бине Габдерәхим бине Габдрахман [Фәхретдин, 3 һәм 4 томнар, б. 240] бине Мөхәммәд [Мәрҗани, б. 298]. Аның атасы да, бабасы да Дары бистәсе мәчетендә имам-хатыйп вазифаларын башкарганнар. Аның үзенә дә 1894 елның 29 июлендә указ (№ 1882)

бирелеп, атасы янына ярдәмче мулла итеп билгеләнгән [ТР Дәүләт архивы, б. 2–15].

1920 елда вафат булган мулла Габделбари Габделгани улы Мөэминовка куелган ташбилге дә саклanган. Аның ташының үлчәмнәре: 118×44×31.Текстының соңгы дүрт юлы кириллицада язылган. Әлеге кабер иясе 1860 елның 22 декабрендә дөньяга килгән. Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габделбари бине Габделгани бине Габдерәкыйб бине Габделмөэмин бине Габдерәхим бине Габдрахман [Фәхреддин, 2010, б. 240] бине Мөхәммәд [Мәрҗани, б. 298]. Габделбариның атасы Дары бистәсе мәчетендә мөәзин, бабасы имам-хатыйп вазифаларын башкарганнар. Ул үзе дә 1882 елның 19 октябрендә (указ номеры: № 7523) шул бистә мәчетенә мөәзин, 1912 елның 16 июнендә (указ номеры: № 3362) имам-хатыйп итеп билгеләнгән.

Шунысы кызык: хәзерге Әтнә районы Казак Үртәме авылында мулла хезмәтен башкарган Хәсән хәзрәт Мөхәммәдхәлим улы да Дары бистәсе зиратына җирләнгән. Ташыннан аңлашылганча, ул тумышы белән хәзерге Чүпрәле районы Иске Чокалы саласыннан булган, 1913 елның 16 декабрендә 66 яшендә ахирәткә күчкән. Таш үлчәмнәре: 114×36×15.

Шулай итеп, Дары бистәсе зираты эпиграфик планда өйрәнелде, гарәп язулы кабер ташларының һәрберсе ачыкланды, урыннары билгеләнде, фотога төшерелде, үлчәмнәре алынды һәм текстлары укылды. Кызганыч ки, хәзерге көндә зиратта байтак кыйммәтле ташъязма истәлекләребез ватылган, җимерелгән, аударылган. Аларны кулдан килгәнчә саклап калу чараларын күрү таләп ителә.

**Әдәбият**

*Мәрҗани Ш.Б.* Әл-кыйсмес-сани мин китаби мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. 268 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. 4 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 384 б.

*ТР Дәүләт архивы:* ф. 2, тасв. 2, сак. бер. 4897.

*Фәхреддин Р.* Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. 304 б.

*Фәхреддин Р.* Асар. 3, 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 648 б.

***Гайнетдинов Айдар Марсил улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 9-05

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# «НӘСЕЛЕМ – КАЗАННАН»: ТӨРКИЯ ЭШЧЕЛӘР ПАРТИЯСЕ РӘИСЕ БӘҺИҖӘ БОРАН (1910–1987)

В статье речь идет об одной знаменитой в Турции, но абсолютно неизвестной в Татарстане женщине – Бехидже Боран, чьи родители переселились в Стамбул и Бурсу в 1890-х гг. из Казани. Выпускница Мичиганского университета, доктор социологии Бехидже Боран стала одним из активных лидеров левого движения и возглавила Рабочую партию Турции. Ее антифашистские выступления, смелые демократические требования в прессе нашли отклик в широких массах и становились причиной для ее арестов и тюремных заключений. Научные труды Б. Боран, основанные на полевых исследованиях, а также политические идеи о равенстве, социальном устройстве общества и ныне сохраняют свою актуальность.

**Ключевые слова**: знаменитые татары, Бехидже Боран, политическая история Турции, социалистическое движение, Рабочая партия Турции.

This article tells the story of a woman who is famous in Turkey, but absolutely unknown in Tatarstan – Behice Boran. Boran's parents moved from Kazan to Istanbul and Bursa in the 1890s. A graduate of the University of Michigan and Doctor of Sociology, Boran became one of the active leaders of the left political movement in Turkey and headed the Workers' Party. Her anti-fascist speeches, bold democratic demands in press found a vivid response among the masses and became the reason for her arrests and imprisonment. Boran's scientific work, based on field research, as well as her political ideas about equality and social structure of society, still retain their relevance.

**Keywords:** famous Tatars, Behice Boran, political history of Turkey, socialist movement, Workers' Party of Turkey.

Төркиядә яшәгән күренекле татар хатын-кызларын барлау эше дәвам итә [кара: Сибгатуллина Ә., Сибгатуллина А]. Төркия җөмһүриятенең сәяси тарихында әһәмиятле роль уйнаган галимә һәм дәүләт эшлеклесе Бәһиҗә Боран ханымның татар асыллы булуын төрекләр үзләре дә бик белеп бетерми әле, безнең дә бүгенге көнгә кадәр шундый олы шәхес турында берни ишетми яшәвебез гаҗәп. Төркиядә социализм идеяләрен фәнни нигезгә куйган һәм аларны тормышка ашыру өчен гомеренең соңгы көннәренә кадәр көрәшкән, Төркия эшчеләр партиясенең (ТЭП) көчле лидеры Бәһиҗә Садыйка Боран, әти-әнисенең Казан татары булуын, 1890 елларда күченеп килүен танылган журналист Угур Мумҗуга (1942–1993) биргән интервьюсында [Mumcu, 16–17] үзе сөйли: «Казаннан... Кырымнан түгел», – дип тә төгәлли хәтта. Әти-әнисенең гаиләләре Төркиягә төрле юллар белән аерым-аерым килеп урнашуын, әнисенең Истанбулдан Бурсага «килен булып төшүен» дә әйтә.



Бәһиҗә Боран. 1980 еллар
*Фото http://bianet.org/biamag/yasam/159091-fotograflarla-behice-boran сайтыннан алынды*

Тууының 110 еллыгы уңаеннан Бәһиҗә Боран шәхесе хакында татар укучыларына да бернинадәр мәгълүмат бирү кирәкледер дип саныйм.

Бәһиҗә 1910 елда Бурса шәһәрендә Садыйк әфәнде белән Маһирә ханым гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Урта хәлле сәүдәгәр Садыйк әфәнде ашлык алып-сатып көн итә, үз заманы өчен шактый укымышлы булган әти кеше, Бәһиҗәнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Казан татарларына хас булганча», кызларының белемле булуына, чит телләр өйрәнүенә аеруча игътибар бирә, мәсәлән, олы кызын Бурсадагы француз мәктәбендә укытырга тели, ул ябылгач, дарелмөгаллимәткә бирә. Лицей бетергән улын да Истанбулда югары сәүдә мәктәбендә укыта.

Беренче бөтендөнья сугышы бетеп, Төркиядә милли-азатлык көрәше барганда, Бурса шәһәре греклар кулына күчә, Садыйк әфәнде гаиләсе белән Истанбулга күченергә мәҗбүр була. Башлангыч белемен Бурсада алган Бәһиҗә монда француз мәктәбенә керә, ул ябылгач, Американ кыз колледжына күчә, 1927 елда урта мәктәп, 1931 елда лицей программасын уңышлы тәмамлап, Истанбул университетының фәлсәфә бүлегендә белем ала башлый. Шул ук вакытта илдәге наданлыкны бетерү эшенә үзеннән өлеш кертер өчен, ватанпәрвәр кыз педагогик хезмәт юлын да башлап җибәрә. Балаларга чит телләр өйрәтеп йөргән Бәһиҗә Садыйканы, университетны тәмамлавын дә көтеп тормыйча, Маниса якларындагы авылларның берсенә укытырга җибәрәләр. Озак та үтми, көтелмәгән бер куанычлы хәл була: аның исеменә Америкадан махсус чакыру килеп төшә. Әле колледжда укыган вакытта ук аның бик тырыш булуын аңлап алган америкалы педагогларыннан берсе, аның исемен Мичиган университетында ачылган стипендияле уку курсларына яздырган була, һәм шулай итеп ул АКШка юл тота. Мичиган университетының социология бүлемен тәмамлый, 1939 елда исә фән докторы исемен ала, Америкада мондый югары гыйльми дәрәҗә алучы, бәлки, беренче төрек-татар хатынкызы була. Марксизм-ленинизм, социализм идеяләре белән якыннан кызыксынуы шул студент чорларында көчәя. Төркиягә кайткач, Әнкара университетында социология фәне буенча доцент дәрәҗәсе алып, фәнни-педагогик хезмәт белән шөгыльләнә башлый. Дәресләрендә студентларны мөстәкыйль фикер йөртергә, мәгълүматны тәнкыйть күзлегеннән кичереп кабул итәргә өйрәтә, аның лекцияләрен

тыңлар өчен хәтта башка уку йортларыннан да килүчеләр күп була. Анадолу авылларындагы иҗтимагый тормышны анализлаган китап һәм мәкаләләр бастыра, социология өлкәсендәге фикерләре халыкара күләмдә кызыксыну уята. Шул елларда әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә күп яза, Европа әдәбиятының күренекле шәхесләрен (Шарлотта һәм Эмили Бронте, Уильям Теккерей, Джеймс Джойс, Вирджиния Вульф һ.б.) беренчеләрдән булып төрекләргә таныта. Төрек авторларының әсәрләрен исә «сәнгать сәнгать өчен түгел, сәнгать – җәмгыять өчен» принцибыннан чыгып анализлый һәм әдәбиятта реализм агымы хакында үзенчәлекле, социология фәне югарылыгыннан чыккан карашларын тәкъдим итә. Шигырьләр дә язган Бәһиҗә Боранның әдәби тәнкыйть язмалары вафатыннан соң аерым бер китап булып басылып чыга [Boran].

Бәһиҗә Боранның зур сәясәт белән актив шөгыльләнә башлавы Икенче бөтендөнья сугышы чорына туры килә, 1942 елда ул Төркия коммунистлар партиясенә (ТКП) керә һәм төрек идарәчеләренең нацистлар Германиясе белән хезмәттәшлек итүенә каршы оештырылган протест чараларында катнаша. Төркия яшьләр оешмасы һәм Прогрессив демократ яшьләр оешмасы кебек органнарда әйдәп баручы була, илдә антифашистлар хәрәкәтен куәтләгән чыгышлар ясый. 1941–1943 еллар арасында, Пәртәв Наили Боратав, Ниязи Бәркәс, Шәриф Башоглу кебек күренекле төрек галимнәре белән берлектә, Бәһиҗә ханым «Ватан һәм дөнья» (Yurt ve Dünya), аннан соң «Адымнар» журналларын чыгара. Мәкаләләрендә сәяси карашларын фәнни теорияләргә нигезләп аңлата. Төркиядә ул чорда даими үзгәреп торган сәяси шартлар тәэсирендә бу матбугат органнары ябылгач, «Милли шеф» режимына каршы оппозициядә торган «Таң» газетасы һәм «Карашлар» (Görüşler) журналында, үз фикерләрен ачыклап, язмалар бастыра. Идеяләре рәсми хакимият ияләренең карашлары белән туры килмәү аркасында, «коммунизм пропагандасы таратуда» гаепләнеп, 1945–1946 елларда эше мәхкәмәләрдә тикшерелә һәм 1948 елда сәяси бер карар нәтиҗәсендә педагогик хезмәтенә чик куела. Аның белән бергә көрәшкән ир-атлардан Боратав, Бәркәс чит илгә качарга мәҗбүр булалар, Бәһиҗә ханыма да төрле илләрдән укытырга чакырулар килсә дә, ул туган җирен ташлап, беркая да китәргә теләми, мәхкәмәдә үз-үзен яклый алачагына ышана. Тормышында шушындый туктаусыз мәхкәмәләр, эзәрлекләүләр булып торган чорда, 1946 елда Бәһиҗә ханым кияүгә чыга: ире чиркәс (адыгей) асыллы Невзат Хатко (1911–1982) – Грециядә политехника университетында авыл хуҗалыгы бүлемен тәмамлаган, Греция коммунистлар партиясенең яшьләр оешмасында эшләгән кеше. 1938 елда Төркиягә кайткач та, төрек коммунистлар партиясе әгъзасы була, «Анадолу агентлыгында» тәрҗемәче булып эшли һәм грек теленнән Аристофан, Корнарос, Н. Казандзакис, С. Миривилис һ.б.ларның әсәрләрен тәрҗемә итә. Өйләнешкәч, алар дүрт кеше – икесенең дә әниләре белән бергә яшиләр. Сәяси карашлары аркасында, тиздән ирле-хатынлы икесе дә

эшсез калалар, матди проблемалар башлангач, Истанбулга күченәләр һәм хосусый тәрҗемә бюросы ачалар. Рәсми документлар белән берлектә, Бәһиҗә ханым инглиз теленнән әдәби әсәрләр дә тәрҗемә итә. 1946 елда төзелгән Төркия социалист эшче һәм крестьяннар партиясенә якын тора, бу партиянең баш органы сыйфатында чыккан «Сүз» газетасында мәкаләләр бастыра. Кызыл Армиянең фашизмны җиңүе, Советлар Союзының сугыштан соңгы эчке һәм тышкы сәяәте аның карашларының дөреслеген исбатлый, шуңа күрә фикердәшләренең саны да көннән-көн арта бара. Бу чорда күренекле шагыйрь Назыйм Хикмәт, язучылар Орхан Кәмал, Абидин Дино, Суад Дәрвиш, аның ире Решад Фуад Баранер, журналист Сәртәл һәм тагын бик күп зыялылар буржуазия диктатурасына һәм империалистик изүгә каршы көрәшүчеләр сафында булалар.

1950 елның җәендә Бәһиҗә Боран, иптәшләре белән берлектә, Төрек тынычлык сөючеләр җәмгыятен оештыра һәм җитәкли, бу җәмгыять хакимияттәге Демократлар партиясенең, парламент карары булмаган килеш, АКШ тарафын яклап, Кореяга гаскәр җибәрүенә каршы чыккан бердәнбер оешма булып тарихка кереп кала. Рәсми протест текстын язып-бастырып таратучылар, «милли мәнфәгатьләргә зарар бирүләре өчен», хәрби-сәяси суд тарафыннан хөкем ителә, бу мәхкәмәдә Бәһиҗә ханым ялкынлы чыгыш ясап, илдәге тынычлык яклы кешеләрне берләшергә чакыра, Кореяда барган сугышка чит илләрнең катышуын тәнкыйть итә. 15 айга ирегеннән мәхрүм ителгән Бәһиҗә икенче баласы Дурсунны 1951 елда төрмәдә таба (беренче баласы – кызы Әлиф бик кечкенә вакытта үлә). Бу елларда хөкүмәт илдә коммунистлар идеологиясен һәм хәрәкәтен юк итү өчен аяусыз чаралар үткәрә, төрмәдән яңа гына чыккан Бәһиҗә исә үзе сайлаган юлдан баш тартмый һәм, ТКП оештырган чараларда катнашкан өчен, 1953 елда тагын биш айга кулга алына. 1954–1960 еллар арасында гына ул, сәясәттән бераз читләшеп, өйдә утыра: улын тәрбияли, энисен һәм каенанасын карый, буш вакытларында әдәби әсәрләр һәм тарихи хезмәтләрне төрекчәгә тәрҗемә итү белән мавыга. Гомумән, кечкенә гәүдәле, әмма көчле рухлы Бәһиҗә ханымны якыннан таныган кешеләр аның гаять гаилә җанлы булуын, тәмле камыр ризыклары пешерүен, ә соңрак, ире Невзат-бәйне паралич суккач, аны яшь бала кебек каравын искә алалар.

Авыр икътисади кризис хәлендә булган Төркиядә демократия аерата кысрыкланган, протестлар кискен бастырылган, хөкүмәткә каршы язган матбугат аяусыз тыелган дәвер 1960 елның 27 маендагы гаскәри түнтәрешне китереп чыгара, нәтиҗәдә, Аднан Мендерес хөкүмәте бәреп төшерелә. Илдәге вакыйгалар, бигрәк тә яңа Конституция язу өстендә алып барылган эш Бәһиҗә ханымны бик өметләндерә. 1961 елның февралендә Төркия эшчеләр партиясе (ТЭП) корыла, аның сафына ватанпәрвәр интеллигенция әһелләре тартыла, партия рәисе Мехмет Али Айбар Бәһиҗә ханымны да үз партиясенә керергә өнди. Чакыруны кабул иткән Бәһиҗә Боран ТЭПнең уста-

вын төзүгә зур өлеш кертә, 1964 елдан башлап, партиянең җитәкче органнарында урын ала һәм, 1965 елда Шанлы Урфа шәһәреннән депутат итеп сайланып, Төркия Бөек Мәҗлесенә керә. 1965–1969 елларда ул парламентта, ТЭПнең тышкы сәясәте сүзчесе (спикеры) буларак, күп мәртәбә ялкынлы чыгышлар ясый. Аның эшсезлекне бетерү, эшсезләрне социаль яклау, ихтыяҗы булган крестьяннарга җир бүлеп бирү, авыл балаларын бушлай укыту, авыл мәктәпләрен арттыру кебек мәсьәләләрне күтәреп чыккан чыгышлары халык арасында теләктәшлек таба.

«Кара син минем шул хәлемә, – ди ул үзенең яшьлек дусларыннан берсенә. – Минем, кафедрада калып, укып-язып, дәрес биреп, укучыларым белән шөгыльләнеп, тар бер даирә кешеләр белән генә дус булып яшисем килә иде. Менә хәзер исә сәяси көрәшнең нәкъ уртасында торам, ничек бу эше башкарып чыгармын, кем белсен» [Urgan,125]. Һәм чынлап та, аның сәяси эшчәнлеге илдәге тотрыксыз хәләткә бәйле рәвештә, гаять тынгысыз һәм авыр була. 1966 елда ул эшчеләр партиясенең Икенче конгрессында мәркәз идарә бюросына керә, 1970 ел башында ТЭП секретаре итеп билгеләнә, шул ук елның октябрендә узган Дүртенче конгресста партиянең рәисе итеп сайлана. Бу елларда Бәһиҗә Боран сыйнфый көрәштә демократик методларны куллануны яклый, НАТО члены буларак Төркиянең Көнбатыш мәнфәгатьләренә тулысынча буйсынуын тәнкыйтьли, илдәге «көрд халкы проблемасын» хәл итүдә тар миллиятчелек сәясәтенең ни кадәр зарарлы булуын аңлатып чыгышлар ясый.

1971 елның 12 мартында исә илдә тагын түнтәрелеш була һәм шул елның июлендә ТЭПнең эше рәсми рәвештә туктатыла, Бәһиҗә ханым һәм партия идарәсендәге көрәштәшләре кулга алына, бу юлы да Б. Боран мәхкәмә барышында үзен хөкем ителүче түгел, хөкем итүче кебек тота, кыю чыгышлар ясый. 15 (!) елга хөкем ителсә дә, 1974 елның июлендә амнистия буенча азат ителгәч, ТЭПне яңадан коруга ирешә, мондый кыюлыгы белән илдәге демократик хәрәкәтнең куркыту белән генә бастырылмаячагын раслый, көрәшнең яңа юлларын һәм ысулларын эзли.

1979 елгы сайлауларда нигезе эшче сыйныфына таянган ТЭП элеккеге кебек күп тавыш җыя алмый, шуңа Бәһиҗә ханым партиянең стратегиясе өстендә аналитик эш алып бара, буржуазиягә каршы көрәштә социалист сул көчләрне берләштерү юлында яңа адымнар ясау, коммунистлар белән берләшү фикерен куәтли. «Бер фронт, бер партия!» девизы белән көрәшкә чакырган уртак бер китап бастырыла, ләкин бу идеяләрне тормышка ашырырга насыйп булмый, 1980 елның 12 сентябрендә чираттагы хәрби түнтәрелеш илдәге бөтен социалистик хәрәкәткә богау сала. Күпмедер вакыт үз өендә тоткын булган Бәһиҗә Боран бик көчле йөрәк өянәге кичерә, аның авыр хәленә бик кайгырган иптәшләре, сәяси эзәрлекләү беткәнче, аңа чит илдә яшәп торырга киңәш итә, ватанын бер дә ташлыйсы килмәсә дә, ул Бельгиягә китәргә мәҗбүр була. «Сәясәт эшенә керешкәндә, бар нәрсәне

күз алдында торган кебек идем: төрмәләрдә ятасымны, басым ясалачагын һәм башкаларны... ләкин җитмеш алты яшемдә чит илдә сөргендә яшәвем уема да кереп чыкмаган иде», – дип ачыклый ул үзенең соңгы интервьюсында [Mumcu, s. 7].

Бәһиҗә ханым, партиясе һәм үзе турында мәхкәмә эше тикшерелгәндә, ватанына кайтырга боерык ала, кайтмагач, 1981 елда рәсми рәвештә Төркия гражданлыгыннан чыгарыла. Сәяси качак вазгыятендә яшәгәнгә, Бельгия хөкүмәтеннән аз булса да, айлык акча ала, шуңа бик тыйнак тормыш алып бара. Дөнья сәясәте белән якыннан кызыксынып, көндәлек газеталарны укып бара, чит илдән торып, партиясендәге бердәмлекне сакларга тырыша, ике партияне (ТЭП һәм ТКП) берләштерергә омтыла, ләкин моңа ирешү бик җиңел булмый: ике якны да инандыру өчен Бәһиҗә ханым шактый күп көч сарыф итә. Ике партия бары тик 1987 елда гына берләшә һәм Төркия Бердәм коммунистлар партиясе (ТБКП) исемен ала, аның рәисе итеп, олы яшьтә булуына да карамастан, тагын Бәһиҗә Боран сайлана. Тик шул вакыйгадан соң ике көн узгач, 10 октябрьдә Брюссельдә Төркия эшчеләр сыйныфының сәяси көрәшендә ару-талуны белмичә, гомеренең соңгы көннәре кадәр әйдәп барган Бәһиҗә ханымның йөрәге тибүдән туктый.

Ул улына үзен ватанында, әгәр ул мөмкин булмаса, ире янында Болгариядә күмәргә васыять иткән була, Дурсун Хатко әнисен Төркиягә алып кайтырга рөхсәт ала, Әнкарада Бөек милләт мәҗлесе каршында һәм Истанбул мәркәзендә киң күләмле хушлашу чаралары үткәрелә. 45 ел буена тынычлык, сыйнфый тигезлек, җенси тигезлек өчен көрәшкән, кеше хокукларын яклаган социалист Бәһиҗә Боран бүген дә галимнәр һәм сәясәтчеләр тарафыннан даими искә алына, хезмәтләре буенча диссертацияләр, монографияләр языла. 2006 елда «Бәһиҗә Боран: соңгы сулышына кадәр» исемле документаль фильм төшерелде, Төркия иҗтимагый тарихын өйрәнү вакыфы (TÜSTAV) тарафыннан мәкаләләре, чыгышлары, әңгәмәләре, мәхкәмәләрдә сөйләгән сүзләре өч томлык китап итеп нәшер ителде. Җәмгыять белеме өлкәсендә Төркиянең иң көчле аналитикларыннан берсе саналучы Бәһиҗә Боранның гыйльми хезмәтләре, экпедицияләрдә ясалган күзәтүләргә нигезләнгәнгә, бүген дә актуальлеген җуймый, ә фикердәшләре, көрәштәшләре аның якты истәлеген кадерләп саклый.

**Әдәбият**

*Boran, Behice.* Bütün Yapıtları. I. Edebiyat Yazıları. İstanbul: Sarmal yayınevi, 1992.

*Mumcu, Uğur*. Bir Uzun Yürüyüş. İstanbul: Tekin, 1995.

*Urgan, Mina*. Bir Dinozorun Anıları. İstanbul, Yapı Kredi yay. 2013.

*Сибгатуллина Әлфинә.* Ультрамарафончы татар кызы // Мәдәни җомга. 2020. 4 февраль. *Сибгатуллина Альфина*. «Не забывайте татарский» // Татарский мир. 2020. № 2. февраль.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы, М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятлары институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

*Зәйнәп Максудова,*
*Шакир Абилов*

# ШАГЫЙРЬ СӨЛӘЙМАН САКСИНИ ҺӘМ АНЫҢ «ДАСТАНЕ МОГҖИЗАТ» ӘСӘРЕ (XII йөз)

Вниманию читателей предлагается архивная публикация совместной статьи татарских филологов позднесоветской поры – З.Г. Максудовой и Ш.Ш. Абилова, посвященной подробному изучению поэтического наследия Сулеймана ас-Саксини (XII в.). Авторы статьи, подготовленной к печати еще весной 1969 г., доказывают принадлежность сочинения «Дастан о [пророческих] чудесах» ас-Саксини и приводят скрупулезный анализ языка этого произведения. Важно отметить, что по мысли одного из авторов, З.Г. Максудовой, главной целью ас-Саксини в написании этого сочинения было описание образа идеальной личности мусульманина. Выводы, сделанные нашими старшими коллегами еще полвека назад, не потеряли своей актуальности и будут интересны современным исследователям.
**Ключевые слова:** исламская поэзия, Сулейман ас-Саксини, татарская филология, исламские рукописи, Саксин.

This is an archival publication of the article co-authored by the Tatar philologists of late Socialist era, namely Zainap Maksudova and Shakir Abilov. In their article, prepared already in spring 1969, the authors meticulously study the poetic legacy of the 12th century scholar Sulayman al-Saqsini. They argue that this scholar authored a work entitled *Dastan-i mu'jizat* and provide a detailed philological analysis of the text. Notably, one of the authors, Zainap Maksudova, claimed that the main goal of al-Saqsini in composing this poetical work was to describe an ideal type of Muslim personality. Observations made by these authors more than a half-century ago are still valuable and relevant for the ongoing research.
**Keywords:** Muslim poetry, Sulayman al-Saqsini, Tatar philology, Islamic manuscripts, Саксин.

## Кереш сүз[1]

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән фәнни мәкалә татар әдәбиятын өйрәнү тарихын яктырта. Соңгы гасырның 60 нчы еллары ахырында ук басмага әзерләнгән, әмма кулъязма рәвешендә генә сакланып калган мәкалә үз укучысын ярты гасыр дәвамында көтәргә мәҗбүр итте. Бүгенге көндә борынгы татар әдәбиятының күп кенә сәхифәләре дә бер серле пәрдә артында яшеренеп, аңа багышланган фәнни күзәтүләрнең зур өлеше архивларда, шәхси кулларда кала бирә. Чыннан да, борынгы тарихка

[1] This research is supported by the ERC Starting Grant «MIND: The Muslim Individual in Imperial and Soviet Russia». Эш барышында ярдәм күрсәткән Рәмзия ханым Абзаловага һәм Илһам абый Гомәровка ихлас рәхмәтләремне белдерәм.

ачыклык кертер өчен, беренче чиратта, безнең «хөрмәтле сәләфләребез»-нең эшләгәннәрен барлау зарур, чөнки төрле фәнни тармакларыбызның үз бай тарихы бар. Аны тирәнтән өйрәнмичә, әлбәттә, фән үсешен алга җибәрү авыр. Шуңа күрә, коллегаларыбыз күрсәткән юл белән[1] без дә фән тарихын өйрәнүгә үз өлешебезне кертергә тырышыйк[2].

Зәйнәп ханым Максудова (1897–1980) һәм Шакир ага Абилов (1915–2003) тарафыннан язылган күләмле мәкалә Татарстан Республикасы Милли музеенда – З. Максудова фондында саклана. Башка материаллардан аермалы буларак, әлеге мәкалә басмага тулаем әзер диярлек иде. Аның ни өчен үз вакытында дөнья күрмәве билгесез, ләкин мәкаләнең монографик характерда булуын һәм «торгынлык чорында» язылуын истән чыгармыйк. Хәер, шактый вакыт билгесезлек шәүләсе астында яткан фәнни күзәтүләрнең югары сыйфаты һич үзгәрмәгән, хәтта киресенчә: бу көннәрдә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан басмага әзерләнә торган Сөләйман Саксини әсәрләре җыентыгына[3] урынлы бер өстәмә һәм татар галимнәренең электән үк бу темага әһәмият бирүләренә бер дәлил буларак, мәкалә үз вазифасын тиешенчә үти.

Тәкъдим ителгән мәкаләнең төп фикере шунда ки, авторлар, махсус эзләнүләр нәтиҗәсендә, күптән билгеле булган «Дастаны Могҗизат» исемле шигъри әсәрне мәшһүр дин галиме Сөләйман Саксинигә нисбәтлиләр. Әлбәттә, бу мәсьәләдә фәндә төрле фикер булырга мөмкин, әмма хөрмәтле галимнәребез ясаган күзәтүләр һәм филологик анализ, һичшиксез, игътибарга лаек. Бигрәк тә шуны искәртергә кирәк: авторларның татар кульязма традициясен тирәнтен белүләре, филологик принципларга тугры булулары һәркемгә ачык билгеле. Нәкъ менә шушы филологик профессиональлек ягыннан фәнни сәләфләребезнең мирасы безнең өчен аеруча кадерле. Шулай да, совет чорында киң таралган кайбер фәнни карашларның тәэсирен дә искәртик. Мәсәлән, бу һәм башка мәкаләләрдә Зәйнәп ханым Максудованың борынгы татар әдәбияты тарихында секуляр мотивларны эзләвен, катлаулар көрәше контекстына кертүен, европоцентрик карашларны кабул итүен – боларның барысын да үз чорының сәяси мохите белән аңлатып була. Чынлыкта исә, Зәйнәп ханымның дингә дә, татар әдәбияты дөньясына да шәхси карашы күпкә катлаулырак һәм нечкәрәк иде[4], тик бу нечкәлекләрне шул вакыт таләпләре ачык күрсәтергә ирек бирмәде.

---

[1] Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2011. Б. 3; *Госманов М.Г.* Хәтер мизгелләре. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019.

[2] *Бостанов Ә.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 112–126; *Альберт Фәтхи.* Габделҗәббар Кандалый шигырьләре җыентыгы // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 151–170; *Альберт Фәтхи.* Үткән гасырларның шигъри сәхифәләре // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 149–166.

[3] *Гомәров И.Г.* Татар иляһият гыйлеме традицияләренең билгесез чыганаклары: Сөләйман бине Дауд әс-Суваринының «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәре // Фәнни Татарстан. 2019. № 4. Б. 50–54.

[4] Бу турыда тулырак: *Бустанов А.К.* Библиотека Зайнап Максудовой. М.: ИД Марджани, 2019.

Зәйнәп ханым Максудова фондында Сөләйман Саксини белән бәйле тагын биш саклау берәмлеге билгеле. Аларның берсе – галимнең «Зөһрәт әр-рийаз» әсәренең татарчага тәрҗемәсеннән өзекләр (гарәп графикасында)[1]. Икенчесен Максудова тарафыннан төзелеп, «Сөләйман бине Дауд ның тел байлыгы» дип исемләнгән карточкалар тәшкил итә[2]. Өченче материал фәнни мәкалә өчен әзерләнгән күзәтүләрне, чыганаклардан күчермәләрне һәм кайбер тәрҗемәләрне үз эченә ала[3]. Дүртенчесе – 1968 елда машинкада җыелган 56 битлек мәкалә варианты. Анда Зәйнәп Максудова тарафыннан ясалган шактый гына өстәмәләр һәм үзгәртүләр очрый, аларның барысы да гарәп хәрефләре белән язылган[4]. Бишенче һәм соңгы саклау берәмлеге аерым бер дәфтәрдән гыйбарәт. Ул – «Сөләйман бине Дауд Саксини әсәрләре: күчермәләр, тәрҗемәләр. Җыючы: Зәйнәп Максудова» дип исемләнгән (кызганыч, материалның җыю датасы куелмаган). Бу саклау берәмлеге аеруча әһәмиятле, чөнки монда галимәнең фәнни планнарының никадәр киң һәм җитди икәнлеге күренә. Аңлавыбызча, ул Саксини иҗатына багышланган китап әзерләргә тели һәм аның эчтәлеген түбәндәгечә тасвирлый:

1) «Тәрҗемәи хәле. Мосанниф хакында төрле галимнәрнең хәбәрләре буенча.

2) Саксин шәһәре хакында кыскача белешмә.

3) «Дастане Могҗизат» («Сирән-Нәби») китабы хакында мәгълүмат:

а) тышкы тәүсифе,

б) эчтәлеге,

в) теле, грамматик төзелеше, сүзлек составы, стиле, сүз бизәкләре, тасвирлау чаралары,

г) шигырь техникасы – вәзеннәре, кафияләре.

4) Кол Галинең «Йосыф Зөләйха»сы, нәмәгълүм шагыйрьнең «Кисекбаш»ы, Өмми Кәмал диваны һәм кабер ташларындагы язмалар белән чагыштырма.

5) Сөләйман бине Дауднең табылган башка әсәрләре.

6) Нәтиҗә – Сөләйман бине Дауд Саксини Идел буе төркиләренең XII йөз галиме, әдибе, шагыйре. Аның әсәрләре халык арасында сөелеп укылган, күп таралган»[5].

Әгәр дә дәфтәрнең эчтәлегенә күз салсак, бу планның зур өлеше монографик рәвештә чынга ашырылган. Дәфтәрнең язмалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 3а–11б кәгазьдә: Саксининең кыскача биографиясе һәм шигырьләре турында фикерләр; 19а–40а кәгазьдә: Казембек чыгарган «Дастане Могҗизат» китабының тулы күчермәсе; 41а, 42а, б кәгазьдә: «XII йөз Болгар-Саксин теле һәм әдәбияты мирасы, Таҗел-ислам шәех Сөләйман б. Дауд Саксини әл-Болгари әсәрләреннән «Дастане Могҗизат»

[1] НМ РТ 18369-353.

[2] НМ РТ 18369-354.

[3] НМ РТ 18369-356.

[4] НМ РТ 18369-355.

[5] НМ РТ 18369-358, л. 1б.

хакында»; 43а–45а кәгазьдә: «Әсәрнең назыймы хакында биографик белешмәләр»; 46а–49б кәгазьдә: «Сөләйман б. Дауднын дастаннарында кулланган аерым сүзләр-исемнәр»; 61б–71б кәгазьдә: сүз байлыгы (җәдвәлдә); 76б, 91а–93а кәгазьдә: «Сөләйман Саксини китабын төзүдә максаты нәрсәдә икән?»; 95б–96а кәгазьдә: «Саксин шәһәре хакында тарихи хәбәрләр»; 96б–97б кәгазьдә: «Сөләйман Саксининың әсәрләрендә имля нигезләре»; 98а–99а кәгазьдә: «Файдаланган әдәбият шәрык телләрендә, гарәп, фарсы, төрки». Исемлектән күренгәнчә, түбәндәге мәкалә – бик җитди һәм дәвамлы алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсе. «Фәнни Татарстан»ның алдагы саннарында бу фондтагы материалларның башка өлешләре дә дөнья күрер дип өметләнәбез.

*Әлфрид Бостанов*

Идел буе Болгар дәүләте культурасы мең еллар буена татар культурасының нигезе булып хисаплана. Асылда болгар-кыпчак булган, соңыннан билгеле тарихи шартларда башка исем белән аталып киткән Идел-Урал татарлары үзләренең гореф-гадәтләренең, гаилә-көнкүрештәге һәм идарә итүдәге тәҗрибәләренең, әдәбият һәм гомумкультура традицияләренең башлангычын һәрвакыт болгар дәвереннән хисаплады, шуннан үзенә рухи азык алды.

Шул дәвернең әдәби мирасы – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы («Йосыф китабы» яисә, соңгырак вакытта кабул ителгәнчә, «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы) татар халкын менә 737 ел буенча соклandырып килә. «Кыйссаи Йосыф» болгар-татар халкының культура үсеше тарихы, яшәеше белән аерылгысыз бәйләнгән. Азәрбайҗан әдәбиятын – Низамидан, Иранныкын – Фирдәүсидән, таҗикныкын – Рудаки, Җамидан, үзбәкнекен –Нәваидан, төрекмәннекен –Мәхтүмкулидән, грузинныкын Руставелидан башка күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, болгар-татар әдәбияты турында да Кол Галинең «Йосыф китабы»ннан башка фикер йөртү мөмкин түгел. Ул болгар-татар шагыйрьләренә шулчаклы йогынты ясаган ки, аның назымында – шигъри үрнәгендә дистәләрчә әсәрләр иҗат ителгән. Шулай итеп, «Кыйссаи Йосыф» болгар-татар поэзиясенең һәм әдәбиятының үсү юлында үзе бер зур тарихи чорны тәшкил иткән гүзәл ядкяр булып тора.

Болгарның алга киткән, культуралы дәүләтләрдән булганлыгы турында күп язылган. Х йөздә яшәгән тарихчылардан Ибне Рустә һәм әл-Бәлхи болгарларның игенчелек белән шөгыльләнеп, бодай, арпа, тары һ.б. шундый ашлыкларны игүләре турында сөйләп, аларның җамигъ мәчетле һәм мәдрәсәле Болгар һәм Сувар шикелле шәһәрләре булганлыкны язалар.

Гарәбстаннан һәм Харәземнән Болгарга дин генә түгел, культура, әдәбият та килгән. Ислам дөньясында һәр мәчетнең аерылгысыз юлдашы булып саналган мәктәп һәм мәдрәсәләрдә, дин дәресләре генә түгел, дөньяви белемнәр дә өйрәтелгән. Акча сугу ягыннан да Болгар Көнчыгыш Европада беренче шәһәрләрдән санала [Бартольд, 1963].

Асылда утраклыкта яшәү һәм игенчелек белән шөгыльләнү Болгарда хуҗалык ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен һөнәрчелекне тудырган: моның нәтиҗәсе буларак, иҗтимагый хезмәт бүленеше процессы болгарларда шәһәрләрнең тууына китергән. Болгарлар «кою ысулы белән корыч ала белгәннәр һәм аларның металл эшкәртеп, яхшы сыйфатлы әйберләр әзерләүче югары квалификацияле осталары булган» [Хлебникова, с. 8]. Бу хәл Болгар дәүләтендә, һөнәрчелекнең игенчелектән аерылып, мөстәкыйль рәвештә киң юл ала барганлыгы һәм иҗтимагый хезмәт бүленешенең шактый югары дәрәҗәгә ирешкәнлеге хакында сөйли.

Б.Д. Греков та: X гасырда болгарларда, җәй көннәре җәйләүләргә чыгуларына карамастан, шәһәрләр булган, аларда һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр даими яшәгәннәр, дип яза [Греков, с. 569]. Һөнәрчелекнең киңәюенә һәм шәһәрләрнең тиз үсүенә Болгарның халыкара сәүдә, культура мөнәсәбәтләренең олы юлы – Идел буенда урнашуы да зур ярдәм иткән, һәм X гасырлардан алып, Болгар халыкара зур базарга әверелгән [Смирнов, с. 39]. Бу – Болгарның экономика һәм культура ягыннан үсүенә зур этәргеч ясаган. Гарәп, һинд, фарсы, Урта Азия әдәбиятлары аша болгарлар борынгы юнан (грек) һәм Рим философиясе, культурасы белән дә танышканнар. Әнә шул культураларны үзенә кабул итәрлек социаль җирлек Болгар дәүләтендә җитешә алган була.

Биредә Болгар дәүләтендәге шәһәр культурасы мәсьәләсенә махсус тукталуыбызның сәбәбе шунда: чөнки бу «Йосыф китабы» авторы Галидән нәкъ бер гасыр алда, Болгар илендә иҗат иткән галим, әдип һәм шагыйрь Сөләйман Саксинины һәм аның әсәрләрен аңлау өчен дә кирәк.

«Идел болгарлары, – дип яза А.П. Смирнов, – Урта гасырларда Европадагы алдынгы дәүләтләр рәтенә керә һәм ул Киев, Бөек Новгород кебек мәркәзләр белән бер сафка куярлык» [Смирнов, с. 39]. Шундый культура дәрәҗәсенә ирешкән Болгарда шул заманга карата мөселман дөньясында билгеле фәннәрнең булуы, галимнәр һәм әдипләрнең яшәве, тарих, философия, хокук – юриспруденция һәм әхлак – мораль буенча трактатлар төзелүе, рисаләләр, хикәяләр һәм зур күләмле поэтик әсәрләр иҗат ителүе бер дә гаҗәп түгел. Моны Болгар дәүләте ирешкән иҗтимагый хезмәт бүленеше, материаль тормышны җитештерүнең югары ысулы тудырган. Чөнки: «Материаль тормышны җитештерү ысулы гомумән, тормышның социаль, сәяси һәм рухи процессларын билгели» [Маркс, 1949, с. 352]. Югары шәһәр культурасына ирешкән Болгарда язма әдәбият та иртә барлыкка килгән. Болгар үзенең атаклы галимнәре белән таныш булган.

Болгар-татар тарихына багышланган китапларда күбрәк галим Ягкуб бине Ногман телгә алына. Ул Болгарда казый булып торган һәм «Болгар тарихы» дигән әсәр дә язган. Испан гарәбе сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнатый 1135–1136 елларда Болгарда торган вакытында Ягкуб бине Ногман белән күп очрашкан һәм аннан Болгар тарихына

караган мәгълүматлар да алган. Ш. Мәрҗани Ягкуб бине Ногманнан бер гасыр алдарак яшәгән Хуҗа Әхмәт Болгари, казый Әбел-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари кебек галимнәр турында да яза һәм Әхмәт Болгари Газнәвиләр династиясенең башы, солтан Мәхмүд бине Сүбүктәгинның остазы – укытучысы, шәехе – өйрәтүчесе булган, ди. Ул соңгысының, ягъни Хәмид Болгариның һиҗри VI гасыр чикләрендә, ягъни милади XII гасыр башларында исән булганлыгын хәбәр итә. Шушы болгар казые, галим Әбел-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари «Дастане Могҗизат» әсәрен язган Сөләйман Саксининың да остазы булган [Мәрҗани, б. 78–79].

## Сөләйман Саксини

Исемен Сөләйман дип куйган һәм Идел буе төрки-татарларда борынгы вакытлардан алып хәзерге көнгә кадәр укылып килгән «Дастане Могҗизат» әсәрен саксинлыларга мөрәҗәгать итеп язган шагыйрь кем, кайчан һәм кайда яшәгән?

Саксини һәм Сувари белән нисбәтле Сөләйман бине Дауд исемле шагыйрь Урта гасырлар болгар-татар әдәбиятыннан тыш башка төрки әдәбиятлар тарихында билгеле түгел.

Ш. Мәрҗани болгар галимнәре турында язганда, Сөләйман бине Дауд Саксинига тукталып, кайбер мәгълүматлар да бирә. Хаҗи Хәлфә исә үзенең энциклопедиясендә бу галим һәм язучыны Сөләйман бине Дауд Сувари дип күрсәтә [Хаҗи Хәлфә, б. 551].

Идел буе төрки, болгар-татар поэзиясе тарихында зур урын тоткан «Дастане Могҗизат» әсәренең авторы булган, үзен саксинлылар белән бәйләнешле хисаплаган шагыйрь Сөләйман Ш. Мәрҗанида «Сөләйман бине Дауд Саксини» дип, ә Хаҗи Хәлфәдә «Сөләйман бине Дауд Сувари» дип күрсәтелгән.

Сөләйман Саксини турында хәбәрләр бик аз. Шулай да, безгә мәгълүм булган чыганакларга һәм әсәрләренә таянып, Сөләйман бине Дауднын шәхесе һәм заманы турында гомуми картинаны күз алдына китерергә мөмкин.

Ш. Мәрҗани Сөләйман бине Дауд Саксининың «Зәһрәт әр-рийаз» («Бакча чәчәге») исемле әсәреннән өзекләр китерә. Сөләйман шул әсәрен соңыннан 67 бабка – мәҗлескә бүлеп, аны «Зәһрәт әр-рийаз вә нөзһәтел-колубел-мираз» («Авыру күңелләрне сөендерүче бакча чәчәге») дип исемләп, һәр бүлек башында Хәмид Болгари аша хәдис риваятьләре белән, үгет-нәсыйхәт мәсьәләләре хакында фикер йөртә һәм шунда Хәмид Болгарины Шәйхел-имам (имамнар башлыгы), казый дип атап, үзенең остазы икәнлеген әйтә. Хәмид Болгари, мөселман хокуклары буенча дәрес биргәндә, үзе таянып сөйләгән әсәрләрнең авторларын да шәкертләренә җиткерә торган булган. Сөләйман бине Дауд, Болгардагы мәдрәсәләрнең берсендә дәрес алган вакыты 1120–1130 елларга туры килеп, XII йөзнең беренче яртысында иҗат иткән дип чамаларга мөмкин.

Сөләйман Саксини шул заманның таләпләренчә, ислам фикъһе-юриспруденция, Коръән тәфсире, хәдис гыйлеме, гарәп-фарсы, төрки

телләре һәм әдәбиятлары, шигырь-гаруз һәм әхлак-әдәп гыйлемнәре өйрәнеп, шул әхлак фәненең шәехе – остазы булып әверелгән. Ул Болгар, Сувар, Саксин шәһәрләрендә вагыйз-әхлак, әдәп, хокук гыйлемнәренең остазы булып хезмәт иткән һәм күп әсәрләр дә язган. Шулай итеп, без XII йөзнең урталарында, моннан 800 еллар элек яшәп иҗат иткән борынгы Идел буе төрки поэзиясе вәкиле Сөләйман Саксини белән танышабыз.

Сөләйман бине Дауднның әсәрләре таралган һәм күпләргә таныш булган. XV йөздә Хөсәен Байкара заманында Һиратта яшәгән галим һәм язучы үзенең «Төхфәтел-Мөлек» («Патшалар бүләге») исемле фикъһе-хокук китабында Сөләйман бине Дауднның «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән өзек китергән. XVI йөз татар язучысы Нух 1592 елда язган «Бостан әл-Коддес вә Гөлстан әл-әнес» китабында «Зөһрәт әр-рийаз»дан бер хикәяне тулысынча биргән. Шәех, таҗел-имам Сөләйман бине Дауд исеме XVI–XVII йөз госманлы галиме Мөхәммәд Чукраклы-Задәнең «Алты бармак (яисә «Дәлаилен-нәбүүәт Мөхәммәди») китабында еш очрый. Автор анда Сөләйманның «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән ун урында төрле күләмдә өзекләр алган.

Бөтен дөньяга билгеле булган, югарыда телгә алынган Хаҗи Хәлфә: Сөләйман бине Сувари фарсы телендә «Бәһҗәт әл-әнвар» («Чәчәкләр шатлыгы»), гарәп телендә «Зөһрәт әр-рийаз» дигән әсәрләр язган һәм аның вәгазь, әхлак, әдәп кануннарын өйрәткән бу китапларының бик мәшһүр булганлыкларын сөйли.

1813 елда Татарстанның Кавал авылында Бикмөхәммәт Бикбау углы тарафыннан язылган кульязма җыентыкта «Зөһрәт әр-рийаз»дан «Мигъраҗ» хикәясе гарәп телендә тулысынча күчерелгән. XVIII–XIX йөз галиме Мөхәммәд-Әмин Сабави 1786 елда күчереп язган «Гакыйдатес-Сөнусия» мәҗмугасында «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән бер хикәяне тулысынча теркәгән.

Болардан тыш, Сөләйман Саксинининың «Зөһрәт әр-рийаз» әсәре Ш. Мәрҗани кулында да булган, ул аның аерым өзекләре белән укучыларны да таныштырган. Казан галиме, тарихчы Хөсәен Әмирхан углы үзенең «Нәҗмет-тәварих» («Тарихлар йолдызы») исемле әсәрендә «Зөһрәт әр-рийаз»дан бер өзек китергән.

Китерелгән бу мисаллардан күренә ки, болгар туфрагында яшәгән Сөләйман бине Дауд Саксини Суваринының гарәп һәм фарсы телләрендә язылган әсәрләреннән «Зөһрәт әр-рийаз» һәм «Бәһҗәтел-әнвар» кебекләре Урта һәм Кече Азиядә, Идел буенда күп кешеләр тарафыннан укылган; күп галимнәр аның китапларыннан файдаланган. Сөләйманның төрки телдә язылган «Дастане Могҗизат» әсәре Идел буенда язма һәм басма килеш күп таралган булса да, татар әдәбияты белемендә, нишләптер, игътибарсыз кала килгән. Авторлардан З. Максудова тарафыннан «Дастане Могҗизат»ның борынгы кульязмасы табылуы бу әсәрне һәм аның авторы шагыйрь Сөләйманны башлап өйрәнергә этәргеч булды.

## Сөләйманның «Саксини», «Сувари» кушаматлары һәм заманы турында

Урта гасыр авторлары исемнәрен һәм иҗат иткән вакытын әсәрләренең башында яисә ахырында күрсәтә торган булганнар, кайберләре урта бер урында да, җае туры килгәндә, үзләре турында мәгълүматны кыстырганнар. «Дастане Могҗизат»та да шулай. Дастандагы 11 нче хикәяттән бер өзек алыйк. Анда шагыйрь сүзнең шигъри көче хакында сөйли. Шигъри сүзне тыңлап ләззәтләнгәндә, тутый кош үзенең яратып ашый торган шикәрен дә онытачак ди ул[1].

Тутыййә шәкәр йимәк үгрәдәйем,[2]
Былбылә бу сүзи тәгълим идәйем[3].
Ул нотсун шәкәрен бу сүзин,[4]
Икесе дәхи бу сүзи кылсын гезин.[5]
Мостафануң мәүлүдене уксун[6],
Шәүкыйлә сәр-мәст улубән Саксун...[7]
Бу Сөләйман нәчә мәдх[8] итсүн ани,
Белең, мәддахедүр анның ул гани[9].
(II)[10]

Бу өзектә шагыйрь җылы хисләр белән тулган поэтик сүзнең көче хакында тирән дулкынланып сөйли. Шигъри әсәр бирә торган ләззәтләнү алдында татлы шикәр бер хәҗәр – таш кына. Ләкин бу өзекнең әһәмияте шунда ки, шагыйрь анда үзенең исеме – Сөләйман, халкының исеме саксинлылар булуын аңлата. Ул саксинлыларга: бу шигырьләрне укып, тәэсирләнеп, һуштан язгыз, ди. «Дастане Могҗизат»ның авторы Сөләйман булып, Саксин шәһәре һәм халкы белән бәйләнгән кеше булып чыга. Без өстә шушы бер ук кеше Ш. Мәрҗанидә «Саксини», Хаҗи Хәлфәдә исә «Сувари» (Suwari) дип язылган, дидек. Хаҗи Хәлфә кулында Сөләйманның әсәрләреннән берәрсендә анның Сувар шәһәре яисә халкы белән бәйләнгәнлеген сөйләгән, шуны күрсәткән фактлар булган дип уйларга кирәк. Шулай итеп, шагыйрь Сөләйман бине Дауд Саксини – Сувари дип аталган була.

Югарыда Сөләйман бине Дауднның Болгар казыйсы, галим Хәмид бине Идрис әл-Болгаридан дәрес алганлыгы әйтелде. Димәк, Сөләйман Болгарда укып белем алган, шулай ук әсәреннән һәм

[1] «Я»ның сүздә «йа»мы, «йә»ме икәнлеген күрсәтү өчен, урыны белән «йа» һәм «йә» язылды. Кыска «уау» «у-ү» хәрефләре аша бирелде. Дастандагы сүзләрнең язылу формаларын сакларга тырышылды.

[2] Юлның мәгънәсе: Тутыйга шикәр ашауны өйрәтим.

[3] Тәгълим идәем – белем бирим.

[4] Юлның мәгънәсе: бу сүз белән ул шикәрен онытсын.

[5] Кылсын гезин – сайлап алсын.

[6] Уксун – белсен, укысын, аңласын.

[7] Юлның мәгънәсе: көчле тәэсир алып Саксун (Саксин) халкы һуштан язсын.

[8] Мәдх – мактау, олылау.

[9] Гани – бай, дәүләтле. Биредә: Аллаһ.

[10] «Дастане Могҗизат»тан китерелгән юллар астында җәяләр эченә алынган саннар ничәнче «хикаять» икәнлекне күрсәтә.

китерелгән чыганаклардан күренгәнчә, Саксин – Сувар халкы арасында да яшәгән.

Шагыйрьнең «Саксини» нисбәтенә килгәндә дә, эш шулай. Саксин (Сахсин) турында күп язылган, ләкин каршылыклы фикерләр әле дә яши. Д.А. Хвольсон Ибне Рустә әсәрләрен бастырып чыгару уңае белән булган хезмәтләрендә Саксин Җаек (Урал) елгасында гына булырга тиеш дип язды [Хвольсон, с. 45, 64–65, 66 (ком., прим. 1, 8)]. Бу фикерен ныгыту өчен, ул рус елъязмасында сөйләнгәннең эчтәлеген биргән Карамзин сүзләренә таянды. Елъязмада: монгол-татарлар алдыннан саксинлыларның һәм кыпчак (половец)ларның түбәннән ашыгычлык белән югарыга күтәрелүләре (възбегоша) болгар чик сакчыларының Җаек елгасы янында монголлар белән сугышканның соңында, калганнарының Болгарга качып килүләре (прибегоша) хакында сөйләнә [ПСРЛ, с. 453]. Карамзин елъязмасында бу өзекне китергәндә: саксинлыларны, кыпчакларны һәм болгар чик сакчыларын «прибежали» (качып килделәр) дигән бер фигыль белән бирә һәм тегеләрнең барысы да бергә, бер урыннан – Җаектан качып килгәннәр булып чыга [Карамзин, с. 236]. Бартольд, Вествергның Саксин шул ук Ител шәһәре, дигән фикерен яклап, аның Идел тамагында булганлыгы мөмкинлеген әйтсә дә, бәхәсле санады [Бартольд, с. 794, 690, 588]. Заходер, Гарнатый сүзләренә таянып, Ител шәһәре егылганнан соң, Саксинны Түбән Идел башкаласы итеп таный [Заходер, с. 144].

Гарнатый сүзләренә караганда, XII гасырның урталарында, нәкъ шагыйрь Сөйләман иҗат иткән дәвердә, Иделнең түбән агымындагы Саксин күп санлы мөселман халыклы шәһәр саналып, мәчетләре дә булган [Хвольсон, с. 13–14].

Ул югары культуралы, зур сәүдә шәһәрләреннән берсе булып, читләргә көмеш, гәрәбә кебек кыйммәтле әйберләр дә чыгарган. 922 елда ук Болгар дәүләте мөстәкыйль булып, Болгар Хәзәргә бәйле булудан котылгач, Иделнең түбән агымы Болгар тәэсиренә күчә, элек хәзәр дәүләте үтәгән рольне Болгар үзе үти башлый [Бартольд, с. 690]. М. Кашгари да: «Әтел (Идел) – кыпчак илләрендәге бер елганың исеме. Ул Болгар диңгезенә коя», – дип яза [Кашгари, 1915, II, б. 70]. Бу – Болгар дәүләте көньяк чикләренең Хәзәр (Каспий) диңгезенә кадәр барып җиткәнлеген ачык сөйләүче фактлардан. Димәк, ул вакытта Саксин Болгар дәүләте тәэсирендәге шәһәр булган. М. Кашгариның: «Саксин – болгарлар янындагы бер шәһәр. Ул – шул ук Сувар», – дип язуы нигезсез түгелдер [Кашгари, 1915, I, б. 365].

Безнең уебызча, монда Саксинны шул ук Сувар итеп караганда – бу ике шәһәрдә (яисә өлкәдә) яшәгән халыкның бер ук шивәдә сөйләүче – суварлар булуы хакында сүз бара. Х йөз тарихчысы әл-Мокаддисинең Болгар һәм Сувар шәһәрләре турында язганда: суварлыларның кайчандыр диңгез буена күчеп китүләре, ә соңыннан кире кайтып мөселман булганлыклары [Хвольсон, с. 84–85 (комментарий)] турында сөйләгәннәре дә Болгар суварларына карый. Саксин (Сахсин) шәһәр исеме булу белән бергә, өлкәне һәм шунда яшәгән

халыкны – кабиләне дә аңлаткан. Плано Карпини саксыларның[1] (саксинлыларның) монголларга кискен каршы торганлыклары турында яза [Плано Карпини, с. 57].

Шулай итеп, кайсы гына яктан килсәң дә, Сөләйман бине Даудның «Саксини» һәм «Сувари» дип аталуы аның болгар кешесе, Болгар дәүләтендәге галим икәнлеген күрсәтә һәм аның «Дастане Могҗизат» әсәренең теле Болгар илендәге төрки халыкларның XII йөз урталарындагы язма әдәби теле булып тора.

**Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат»ы.**
**Әсәрнең тасвирламасы**

Бу әсәр кулъязма җыентыкта, анда барысы 45 кәгазь, 90 бит. 20 б кәгазьдән «Дастане Могҗизат» башлана. Ул 25 кәгазь – 50 биттән гыйбарәт. Һәр битендә 17 бәет – 34 юл, барысы 854 бәет – 1708 шигъри юл. Башында әсәрнең исеме әйтелмәгән.

Соңгы бите төшкәнлектән, әсәрнең кайда, кайчан язылуы яисә кем тарафыннан күчерелүе анык билгеле түгел. Кәгазьнең искелегенә карап, XVI йөзнең ахырларында күчерелгән дип исәпләргә мөмкин. Рәсме хатты – нәстәгълик, иске Идел буе язуы: тел үзенчәлекләре, сүзләрнең язылышы бик борынгы. Әсәр «хикайәт» дип аталган шигъри бүлекләрдән тора, барысы 25 хикәят.

20 нче хикәяттә шагыйрь баштарак:

Бер гаҗәиб дастан дорур бу гайәт
Мостафадин белүң моны могҗизат, –

дисә, ахырдарак:

Дастане Могҗизат [бәс] улды тәмам,
Сөйләр мигъраҗендән[2] [бер] пәйам[3], –

дигән бу юллардагы «Дастане Могҗизат» сүзләре әсәрнең исеме булып чыга.

«Дастане Могҗизат» кергән кулъязма җыентык элекке Сарапул өязе Нарат авылы имамы, 1870 елларда үлгән Габдессаттар Сөендек углыннан калган әсәрләр арасыннан табыла. Бу – Сөләйман бине Дауд дастанының бердәнбер генә нөсхәсе түгел.

Дастанның төрле вакытларда күчерелгән кулъязмалары Казан, Мәскәү, Ленинград китапханәләрендә дә сакланалар. Ләкин З. Максудова кулъязмасы борынгы булуы белән кыйммәтле. «Дастане Могҗизат» тулы килеш тә, аның кисәкләре дә элек төрле елларда берничә тапкыр басылган да була. Мәсәлән, бу әсәр үткән йөзнең зур мөстәшрикъләреннән (көнчыгышны өйрәнүчеләрдән) М.А. Казем-бек һәм И.Н. Березинның рөхсәте белән 1849 һәм 1855 һәм аннан соңгы елларда да басылган. Элекке дәреслекләрдә, үгет-нәсыйхәт

[1] Көнбатыш тарихчыларының Иделдәге Саксин, Саксун, Сахсинны герман кабиләләре исеме сакс, саксы, саксоны белән бутап язуларын Хвольсон төзәтеп укырга тәкъдим иткән [Хвольсон, 65, комм. 3].

[2] Мигъраҗ – югарыга күтәрелү, күккә ашу. Мөхәммәднең күккә фантастик сәяхәте.

[3] Пәйам – хәбәр.

китапларында аннан төрле хикәятләр алынган, татар әдәбияты тарихында аңа ияреп әсәрләр иҗат ителгән. Шулай итеп, Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат»ы татар укучыларына якыннан таныш булып, киң таралган әсәрләрдән булган.

Басмасы белән чагыштырганда, дастанның сүз барган кульязмасы 66 бәеткә (132 шигъри юлга) ким, әсәрнең ахырында шагыйрьнең үз хәлләре турында сөйләгән бүлекчә юк. Шунда шагыйрь үз гөнаһларын Алладан кичерүне үтенеп язганда:

Һәм бу Сөләйман фәкыйрә рәхмәт ит,
Юлдашын иман йирени җәннәт ит, –
(«Могҗизат», б. 44)[1]

дип, шагыйрь исемен тагын искә ала.

## «Дастане Могҗизат»ның эчтәлеге

Әсәр кереш өлеш белән башлана. Борынгы көнчыгыш һәм төрки әдәбиятларда урнашкан гадәт буенча, шагыйрь анда Алланы мактый. Дастанның төп өлешен башлап җибәргән беренче хикәяттә дә эле сүз шул турыда бара, Алла барлык нәрсәләрне яратучы итеп күрсәтелә. Аннан соң килгән хикәятләрнең барысы да Мөхәммәдкә: ата-анасына, Мөхәммәднең тууына, дөньяви тереклек итүенә, семья хәлләренә багышлап язылган. Соңгы хикәят аны күмәргә дип кабер янына китерү белән өзелә.

XII гасыр шагыйреннән җәмгыятьтәге социаль тормыш күренешләрен турыдан-туры сүрәтләүне көтү бик сәер булыр иде. Урта гасыр әдәбиятының үзенә генә хас яклары, үзенчәлекләре бар. Ул үзенчәлекләрнең берсе – борынгы әдәбиятларның барысында да дөньякүләм дини-мифологик сюжетларга мөрәҗәгать итү. Сөләйман Саксини да шулай итә. Ислам дөньясында Алланың илчесе, пәйгамбәре итеп күтәрелгән Мөхәммәдне башта шул яктан сурәтләсә дә, аны җир кешесе итеп карый һәм җәмгыятьтә кешеләр арасында булырга тиешле игелек, ярдәмчеллек, рәхим-шәфкатьлекне, үзенең шул турыдагы үгет-нәсыйхәтләрен, әхлак-мораль нигезләрен, гуманистик теләкләрен Мөхәммәд образы аша һәм дастанда киң урын алган лирик герой кичерешләрен чагылдырган юллар аркылы бирергә тырыша. Әсәрдә дөньяви идеяләр дини мотивлар белән бәйләнеп бара. Бу – башка әдәбиятларда да шулай. Мәсәлән, изгеләрнең («житие»ләрнең) тормышын сүрәтләү борынгы рус нәфис әдәбиятында зур урын алган. Яисә Урта гасырлардагы русның сынлы сәнгатен алсак та, беренче караштa ул күбрәк дини-мифологик образларга, «изгеләргә»: Мәрьям ана белән Гайсәгә, фәрештәләргә, яки Гайсәнең шәкертләренә – апостолларга багышланган, хәтта тәре сурәтләү – икона сәнгате барлыкка килү дә шуны раслый.

Кешенең хыял көче белән тудырылган, үзе өчен үрнәк булып саналган ул образлар аша язучы, рәссам дөньяга карашын үткәргән, чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдергән һәм җәмгыятьнең башка член-

[1] Кульязмада булмаган соңгы бүлектәге мисалларны без «Дастане Могҗизат»ның 1855 елгы Казан басмасы буенча алабыз һәм «Могҗизат» дип битләрен күрсәтәбез.

нарына яхшылык турындагы мораль кагыйдәләрен бирергә тырышкан. Бу язучы дини-мифологик образлар аша үз заманы кешеләрендә булырга тиешле, үзе күрергә теләгән сыйфатларны чагылдырырга омтылган. Ул образлар яхшылыкның идеалы саналган һәм укучы аларны шулай кабул иткән дә. Башкача булганда, борынгы грек, Урта гасырлар рим сәнгатьләренең һәм әдәбиятларының әһәмияте булмас та иде, ә алар әле дә безне рухландырып, таңга калдыралар. Гомерның, Рафаэльның, Урта гасыр рус рәссамы Рублевның даһилыклары да шунда ки, алар идеаль булып саналган дини, мифологик сюжетлар аркылы кешелек сыйфатларын, яхшылык морале принципларын үткәргәннәр. «Әдәби портретта чагылган бу яхшылык идеалы аерым шәхес зәвыклары белән түгел, социаль строй тарафыннан тудырыла» һәм «үзеңне яхшы тоту идеаллары әдәбиятка тормыштан килә» [Лихачев, с. 58, 60], – ди Лихачев.

Бер яктан, дини-мифологик сюжет яисә образ; икенче яктан, зур художество көченә ия булган әдәбият, сәнгать әсәре. Бу катлаулылыкны аңларга безгә марксизм-ленинизм өйрәтүләре ярдәм итә. К. Маркс борынгы мифологик сюжеттагы сәнгать һәм әдәбият әсәрләре хакында болай ди: «Моны аңлаудагы кыенлык шуннан гыйбарәт ки, алар һаман әле безгә әдәби зәвык бирүдә дәвам итәләр һәм билгеле мәгънәдә норма һәм иң югары үрнәк булу әһәмиятен саклыйлар» [Маркс, 1951, с. 205]. Сөләйман Саксини әсәрләре, «Дастане Могҗизат»ка шул яктан килгәндә, без андагы идея-эчтәлекнең каршылыклы булуын да, художество югарылыгын да һәм шагыйрьнең эстетик, фәлсәфи карашларының дәрәҗәсен дә аңларбыз.

Шагыйрь – үз заманы вәкиле, тарихи шәхес. Аның омтылышларының киңлеге дә, чикләнгәнлеге дә шул чор җәмгыятенең тормышы белән бәйле. Тарихта бөтен Урта гасырлар буена Көнбатышта – христианлык, Көнчыгышта ислам дине феодаль дәүләтләрнең югары санкциясе булып тордылар, шунлыктан, кешеләрнең хисләре дини азык белән туенып тәрбияләнгән була [Энгельс, 1952, с. 49]. Шушы хакыйкатьтән чыгып килгәндә, ислам дөньясындагы Урта гасырлар шагыйренең иҗатын дөрес аңлап булыр.

Барлык диннәр кебек, ислам дине дә чынбарлыкны фани, бетә торган нәрсә дип өйрәткән бер вакытта, Сөләйман Саксини дөньяны матур бер күренеш, ә кешене шул дөньяны бизәүче итеп күрә:

Дотың имди җан колагың бу сүзә,
Та бәйан идәм бу сүзи хуш сезә:
Хак Тәгалә чөн йаратты адәми, –
Кыйлды адәмилә мөзәййән галәми,[1]
Адәме лотф әсси хак вирде вөҗүд,[2]
Бойурды, фәрештәләр кыйлды сөҗүд.[3]
(9)

[1] Кеше белән галәмне (дөньяны) бизәде.
[2] Шәфкатьлелек иясе – Алла кешегә тереклек бирде.
[3] Сөҗүд – сәҗдә.

Дөньяны матур күрсәтер өчен барлыкка китерелгән кешенең иң беренче сыйфаты – яхшы холкы аның үзен күркәм ясый.

Һәр нә дөрле кем сәгадәт вар дорур,
Йахшы хой, күркле гадәт вар дорур.
(7)

Юлның мәгънәсе: дөньяда нинди генә күп төрле бәхет булмасын, матур гадәте кешенең иң яхшы табигате – характеры (хой) санала. Яхшылык, игелек идеясен шагыйрь башка әсәрләрендә дә үткәрә. Сөләйман алда телгә алынган «Зөһрәт әр-рийаз»да, «Тәнбиһ» дигән әсәрдән файдаланганлыгын әйтеп, юмартлык һәм саранлык турында бер өзек китерә.[1]

Шагыйрь анда үгет-нәсыйхәт морале укып, җәмгыятьне савыктырырга тели. Эш юмартлыкны саранлыкка каршы куюда гына түгел. Кеше юмарт һәм игелекле икән, ислам динендә булмаса да, ул – оҗмахлы. Язучы, хәтта тәмуг белән куркытып булса да, милек ияләрен рәхимле-юмарт итәргә тырыша. Бу – бөтен Урта гасырлар буена дәвам итеп килгән һәм киң таралган, күп халыклар әдәбиятларына уртак булган философия. XII йөз Идел буе төрки, болгар әдәбияты да гомумкешелек культурасы сорауларыннан читтә тормаган. Аның алдынгы язучылары шул чор җәмгыятендәге прогрессив идеяләрне күтәреп, аларны сүз сәнгате, образлар аша укучыларга җиткерергә тырышканнар. Күренгәнчә, бу дөньяви идеяләр дини сурәтләр белән төсмерләнеп, бергә үрелеп бирелгәннәр. Сөләйман Саксини башкаларда булырга тиешле юмартлык, гаделлек, игелекне шул идеаль образ аша бирә.

Мөхәммәднең авырган вакытында кызы, оныклары белән сөйләшү моменты да гади, дөньяви итеп сурәтләнә:

Мостафа диде: дотуңлар, дорайым,
Ул йаранларым катына варайым.
Күрәйем бер дәхи ул йаранлари[2],
Йәнә бән күрмисәрем анлари.
Һәм дәхи анлар бәни күрмәисәр,
Сөхбәтүмә[3] дөньяда ирмәисәр.
Һәм үлем айрусәрдүр безләри,
Дөрр йәшилә[4] дәхи дулды күзләри.
(25)

Диниләр тарафыннан пәйгамбәрлек таҗы кидерелгән Мөхәммәд бу юлларда гади кеше сыйфатларына ия булган конкрет, җанлы образ булып сурәтләнә. Алай гына да түгел, ул балаларыннан, дөньядан үлем мәңгелеккә аерачагы турында хәсрәт белән янып сөйли, аны шушы фаҗига борчый. Бу – әсәрдәге көчле кичерешле урыннарның

[1] «Зөһрәт әр-рийаз»дан өзек алган «Кагыйдәтес-Сөнусия» әсәре З. Максудова китапханәсендә саклана.

[2] Йаранлари – якыннары.

[3] Сөхбәтемә ирмәисәр – киңәшемә, мәҗлесемәирешмәячәкләр.

[4] Дөрр йәшилә – энҗе яшьләре белән.

берсе. Мөхәммәдне дә, Гайсәне дә ул заман кешесе үзенә идеал итеп таныган һәм алардан үрнәк алырга тырышкан. Бу хакыйкать әсәрдә шулай сурәтләнгән дә.

Шагыйрь үзенең геройларын яратып, бирелеп сурәтли, әйтерсең, аның күңеле саф бер чишмә һәм аңардан өзлексез хисләр тасмасы сузыла. Шагыйрь яшәү яменә, җир тормышына гашыйк. Хәзерге төшенчә белән әйткәндә, шагыйрьнең дөньяга өмет белән карашы, чынбарлыкка мәхәббәте аның әсәренә баштан ахырына кадәр үзенә бер җылылык, күтәренке рух бирә. Күпчелек халыкка ягымлы карап, теләктәшлек күрсәтү, аларга ярдәм кулын сузып, игелекле, юмарт булырга өндәү – әсәрнең әһәмиятен тагын да күтәрә. Дини образлар аша эш итүгә карамастан, әсәрдә суфилык идеяләренең урын алмавы да игътибарга лаек.

Шик юк ки, Сөләйман Саксини – югары рухани катлаулар вәкиле: ул – феодаль дәүләтнең турыдан-туры яклаучысы булган ислам дине карашларын чагылдыручы, хакимлек итүче идеяләрне үткәрергә тырышучы. Ә «теләсә нинди вакытның хаким идеяләре һәрвакытта тик хакимлек итүче сыйныфның идеяләре булалар» [Маркс, Энгельс, 1952, с. 54].

Әмма Урта гасырларда яшәгән күп язучыларның дөньяга карашлары катлаулы һәм каршылыклы. Ул заман каләм остасын тик бер сыйныф вәкиле итеп, шул социаль катлауларның гына дөньяга карашын чагылдырган дип әйтеп булмаган кебек, әсәрнең идея-юнәлешен дә авторның тик шәхси карашларына гына кайтарып булмый. Чөнки, Маркс сүзләре белән әйткәндә, «кешенең асылы аерым индивидка гына караган (хас) нәрсә түгел. Үзенең чынлыгында ул (асыл) иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең җыентыгы» [Маркс, 1952, с. 55, приложение].

Теге яки бу язучының дөньяга карашының катлаулы булуының сәбәбе дә шунда. Ныклап өйрәнгәндә генә, шагыйрь Сөләйман Саксини иҗатында без теге яисә бу тенденцияләрнең ни дәрәҗәдә чагылышын күрә алырбыз.

Бер яктан, барлык нәрсәләргә кул селтәргә өндәп, теге дөнья өчен генә яшәргә чакырган ислам өйрәтүләре; икенче яктан, кешенең җирдә яшәве үзе бер гүзәллек булу. Менә шул җир тормышында шагыйрь Сөләйман ямь таба. Аныңча, кеше гомеренең чын мәгънәсе дә әнә шул чын тормышта яшәвендә һәм дөньяда игелекле, ярдәмчел булып, үзеңнән түбәннәр белән «ит-икмәк бүлешүдә».

Шагыйрь үзенең әнә шундый дөньяви теләкләр белән гомер кичергәнлеге турында сөйли.

«Дастане Могҗизат»ны язган вакытта, Сөләйман озын гомер юлы үткән, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, чәч-сакалы агарган, олы яшьтәге акыл иясе, карт бер хәким булгандыр дип уйларга туры килә.

Аһ ки бән нидәм, әмрени дотмадым,
Бер көн ул дидеки йула кәтмәдем.
Назәнин[1] гомри каму[2] вирдем йилә,

[1] Назәнин – матур, нәзәкатле.
[2] Каму – барысы.

Нәфсем арзуларына[1] йилә-йилә[2].
Гомремнең кадрен һәргиз[3] белмәдем,
Имди кем белдем, гомри булмадым.
Сач-сакал агарды, күңел кап-кара,
Кылмадым бер эш, ки карам агара.
(«Могҗизат», б. 43)

Күренә ки, шагыйрь дөньялыкта дин кушуы белән генә яшәмәгән: тормыш шартлары, әйләнә-тирә мохит аны үз эчендә мәшәкатьләнергә, үз юлыннан атларга мәҗбүр иткән.

Бер йарамаз фигълемез тәрк итмәдек[4],
Ахирәт бабында тәдбир итмәдек.[5]
Күңлемез милкен абад әйләмәдек.[6]
Үлүмемез чөн йараг әйләмәдек.
Хакка лайык һич йук әгъмалемез[7],
Белмәзез ки нулисәр әхуалемез.[8]
(«Могҗизат», б. 41)

Шулай итеп, үлгәч хәлебез ничек булыр икән дип, шагыйрь шикләнеп тә куя, чөнки ул теге дөнья өчен әзерләнеп яшәмәгән. Ә кеше гомере мәңгелек түгел, соңгы чиктә ул үлем белән киселә. Аныңча, фаҗига әҗәлдән котыла алмауда гына түгел, үлгәч, туфракка әверелеп юкка чыгуда.

Һәр нә дәклү чук йәшәрсә бер кеши,
Гакыйбәт үлмәк дорыр аның эши.
Һәр кем ула гакыйль, дәүләтлү әр[9],
Вагыйз, насих[10] аңа үлүм йитәр.
Белүрез чөнкем үлүрез гакыйбәт,
Черүбән туфрак улурыз гакыйбәт,
(«Могҗизат», б. 41)

дип, шагыйрь борчыла, уйлана, үткәннәрен башыннан кичерә.

Тормышта ул, үзе теләп-теләмәвенә карамастан, дөньяви уйлар белән яшәргә мәҗбүр булган. Сөләйманның тирән кичерешләр белән тулган юлларын дулкынланмыйча укып китү мөмкин түгел. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Сөләйман Саксини вагыйз – дини вәгазьче, нәсыйхәтче – насих кына түгел, киресенчә, ул дин таләпләрен үтәмичә, үзен уратып алган тормыш мәшәкатьләре белән мавыгып, дөньяви теләкләр белән гомерен үткәргәнлеге турында сөйли. Моны

[1] Арзу – теләк.
[2] Йилә-йилә –ашыгып, йөгереп.
[3] Һәргиз – бер дә, һичкайчан.
[4] Тәрк итмәдек – читкә какмадык.
[5] Тәдбир итмәдек – уйламадык, хәзерлек күрмәдек.
[6] Абад әйләмәдек – төзекләндермәдек.
[7] Әгъмаль – эшләр.
[8] Нулисәр әхуалемез – хәлебез ничек булыр.
[9] Әр – ир.
[10] Вагыйз, насих – вәгазьче, нәсыйхәтче.

ачыграк күреп, яхшырак төшенер өчен, дастанның ахырында шагыйрь үз хәле хакында сөйләгән бүлектән тагын бер өзек алыйк:

Бәндәм ул йөзе кара гасый[1] кол,
Бунчалайын[2] гасый кол кәлмеш дәгел.
Бер нәфәс[3] йукдыр ки гыйсйан[4] итмәдем,
Һәм дәхи бер дугры йула кәтмәдем.
Һәр нәфәсдә эшләдем бән чук гөнаһ,
Белең, гөнаһчен кыйлдым бән бер көн аһ...
Хакка лайык эшләмәдем бер гамәл[5],
Эшләрем җөмлә зәгалилә зәгаль[6].
Ахирәт әхаалени зикер итмәдем,
Нулисәр[7] хәлем дәйү фикер итмәдем.
Хәлемең, хуш, бәгъзесен кыйлдым бәйан[8],
Бундан артук йавыз эшем чук ниһан[9].
Кемсә белмәз, ничә хәлем вар дорыр,
Ул белүр, кем галимел-әсрар[10] дорыр.
Гизлү хәлем бер булисә әшкяр,
Дашлар илә әйләйәләр сәнгсар.[11]
(«Могҗизат», б. 43)

Шулай итеп, шагыйрь үзенең үткән гомер юлын ачып бирә. Аның дөньялыкта кылган гамәлләре ислам таләпләренә каршы булган һәм шул «[Аллага каршы] явыз эшләренең күбесе яшерен» булып кала. Ул тормышны зәвык белән үткәргән, теге дөнья өчен дә үзен әзерләмәгән, чәч-сакалы агаргач кына, дин кушканнарны үтәми яшәгәнлеге аның исенә төшә.

Димәк, эш әсәрдәге геройның ярым дини, яисә фантастик-мифологик сюжет белән бәйләнгән булуына түгел, бәлки аңа салынган һәм шуның аша үткәрелгән идея юнәлешендә. Сөләйман Саксини «Дастане Могҗизат» әсәрендә чынбарлыкны җәмгыять ирешкән сәнгатьчә фикерләү дәрәҗәсендә чагылдырган, үз чоры әдәбиятының алымнары һәм таләпләре нигезендә иҗат иткән.

## «Дастане Могҗизат»тагы сурәтләү чаралары

Шагыйрь чынбарлыкны гәүдәләндерүгә үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып килә һәм аның иҗат лабораториясендә туган шигъри юлларында үзенчәлекле рәвештә үз заманы рухы чагыла.

[1] Гасый – гөнаһлы.
[2] Бунчалайын – мондый, бу кадәр.
[3] Нәфәс – сулыш алу кадәр кыска мизгел, вакыт.
[4] Гыйсйан – фетнә, гөнаһка бату, боерыкны тотмау.
[5] Гамәл – эш.
[6] Юлның мәгънәсе: эшләрем барысы да ялган, алдашулар белән тулы.
[7] Нулисәр – ничек булыр.
[8] Кыйлдым бәян – аңлаттым.
[9] Юлның мәгънәсе: моннан башка явыз эшләрем күбесе яшерен.
[10] Галимел-әсрар – серләрне белүче (Алла).
[11] Бәетнең мәгънәсе: Әгәр яшерен эшләрем билгеле була калса, мине ташлар белән кыйнаячаклар.

Моның укучыга ничек барып җитүе һәм тәэсир итүе авторның сүз белән оста эшли белүенә бәйләнгән.

Сөләйманның шагыйрьлек көче, иң беренче чиратта, аның сүзгә мөнәсәбәтендә сизелеп тора. Шигърият сүзенә ул менә ничек карый:

Бу күңлүм Мисрынә[1] кыйлдым сәфәр,
Багладым[2] анда нәчә тәклү шәкәр.
Ачалум ул шәкәрең тәңин уш,
Йимәдән[3] җануң сафалар булур хуш.
Илә ләззәтлү шәкәрдүр бу шәкәр:
Кем шәкәр бунуң катында бер хәҗәр[4].
Бу мәгани[5] шәкәрен гәр йиеп сән,
Дөнйада шәкәр бу имеш дийәсән.
(11)

Шагыйрь шигырьдәге сүзнең кеше күңеленә кереп, аның хисләрен уятып дулкынландырган, фикерләренә канат биреп уйланырга мәҗбүр иткән, аны сөендерә торган көче хакында сөйли. Шикәр татлы, шикәрдән дә татлырак нәрсәләр бар икән – ул поэзия; кешеләргә шигърият бирә торган рухи рәхәтлек, ләззәт янында гади шикәр хәтта бер таш кына ул, ди. Көчле чагыштыру бу.

Шикәр сүзе, поэтик образ буларак, бөтен Урта гасырлар болгар-татар әдәбияты аша үтеп, хәзер дә актив кулланылудан туктамый. Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»та бал-шикәр сүзен Йосыфның иреннәре белән чагыштыру өчен ала һәм:

Бал-шәкәрдән датлу(ы)рак дуадакларың,
Ике ләбең күңелеми үртәр имди, – ди.

Шикәр сүрәте М. Колый (Меллагол)да да нәкъ шушы мәгънәдә килә:

Кыз углан раушан ирер йакты көндин, –
Ата-анага ләззәтлектер шәкәр-балдин.

Ф. Бурнашта:

Телләрендә – бал-шикәрдән тәм генә...

Халык җырларында:

Шикәрләрдән тәмле, балдан татлы
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең.
(«Мәдинәкәй» җыры)

Бу китерелгән берничә мисалда шикәр сүзенең татар поэзиясендә, борынгы вакытлардан алып, традицион сурәт булып, һаман да яшәп килгәнлеге күренә; халык авыз иҗатында ул тагын да күбрәк таралган.

---

[1] Мисыр – ил исеме.
[2] Багладым – күңел юнәлдердем.
[3] Йимәк – ашау.
[4] Хәҗәр – таш.
[5] Мәгани – мәгънәләр, фикерләр. Шигъри: соклandыргыч.

Күгәрчен, былбыл, тавис, һома, сәмруг[1] кебек кош исемнәре Сөләйманда матур образлы сүзләр булып килгәннәр.

Дастанда, персонажның – Мөхәммәднең үлеп, арадан китүен шагыйрь һома кошы образы аша бирә.

Ул һома кош чеки пәруаз әйләди,
Җөмлә әсхаб фәрйад агаз әйләди.
(25)

*(Ул һома кош очып киткән чагында,*
*Җылый башлады бар дуслар тагын да.)*

Фантастик һома – бәхет кошы, тирән образлы сүз буларак, татар поэзиясендә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә әле дә яши. Менә бер-ике мисал.

Г. Тукайның халык җырларында:

Очырдым һомай, ай, кошларын,
Табалмадым кунган төшләрен.
(II, б. 322)

Ә. Фәйзидә:

Күктә очкан кошның исеме –
Һомаюнмы, Сәмрәү кошымы?

Әлбәттә, кайбер поэтик фигуралар артык актив кулланылмаска да мөмкин. Һомай моңа мисал була ала. Ләкин гасырлардан гасырларга күчә килә, алар барыбер традицион образларга әвереләләр. Болгар-татар әдәбиятында тавис та нәкъ шундый традицион сурәтләрдән санала. Менә дастандагы 21нче хикәяттән бер мисал:

Гаклу тауис ачды кирү пәру-бал,
Таки җәүланилә күстәрә җәмал.
(21)

*(Акыл тависы җәеп каурый-канатын,*
*Боргаланып күрсәтә гүзәл затын.)*

Табигатьнең үз законнары гына тудыра алган тавис каурыйканатларына күз явын ала торган гүзәллегенә карап, кемнәр генә сокланмый икән! Акылларны таң калдырган менә шул тавис Сөләйман Саксинида бөтен матурлыгы белән гаҗәп күркәм образ булып алга баса. Әлбәттә, моннан сигез йөз еллар элек иҗат ителгән шигъри юллардагы сүзләрнең мәгънә, тойгы, хис, омтылыш төсмерләрен аңлау һәм ул сүз энҗеләренең серләрен ачып бирү җиңел түгел. Сөләйман сүзне оста куллана белә – нәкъ шунда аның зур шагыйрь икәнлеге күренә дә. Тавис канатларын җәеп горур әйләнгәндә үзенең матурлыгын бөтен тулысы белән күрсәткән кебек, кешенең акыл көче дә илһамланып иҗат эшендә кайнаганда искиткеч көчкә ия булган тыл-

[1] Һома, һомай – кешеләргә бәхет китерә торган фантастик кош. Ышанулар буенча, һомайның күләгәсе төшкән кеше зур бәхеткә ия була, имеш.

Сәмруг – фантастик кош.

сымлы шигъри юллар тудыра ала. Шулай итеп, шагыйрь төрле сурәтләр, образлар аша тирән фикерләргә, эмоциональ хисләргә ирешә.

Г. Кандалыйда тавис, гандәлиб (сандугач), тутый кебек традицион поэтик чаралар хәтта бер строфада бер-бер артлы киләләр. Мәсәлән:

Йөзләре шәмс-камәрди[1]
Мисле тауис рәфтәси[2],
Авазы хуш гандәлибди[3]
Тутый кеби гөфтеси[4].
(«Шигырьләр», б. 155).

Үзенчәлекле тавис образын хәзерге татар шагыйрьләре иҗатында да очратып була. Мәсәлән, Шәйхи Маннур

Бибкәй матур үскән икән,
Үсеп буйга җиткән икән,
Күгәрчендәй көлгән икән,
Тавис коштай йөргән икән.
(Сайланма әсәрләр, 1951, б. 346).

дип, кызның нәзакәтен, күңелләрне дулкынландырган һәм әйләнәтирәгә ямь биреп торган сылулыгының камиллеген бик отышлы сайлаган «тавис коштай йөргән икән» сүзләре аша әйтеп биргән. Бер сүз кызның нәфислеген дә, купшылыгын да бирә алган. Димәк, традицион төс алган сурәтләр үлмиләр, һәр чорның язучысы аларны үз карашларыннан чыгып файдалана, аларга яңа мәгънәләр, төсмерләр өсти.

Югарыда «Дастане Могҗизат»тан тавис турындагы китерелгән бәеттән соңгы юлларында да чын шигърият аһәңе яңгырый. Шигырь болай дәвам итә:

Фикер сахрасы эченә керде хуш,
Мәгънә гөлзарында җәүлан орды жуш[5],
Уорды пәру-бален[6] бер-беренә:
Таки нәкыш, фәһм, фикрәт күренә.
Чумды дил бәхренә[7] һәм гаувасуар,[8]
Булды анда нәчә дөрре-шаһуар[9],
Алды, гыйшык базарына килде, аны,
Аңа гыйшык мөштәри кәлсүн кани?[10]

Шагыйрь сүзләрнең күбесен күчерелмә мәгънәдә куллана һәм шул нигездә тирән җанландыруларга ирешә: фикер сахрасы, мәгънә

[1] Шәмс-камәрди – кояш һәм ай кебек.
[2] Юлның мәгънәсе: йөреше тависныкы төсле.
[3] Гандәлибди – сандугачныкыдай.
[4] Гөфтеси – сүзләре, сөйләве.
[5] Юлның мәгънәсе: Мәгънә гөлбакчасында сәер итеп дулкынланды.
[6] Пәр вә бал – каурый-канат.
[7] Дил бәхре – күңел диңгезе.
[8] Гаувасуар – чумучы кебек.
[9] Шаһуар – иң кыйммәтле, ара бөртекле энҗе.
[10] Кани – кайда.

гөлзары (чәчәклеге); дил бәхре (күңел диңгезе), гыйшык базары һ. б. Гавасвар (чумучы – водолаз) диңгез төпләренә чумып, эре энҗе бөртекләрен зур тырышлык белән генә тапкан шикелле, шагыйрь дә тик күңел диңгезендә, фикер сахраларында, мәгънә гөлбакчаларында иҗат дулкыннарын кичкәндә генә сүз энҗеләреннән шигъри тасмалар барлыкка китерә алырга мөмкин, ди. Сөләйманның поэтик иҗат эшенә карашы шушылай. «Дастане Могҗизат» – баштан ахырына кадәр шундый образлы сүзләр белән бизәлгән поэтик әсәр. Анда: ширин сүз, энҗе дешләр (тешләр), катыг сүз, сәгадәт (бәхет) таҗын ору (кию), үлем зәхмәте, гафләт уйкусы (гамьсезлек йокысы), бәхре гыйлем (белем диңгезе), гүзәл йөзле, һома кошы,васлат (кавышу) җилләре, җан колагы, җан һомасы, күңел дәрьясы, сәрүе буйлуг, дөньядин сәфәр әйләде, сабыр пәрдәсе, канлы яшь, рәхмәт йагмуры (яңгыры), күңел күзе, йалан айак, йөзе ак, йөз суы, көн йөзе, йөзе кара, башы ачык кебек күчерелмә мәгънәдә килгән поэтик чаралар – троплар еш очрый.

Сөләйман бине Дауд кулланган образлы сүзләр, сурәтләр арасында бик борынгы формалары, хәтта заманыбыз телендә онытыла башлаганнары да бар. Мөхәммәд авырып яткан вакытында оныкларын соңгы кабат күрергә теләп, аларны янына чакырта һәм үкенечле сүзләр сөйли.

Бөйлә диде, йәшилә дулды күзи,
Диде: каны шул ике көрпә[1] кузый?[2]
Керделәр иүәрү чен аглашдылар,
Бабасының буйнуна чырышдылар.
Диди: җаным кузыйлар, нитмәк кәрәк,
Дәдәңез дунбагъ[3] тәрк итсә кәрәк,
(25)

Биредә Мөхәммәд оныкларына көрпә[4] кузый, җаным кузыйлар, ягъни бөдрә бәрәннәрем, җаным бәрәннәрем дип эндәшә. Йомшак, мамык йонлы мәгънәсендәге керпә сүзеннән оста файдалануның үрнәге Дәрдемәндтә дә бар:

Мачы, мачы пәскәеп,
Көрпә мамык төскәме...

Яисә:

Күтәр чәчкәйләрең, күтәр кабагың,
Күренсен йөзләрең, көрпә яңагың.
(Шигырьләр, б. 85)

---

[1] Көрпә – йомшак, бөдрә, мамык йон. Мамык, йон белән сырылган түшәккә, җәймәгә, юрганга да керпә диләр.

[2] Кузый – бәрән; дөнья; төнбагы.

[3] Дунбагъ – урын, ястык. Юлның мәгънәсе: бабагыз урынын ташлап китә булса кирәк.

[4] Көрпә – борынгы төрки телдә мәче мәгънәсендә дә кулланылган.

Җанвар, җәнлек балалары яисә кошлар исеме белән сабыйларга эндәшү, иркәләп, сөеп әйтү, мөрәҗәгать итү күп халыкларда һәм болгар-төркиләрдә да киң таралган. Мәсәлән, тоткынлыкта яшәгән каһарман Муса Җәлил югалган ирекен очып киткән кош белән чагыштыра:

Алтын иркем, азат тормышым,
Кая очтың киек кош булып?
(«Ирек»)

ди шагыйрь.

Мондый мисалларны татар әдәбиятыннан, халык дастаннарыннан, эпослардан күп китерергә мөмкин. Мәсәлән, колын сүзен образ итеп куллануга бер-ике үрнәк алыйк.

Дәрдемәндтә:

Колынкаем,
Кил җанкаем,
Йоклаек икәү.
(«Бәллү»)

«Бүз егет» дастанында, улының (Бүз егетнең) үтерелгәнен белгәч, ана күз яшьләрен түгеп, хәсрәтләрен белдереп, болай ди:

Күз алдымда бар булсаң,
Күрмәс мидем, колыным[1];
Үлгән йирдә бар булсам,
Үлмәс мидем, колыным.
(«Бүз егет», 1916, 60)

Хайваннар исеме белән бу рәвешле балага эндәшүне «Алпамыш», «Манас», «Раушан» кебек дастаннарда, шулай ук «Кузы-Күрпеч»нең казакъ, башкорт һәм татар вариантларында да очратабыз. Язма әсәрләрдә сурәтләү чарасы буларак кузы (бәрән) беренче XI йөз ядкәре Йосыф хас-Хаҗибның «Кутадгу билиг»ендә күренә.

Никү тир[2], ишеткел утачы[3] сүзи, –
Монуң мәгънәси укъ[4] – терелгел, кузый.
[Валитова, с. 99].

Яисә:

Йатыг әрмәс әрсә бу дәүләт үзи,
Нә әдгүнәң әрди бу кот, әй кузый!
[Малов, с. 268]

*(Бу дөньяда, байлыклары асылда шул кадәр түбән-әшәке булмаса,*
*Бу бәхет дигәнең нинди булыр иде, и кузый!)*

---

[1] Колыным сүзе белән баланы иркәләү XVII йөз әдәбиятыннан «Әбү Шәхмә» хикәятендә дә кулланылган.

[2] Никү тир – изге кеше.

[3] Утачы – табиб.

[4] Укъ – аңла.

Монда «кузый» поэтик фигура булып килгән. Ләкин «Керпә кузый» формасын без алда Сөләйманнан китерелгән мисалда күрдек. Шушы образлы сүз соңыннан халык дастаннарында геройның исеменә әверелә – аның асылында шул ук сөеп әйтү һаман да саклана. Казакъта ул: Кузы-керпеш, башкортта Кузы-керпәс, татарда Кузы-керпәч. Әмма Сөләйманда әле «керпә кузый» иркәләп әйтүне генә аңлата.

А. Вәлитова: хайван балалары исеме белән эндәшү элек малчылык белән шөгыльләнгән халыклар фольклорына гадәти күренеш дип яза [Валитова, с. 100]. «Кузы-керпәч һәм Баян-Сылу» эпосының казакъларда, башкортларда, шулай ук Көнбатыш Себердә һәм Урал якларында башкортлар белән бәйләнештә яшәгән татарлар арасында таралган булуы да шуның белән аңлатылса кирәк. Димәк, эпос элекке күчмә яисә ярым күчмә халыкларның тормышына җайлаштырылган. Болгар-татарларның төп халкы яшәгән Идел буенда бу эпосның язмышы башкарак юнәлештә киткән. Болгарлар – бик борынгы вакытлардан бирле нигездә утраклык белән яшәгән халык. Элекке вакытлардан ук шәһәр тормышы белән бәйләнгән үзбәкләрдә, госманлы[1] һәм болгар-татарларда бу эпосның башлангыч легендасы нигезендә икенче игезәк төре барлыкка килгән булса кирәк. Бу – Таһир белән Зөһрә турындагы эпос яки дастан. Бу исә утраклыкта яшәгән һәм шәһәрләре булган халыкларның тормышы белән бәйләнгән. Безнеңчә, ике төр эпосның да генезисы бар. Ләкин аерым халыклар аны үзләренең тормыш барышына яраклаштырып эшкәрткәннәр, тарихи социаль яшәү шартларына җайлаштырганнар.

Биредә Сөләйман Саксинның «Дастане Могҗизат»ындагы сурәтләү чараларына карата кайбер мисаллар гына алынды. Ул образларның күбесе бүген дә әле татар поэзиясендә көчле яңгырыйлар, аларның эзләрен халык авыз иҗатында да күреп була.

Сөләйманда:

Гәр аңа күңел күзе илә бака сән,
Җан колагына бу дөрри дака сән.
(19)

*(Аңар күңел күзе салсаң –*
*Җан колагына бу энҗене тагарсың).*

Күңел күзе сурәте шулкадәр таралган ки, һәр болгар-татар шагыйренә таныш, хәтта ул: «күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – күрә алмас» дигән мәкальгә дә төп элемент булып кергән. Шагыйрьнең күләгә сүзен куллануы да үзенчәлекле.

Нур иде башдан айага гәүдәси,
Бу гайандыр[2], нурың улмаз күл(ә)гәси;
Күләгә золматдан төшә һәр йирә,
Күләгәне нурдин бу күз канда күрә.
(19)

[1] Әхмәд Уразай «Таһир – Зөһрә»сен госманлылардан алам дигән.

[2] Гайандыр – ачык.

Сөләйманча, күләгә – караңгылык, золмәт, кайгы, наданлык билгесе. Татар поэзиясендә һәм әдәбиятында күләгә, образ буларак, күп очракта хәзер дә тискәре мәгънәдә кулланыла. Муса Җәлил «Моабит дәфтәре»ндә кайгыны «кара күләгә», үлем куркынычын «үлем күләгәсе» дип бирә.

Айлар буе минем бүлмәмдә,
Булып ямьсез кара күләгә,
Боектырып назлы күңелне,
Карауладың минем гомерне.
(«Шатлыкны каршылап»)

Яки:

Һәр тыкрыкта үлем күләгәсе,
Һәр ишектә коллык йозагы...
(«Серле йомгак»)

Халык әдәбиятында аерым сурәтләр, образлы сүзләр, шул чаклы нык, тотрыклы булып әвереләләр ки, гасырлар, хәтта меңъелга якын вакыт үтүгә дә карамастан, алар шул әдәбиятта әле дә солдат булып калалар. Димәк, аерым образларның озын гомерле булуы шул әдәбиятның үзенчәлеге, эчке үсү закончалыклары белән бәйле.

### «Дастане Могҗизат»ның теленә карата

Болгар заманындагы Идел буе төрки теле Галинең «Йосыф китабы» һәм каберташ язулары буенча гына билгеләнә килде. Ләкин шул өлкәдә язылганы анык билгеле булган әсәрләр әле юк иде. Ниһаять, «Кыйссаи Йосыф»ның әүвәлге хәбәрчесе булган Сөләйман Саксини әсәрләренең культурабыз тарихында яңадан тергезелүе шул чорлар әдәбияты һәм тел ядкярләрен янәшә куеп өйрәнү өчен киң юл ача.

«Дастане Могҗизат»ның теле – борынгы; Идел, Урал буе төркисе. Ул заман төрки телләрдәге уртаклык хәзергегә караганда да күбрәк булган. Шуның өчен дә Сөләйман Саксини дастаны теленең угыз, харәзм төркисенә якын булуы гаҗәп нәрсә түгел. Шундый уртаклык булуга карамастан, аның төп лексик составы Идел буе төркисен тәшкил итә, шуңа күрә ул хәзерге татар теле белән нык бәйләнгән. Кайбер сүзләрне алып карыйк.

**Исемнәр:** ат, ата, ана, атасы, айагына, агач, аккош, асман һәм күк, бодак, даш (таш), туфрак һәм тупрак, җәннәт һәм оҗмах, дәрт һәм дәрд, күз, киңәш, көн (кояш), кап (капчык дигәндәге), катына (янына), кот (бәхет), йөз, йолдыз һәм кәүкәб, йир йөзе, йапрак, йөз суы, өү, ү (мишәр сөйләшендәге «ү» кебек).

**Сыйфатлар:** айрук (аерым), ак (агыйде – ак иде), бойурмадуг эш (боермаган эш), каты һәм катыг, канку (кайсы), канкусы (кайсысы), ушбу, дөрлү (төрле), күрклү, чук сәлам, котлу (бәхетле), күзлү, сүзлү, гүзәл, олы (олы кол), йалан айак, айрулдуг сәгатдә, булдуг йул.

Дастанда **сан** исемнәреннән хәзерге вакытта кулланылганнарыннан барысы да бар, ләкин: беңъязыла һәм икенч, өченч формасы да очрый.

**Алмашлыклар:** бән, сән, ул һәм у; без, безләр, анлар һәм улар; бу, буны, булар, бунлар (бонлар) һәм моны, монының, монлар.

**Фигыльләр һәм хәл фигыль формалары:** алмак, элмәгә, белүлде (белдерде), булды һәм улды, йагар (кар йагар), кыйлур, котлады, дугды (туды), улмаз, күстәр, күргүзде, ачалум, сачалум, озар (озынаер), уарса, килсә, йагыйсәр (яуачак), дугыйсәр (туачак), илт, нәтде – нишләде, әйтде; аглайу (елап), йиңмәйүп (җиңмичә), тугдурмасачы, кыйлубән, кәлүбән, сөйләгел.

**Рәвешләр:** уйагыйкән, бончалайын, бераз, мончә, бөйлә-бүйлә, гомреңезчә, тулунчә, айрунчә, ирак (йырак), ари (ару, таза), кирү (кире кәлде), үтә бакды, каршу һ.б.

**Ярдәмлекләрдән:** бәлки, чөнкә-чөнки, һәм, дәхи, ирди, имди, иде һәм изе (Минзәлә ягы сөйләшендәге кыдыл бодай дигәндәге кебек); үзе, үзрә һәм өстенә, илә (күп очракта дастанда кушылып языла: аныңилә (аның белән), ичрә һәм ичендә, гәр, әгәр, гәрчә, йәнә, ки.

Бу китерелгән сүзләр белән беррәттән, «Дастане Могҗизат»та бик борынгы сүзләр һәм иске формалар бар. Монда аларның кайберләрен генә китерәбез. Мәсәлән, агаз – башлау; фәрйад агаз әйләде (җылый башлады).

Агды – күтәрелде: йәнә күккә агды (күтәрелде). «Йосыф китабы»нда (40): хәрир (ефәк) киде, орынды, тәхтә агды (тәхеткә күтәрелде).

Андук: әүвәл анук аны, кем әүвәлдүр ул.

Андук искә алды, «аң», «аңламак» сүзеннән: зиһенгә китерү, хәтерләү, искә алу, аңлау, белү мәгънәсендә. Мәсәлән, Ф. Әмирханда: Рәсемдәге матур күзләренең матур елмаешлары хөр вә ялгыз үскән тубылгы чыбыгын андыра... (т. 1, 484). Бу сүз «Кыйссаи Йосыф»та да шул мәгънәдә килә: Аны сезгә андырмага үгъдә кыйлдым (40).

Уграды – очрады:

Бу фирак уды кәмә кем уграды,
Уградугың йөрәкен дуграды.

Мәгънә:

*Бу аерылышу уты кемгә очрады,*
*Шул очраучының йөрәген трукլады.*

Уграды – очрады, угурмак, угратмак – туры килү, якынаю, очрашу. «Кыйссаи Йосыф»та да бу сүз нәкъ шул төшенчәдә алына.

Йосыфә бакмага уградылар, –
Кәнд әлләрен кәсүббән дуградылар.
(56)

Мәгънә:

*Күрергә дип Йосыф белән очраштылар,*
*Шулчак үз кулларын кисеп турадылар.*

Әбелмәних Каргалыйда: «Бер бәлайә униграмышым нагәһан», ягъни кинәт бер бәлага очрадым. Сөләйманда сил – сөрт сүзенең кулланылуы да тел факторы буларак кызык һәм әһәмиятле:

Бәс рәсүл кәм диде: йилең, и кызым,
Сил йәшеңи, аглама, тотгыл сүзем.
(25)

Икенче урында:

Рәсүл икенде намазын кыйлмышиде,
Дога кыйлып, әл йөзә силмешиде.
(20)

Җөмләләрдән күренгәнчә: сил йәшеңи – яшеңне сөрт, әл йөзә силмешиде – кулын йөзенә сөртте, сыйпады була. Шушы сил-сел яисә силмә, силмәк, селмәк тамырыннан ясалып, татар телендә хәзер дә иң актив булган «сөлге» сүзе яши.

Касыйм татарлары телендә «сөлге» сүзе башкачарак әйтелештә: «селе», «сәлә» (Диалекталь сүзлек, III, 137 б.) [Махмутова, 1955, с. 155], чөнки аларда «г, к» авазлары әйтелми: күлмәк урынына «үлмәә» диләр. Бу, ягъни «селе» – «сәлә», «сил» тамырыннан ясалып, хәзерге көнгә кадәр сакланган тагын бер күренеш.

«Дастане Могҗизат»та актив кулланышта булган – исар-исәр кушымчалары да борынгы үзенчәлекле фигыль формаларыннан. Безнеңчә, бу – барлык төрки телләргә дә хас күренеш түгел. Ә. Нәҗип Харәзминең «Мәхәббәт-намә»сендә очраган бу форманы чыгышы ягыннан угызныкы итеп карый һәм Урта Азия язма истәлекләрендә аның күренмәгәнлеген әйтә. Без аны Идел буе болгар-кыпчак (татар), Харәзем төрекләре, азәрбайҗан, госманлы Урта гасырлар язма ядкярләрендә очратабыз. Әмма Идел буе төрки (болгар-татар) әдәбиятында ул XX йөзнең башларына кадәр кулланууда була.

«Дастане Могҗизат» бу формада килгән фигыльләргә бик бай.

Кортарисәр (коткарыр), әйләисәр (шулай эшләр), улисарз (булырбыз), куйисәр (куячак), уирисәрем (бирермен), диисәр (дияр), айрусар (аерачак), күстәрисәр (күрсәтер), охшаисар (яратыр).

«Дастане Могҗизат»тагы сүзләрнең яисә фигыль формаларының кайсын гына алсак та, без аларның болгар-татар әдәбияты истәлекләре теле белән, хәтта халыкның хәзерге җанлы сөйләме белән органик бәйләнгәнлекләрен күрербез. Менә бер мисал:

Хури җинан[1] шад улдугый
Дугдугый ау кәлди йәнә.
(3)

Биредә «шад улдугый» һәм «дугдугый ай» – «шат булган», «туган ай» була, ягъни үткән заман сыйфат фигыле хикәя фигыльнең үткән заманына – кы-гы, ке-ге аффикслары кушылу белән ясалган. Бойурмадуг эш һич итмәде – боермаган эшне һич эшләмәде дигән сүз. Сөләйман бине Даудның дастаны бу форманы теркәгән бердәнбер әсәр түгел, соңгы вакытка кадәр татар язучыларының әсәрләрендә ул урын ала.

[1] Хури җинан – оҗмах хурлары (кызлары).

Әбелмәних Каргалыйда:

Туры кәлеп аңа йул кұстәрделәр,
Алдукый флюресен һәм вирделәр.
(«Тәрҗемәи..., 25)

Алдукый флюресен – алган акчасын.

Г. Ибраһимовта: «Зәки ачлык, бу кадәрле кыенлык күрдеги кеби, әүвәлге көндән үк... вәхшәтләрне күрә башлады. Зәкинең хәлфәсенең шәкертләре бик күп булдыгыннан, тиз дәрес алырга чират җитми иде («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»).

Татар әдәбияты классикларының әсәрләрендә һәм халыкның җанлы сөйләшендә әле дә кулланылган шушы булдык – булдыкы – булдыкыннан формасын Р. Шәмгунованың борынгы күренеш итеп каравына тел галиме Э.Р. Тенишев каршы чыгып, -дык, -дек (калдык – җыентык) формасы татар теленең үзенә хас түгел, ул форманың Г. Ибраһимов тарафыннан кулланылуы «тышкы күренеш ягы, төрекләргә охшарга тырышу модасына өстенлек бирү генә», – дип яза [Тенишев, 1966, с. 216–220].

Гаҗәп парадокс бу!

Э.Р. Тенишев фикеренчә, Г. Ибраһимовта мода артыннан куу булсын ди. Ә Г. Тукай публицистик мәкаләләрендә ул тышкы ясалмалыкны күз алдында тотмагандыр дип уйларга кирәк. Менә шул формага Тукайдан мисаллар: «шуның өчен аларга, һәр милләттә **булдыгы** кеби... җәмгыяте хәйрия ясау лөзүме (кирәклеге) күптән хас ителмәктә иде (т. III, 132 «Җәмгыяте хәйрия»). «Баз мәхфи улмая ки (аннары яшерен булмасын), без сезләрни Думага сайлап мәшәкатьләнеп әбәрдек хөкүмәт сайларга **кушканлыгы** өчен, юкса безгә кирәк нәрсә **булдыгыннан** түгел (т. III, 59. «Казаннан Думага телеграм»).

Мисаллар китерелгән чыганаклар икесе дә – Тукайның памфлет-сатирик мәкаләләре. Мода артыннан куу дигән нәрсә мөмкин түгел.

Татар теле диалектларындагы җанлы сөйләмдә: «бар булдыгы – шул инде», «баргым кели» [Махмутова, 162, с. 143] диюләр дә шул формага керә. Булдыг формасы борынгы уйгур, госманлы телләрендә һәм угыз теленең яргу диалектында да булган [Рясянен, 1955, с. 169–170].

Бардыг формасының «Дастане Могҗизат»ка, «Кыйссаи Йосыф»-ка, Гариб Болгариның «Былбыл вә Гөл»енә барып тоташуы һәм аннан соңгы әсәрләрдә, җанлы сөйләм телендә һаман да яшәп килүе шушы телнең үзенә хас булган үзенчәлек икәнлеген раслый.

«Дастане Могҗизат»та аерым сүзләрне, беренче карашта тиеш күренмәгән урында, әлиф аша язу очраклары бар. Мәсәлән, без күрергә күнеккән *тибрәнде* сүзе *тибрәндәи* формасында язылган:

Варды ул тагга, орды кадәм,
Таг тибрәнди кадәм ордуг дәм.
(19)

Мәгънә:

*Тауга барып ул аяк басты,*
*Аяк баскан чагында тау тибрәнде.*

Гарәп хәрефләре белән язылган тибрәндәи сүзен ачыграк аңларга тырышсак, тибрәндейе, ягъни тибрәнде-эйе дип бирергә мөмкин һәм моның шулай булырга тиешлеген шигырь юлындагы үлчәү дә тели. Әгәр без татарның урыннардагы җанлы тел фактларына күз салсак, моның шул телнең үзенчәлекле сөйләшен чагылдырган күренеш икәнлеген аңларбыз. Мәсәлән, диалектология материалларына караганда, Чистай яклары, Куйбышев өлкәсе татарларына бардымие (бардым-эйе), килдемие (килдем-эйе) дип сөйләү характерлы [Шамгунова, б. 166]. Авторларның күзәтүенчә, болай сөйләү Тархан, Буа, Апас, Тәтеш тирәләрендәге татарлар телендә дә бик актив. Борынгы әсәрләрдәге бардуи, кабер ташларындагы бултуи (булдыи), тындуи (тындыи) формасы үзенең язылышы белән диалектлардагы әнә шул бардыйе сөйләшенә бик якын. Бу күренеш – язуда болгар-татар сөйләшендәге үзенчәлекле әйтелешне чагылдырырга тырышу билгесе генәдер. Гариб Болгариның «Былбыл вә Гөл» әсәрендәге[1]:

Хали калдуи җаныдин бостан, баг...
Кәтдүкендин улдуи зар-зар, –

дигән юлларда калдуи – улдуи дип язылуның да сәбәбе шулдыр.

«Дастане Могҗизат»тагы шикелле «әлиф» белән язу үрнәкләре «Йосыф китабы», каберташ язуларында да бар.

Көн, җите сүзләренең кабер ташларында ку(а)н, җи(а)те рәвешендә әлиф белән язылуларын да шулай аңларга кирәк. Бу язылыштагы әлиф – «а» яисә «ә» авазын да тулы мәгънәдә аңлатмый. Бу күренешне шулай төшенергә безгә борынгы вакытларда «уау»дан соң «әлиф»нең график-язу билгесе булып йөргәнлеге дә ярдәм итә.

«Дастане Могҗизат»та характерлы мисал бар:

Аныңчен улды бу варлук камуа;
Ай, йулдуз, йир, күк, уҗмак, тамуа.
(6)

Биредә каму (барысы), таму (тәмуг) сүзләре ахырында язылган «әлиф»не тик график билге итеп карарга туры килә, чөнки аның бу урыннарда нинди дә булса аваз мәгънәсенә ия булмаганлыгы ачык. Аерым сүзләрне «әлиф» белән язу Болгарга килгән гарәп сәйяхларыннан Ибне Фадлан көндәлекләрендә дә урын ала. Мәсәлән, Башту(а), Вису(а), Йабгу(а), Ардакуа.

Зирәк акыллы сәяхәтче үзе булган илләрдәге Харәзем һәм бигрәк тә якыннан танышкан болгар төркиләрендәге сүзләрнең язылышындагы аерым нечкәлекләрне дә сизгән һәм аларны язуда сакларга тырышкан.

---

[1] [Кырыенда З. Максудова искәрмәсе: «Гариб Болгари хакында әле матбугатта сүз ачылмаган, шунлыктан аның иҗадыннан мисаллар китерү урынсызрак буладыр. *З.М.*»].

Болгар илендәге язу практикасында «уау»дан соң гына түгел, хәтта урыны белән «уау» белән бәйләнмәгән әлифне дә язу билгесе итеп карарга туры килә. XIII йөз галиме, «Тәрҗемани фарси-төрки вә могули» сүзлегенең авторы «уау»дан соң «әлиф» белән язу кайбер төрки халыкларда гадәт булып санала дип яза. Болгар-татарларда шушылай язу традициясе тагын да көчлерәк булган. Димәк, болгар-татар кабер ташларындагы әлиф белән язылган «көн», «җите» сүзләрен «кү(а)н», «җи(а)те» дип укырга урын калмый. Бу типтагы кабер ташларында күчте фигылен искә алмаганда, нигездә бултуи (булды) һәм тындуи (тынды) кебек ике генә фигыльнең язылган булуы: «булды»ның һәрвакыт «вафат» сүзе белән, «танды»ның сәфәр сүзе белән генә килүләре дә штамп формасына әверелгән язу традициясен генә күрсәтә.

Биредә «Дастане Могҗизат» телендәге сүзләрнең үзенчәлекле формаларыннан кайберләре генә күзәтү рәвешендә алынды. Төрлелек һәм үзенчәлекләр язу кагыйдәләре белән дә бәйләнгән булырга мөмкин. Ләкин әсәрнең язу-хатында төпле кагыйдә юк, бер үк сүзләрнең төрлечә язылышы очрый. Күп вакытта «с» астына, борынгы традиция буенча, өч нокта куелган. Иде, иле кебек ярдәмче фигыльләр күбесенчә үзеннән алда килгән сүз белән кушылып язылалар: аның илә – аныңилә, уң иде – уңиде, кыйлмыш иде – кыйлмышиде, кыйлмышди.

Сөләйман Саксини әсәрендәге сүзләрдән бик борынгы дип хисапланганнарын да без соңны вакытлардагы татар теле фактларында күрә алабыз.

Һәм һидайәт былбылы анда үти,
Һәм сәгадәт сөмбеле җанда бети.
(10)

Бу ике юлның ахырында килгән «былбылы үти» һәм «сөмбеле бети» дигәндәге «үти» (яисә «үтте»), «бети» (яисә «бетте») сүзләре «үтте, үтеп китте», «бетте – юкка чыкты» мәгънәләрендә килмәгән. Үти – сахра; үтмәк – сайрау һәм бети – үсә, бетмәк – үсү фигыленнән. Ул ике юлны хәзерге сүзләр белән:

*Һәм хак юл былбылы анда сайрый,*
*Һәм бәхет сөмбеле җанда үсә,* –

дип бирергә мөмкин.

Сөләйман Саксини дастанындагы әнә шундый борынгы саналган сүзләр дә татар әдәбиятының соңгы вакытларга кадәр саклап булган истәлекләрендә, хәтта халык җырларында да яшәп киләләр.

Канәфәр чәчдем – гөл бетте,
Гөл чәчәкләрен җил түкте.
(«Җырлар китабы», 1880, б. 7)

Аллар бетеп, гөлләр үскән
Безнең җанкәй битенә.
(«Җырлар көлтәсе», 1918)

Бу ике мисалдагы «гөл бетте», «аллар бетеп» тезмәләре дә «гөлләр үсте», «аллар үсеп» дигән сүз була. Халыкның зирәк аңы «Аллар үсеп, гөлләр үсеп» димәгән, үскән сүзен кабатларга теләмәгән, аның икенче синонимын кулланган. Яисә:

Бакчада гөлләр бетәдер,
Арасында былбыл үтәдер.
(«Җырлар», 1880, 20)

«Үтәдер» ягъни «сайрыйдыр – сайрый». Болар борынгы җырлардан булырга тиешләр, әмма алар – халыкның үзенең иҗаты, үз теленең үрнәкләре. Һәм болар барысы да татар теленең нигезендә Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат» әсәре теле ятканлыгын күрсәтәләр.

Югарыда китерелгән фактлардан күренә ки, Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат» әсәре тел үзенчәлекләре һәм сурәтләү чаралары ягыннан болгар-татар әдәбиятының бөтен чорлардагы ядкярләре белән, хәтта каберташ язулары һәм халыкның җанлы сөйләм теле белән дә нык бәйләнгән. Димәк, ул – Болгар иле әдәбияты җимеше, болгар-татар поэзиясе мирасы.

## «Дастане Могҗизат»ның шигырь төзелешенә карата

«Дастане Могҗизат» – эшләнеше ягыннан чын мәгънәдә зур поэтик әсәр, Идел буенда хәзергә билгеле булган, иң борынгы хисапланган әдәби мирас. Аның шигъри юллары ниндидер бер трафарет калыпка салынмаган. Бу үзе генә шул заманда Идел буендагы төрки поэзиясенең колачы киңлеге хакында сөйли. Әсәрнең күп өлеше унбер иҗекле бәхре рәмәл үлчәвендә язылган, соңгы сүзләре рифмалашып килгән ике юллы бәеттән тора.

Су дик акызуп күзүңездән канлу йәш,
Агласунлар сездәр илә таг-у-таш.

Ләкин кайбер хикәятләр башка үлчәүдә һәм тәртиптә язылганнар.

Сусадым, суны теләдем эчмәгә,
Үирделәр бер кадәх[1] дулу ширбәти;
Кардан агыйди һәм суыгыйди,
Дәхи ширинди[2] шәкәрдән ләззәти...

Шигъри юллар шулай төзелеп китә, бәетләрнең икенче юлларындагы сүзләр генә рифмалашып килә. Алардагы аһәң һәм моң гармониясе ул юлларны бербөтен ясый.

Яисә строфаларның өч юлындагы соңгы сүзләр аваздаш килә, ә дүртенче юл калган куплетларда кабатлана яисә рифмалаша – яраша. Мәсәлән:

[1] Кадәх – кясә, савыт.
[2] Ширинди – ширин (баллы) иде.

Андан уман шәфагати,
Җанилә дотар сөннәти,[1]
Кәлең, идәлем хөрмәти, –
Дугдугый ай кәлди йәнә.
(3)

Шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйның күп назымнары – көйле шигырьләре «Дастане Могҗизат»тан китерелгән әнә шул шигъри үлчәү һәм алымда язылганнар. Менә аның үзенең сөйгән кызын мактап язган кайбер юллары:

Йөзеңи[2] әйләде гөл тик,
Сачыңи кыйлды сөмбел тик,
Авазың итте былбыл тик,
Идүп фазлы гыйнайәти[3].
Гаҗәбдер бер билең анчә,
Ләбең ләгыль, дешең гончә[4],
Йук ирди күрдекем бончә,
Күрүбән күп кямаләти[5].
(«Сахибҗамал бәете»ннән, 25).

Кандалыйның бу юллары турыдан-туры Сөләйман Саксининың шигырьләрен хәтерләтәдер. Ул «Дастане Могҗизат» белән таныш булу гына түгел, аннан нык өйрәнгән, элгәрләренең мирасыннан иҗади оста файдаланган.

Сөләйман Саксини әсәрләре шигъри яктан нәфис эшләнгәнлеге белән аерылып торалар. Моның шулай икәнлеген югарыда китерелгән ике юллы бәеттән дә яхшы сизеп була:

Һәм һидайәт былбылы анда үтти,
Һәм сәгадәт сөмбеле җанда бетти.

*Һәм хак юл былбылы анда сайрый,*
*Һәм бәхет сөмбеле җанда үсә.*

Бу юлларда чын мәгънәсе белән төгәл рифмалар булу өстенә, тезмәләрдәге калган сүзләр – барысы да үзара бөтен яктан ярашып килгәннәр: сузык һәм тартык авазларның чиратлашулары да, алардагы яңгыраш та шигырьнең living бербөтен эчке музыкаль мелодиясенә барып кушылалар.

М. Кашгари үзенең сүзлегендә күп төрки халыкларның авыз иҗаты һәм язма поэзиясеннән шигъри үрнәкләр теркәгән. Анда нәкъ Сөләймандагы шикелле алым белән, бер үк үлчәүдә һәм формада язылган куплет та китерелә. Ул – болгар поэзиясенең беренче карлыгачларыннан, шигърият бакчасының беренче хәбәрчеләреннән.

---

[1] Ике юлның мәгънәсе:
Аннан үзен яклауны тели, –
Җаны белән аның гадәтләрен тота.

[2] Китапта: «буеңны».

[3] Ярдәме һәм юмартлык итеп.

[4] Юлның мәгънәсе: иреннәрең – якут, тешләрең – чәчкә бөресе, төймәсе.

[5] Кямаләти – төгәллеге.

Әтел суы ака торур,
Кыйа төби кака торур,
Балык тәлим бака торур, –
Күлүң тәкый кушәрүр[1].
[Кашгари, 1960, I, с. 103]

Бу шигъри форма Идел буе болгар-төркиләрдә аларның «имди» белән язылган «Авык кыйссасы» һәм «Кыйссаи Йосыф» әсәрләре иҗат ителгәнчегә кадәр үк киң урын алган була. Сөләйман Саксини дастаннарын, халык авыз иҗаты әсәрләрен, «Авык» кыйссаларын эченә алган болгар поэзиясе җирлегендә мең яшьлек имән кебек аның өскә калыккан классик үрнәге – Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы. Үзеннән алда бай поэзия җирлеге, шигърият практикасы булмаса, «Йосыф китабы» кебек югары сәнгать әсәрләре тумас та иде. Нәкъ менә шушындый хәлне күз алдында тотып, Белинский болай язды: «Поэзиянең шулай ук үзенең яше бар, ул һәрвакыт халыкның яшенә тиң» [Белинский, с. 10]. Моннан берничә еллар элек, «Дастане Могҗизат», «Авык кыйссасы» кебек әсәрләр әдәбиятыбызга әле билгеле булмаган вакытта, әдәбиятчы Р. Бикмөхәммәтов: «Гали бу гүзәл поэмасыннан («Йосыф китабы»ннан) тыш та бик күп әсәрләр язгандыр һәм без белмәгән күп кенә татар (болгар) шагыйрьләренең әдәби тәҗрибәләренә таянгандыр дип уйларга кирәк. Поэманың әдәби теле, поэтик синтаксисының чын сәнгатьчә югарылыгы әле Галигә кадәр үк җитлеккән әдәби традицияләрнең булуын раслый», – дип язуында хаклы иде [Бикмөхәммәт, б. 36].

«Дастане Могҗизат» үзеннән соңгы күп әдипләргә рух биреп, аларга үрнәк булып торган. Хикәятләрдән берсендәге:

Башлайалем кирү бер сүз сүзилә,
Уд сачсун бу сүземдән сүзилә, –

дигән бәет бөтен тышкы формасы һәм сүзләре белән соңыннан «Кисекбаш» дастанына килеп керә. Унбер иҗекле рәмәл үлчәвендәге ике юллы бәет татар поэзиясендә озын тарих буенча килә. Гариб Болгари, Хисам Кәтиб, Мөхәммәдьяр, М. Колый (Меллагол), Утыз-Имәни, хәтта Тукайдан соңгы шагыйрьләр дә шул шигъри үлчәүдә яздылар, ә лексикаларының нигезендә шул ук сүзләр булды. Мәсәлән, Сөләйман Саксинида:

Һәрки гакыйлдыр сүземни аңлар ул,
Һәм гакылсыз кем сүземни таңлар ул.

Мөхәммәдьярда:

Укыган гакыйль кешеләр аңлагай,
Бу зәгыйфь бичарә колына таңлагай.
(«Нуры-Содур»)

[1] Соңгы ике юлның мәгънәсе:
Балык күпләп карый тора,
Күле күшәрелеп – җәйрәп ята.

Сөләйман Саксинида:

Бонларә чук дерлү нәсыйх[1] әйләди,
Халкый[2] лотфилә[3] йанлари[4] туйлады.

Утыз-Имәнидә:

Безгә вирдең бер китап, хуб әйләдең,
Йахшы сүзлә күңлемезни туйладың.

Мондый мисалларны тагын да китереп булыр иде. Аның болары да төрле заманнарда яшәгән татар шагыйрьләре иҗатларының, алар әсәрләрендәге тел чараларының уртаклыгы, бер үк поэзиянең традицияләре хакында сөйлиләр. Идел буенда Болгар җирлегендә иҗат ителеп, бөтен Урта гасырлар болгар-татар поэзиясенә зур йогынты ясаган, шагыйрьләргә үрнәк булып торган «Дастане Могҗизат» күп дәверләр буена укучыларның эстетик сорауларына хезмәт итеп килгән һәм халыкның зур ихтирамы аны буыннардан буыннарга тапшырып, безнең көннәргә китереп җиткергән.

### Кайбер сөземтәләр

Җыеп әйткәндә, Сөләйман бине Дауд Саксининың күркәм әдәби тасвир сыйфатлары белән тезелгән «Дастане Могҗизат»ы, һичшиксез, Идел буендагы шул заман болгар чоры әдәбиятының күренекле әсәрләреннән берсе булырга тиеш.

Соңгы вакытларда табылган яңа археологик материаллар Казан галимнәренә Идел-Кама болгарларының элгәрләре белән бәйләнешле аерым мәсьәләләрне хәл итәргә юл ачкан кебек [Генинг, Халиков, 1964; Халиков, 1966], Сөләйман Саксини әсәрләре дә шул заманда Болгар дәүләте ирешкән культура, әдәбият, философия, әхлак-мораль, фикъһе-юриспруденция фәннәре турында яңача фикер йөртеп, аларны яңача бәяләргә нигез бирә. Сөләйман бине Дауднын зур поэтик әсәре булган «Дастане Могҗизат» борынгы Идел буе төрки әдәбияты, ягъни болгар-татар әдәбияты турындагы төшенчәне тагын да киңәйтә һәм Галинең «Йосыф китабы» кебек әсәрләрне яхшырак төшенергә, ныклабрак өйрәнергә юл ача, аларның болгар-татар әдәбияты әсәрләре икәнлеген бәхәссез ясый.

Сөләйман әсәрләренең теле – кыпчакча тел, анда көньяк төркиләре, угыз элементларының урын алуы гаҗәп түгел. М. Кашгари угыз, кыпчак, бәҗәнәк, ямәк, сувариин, болгарларның бер географик киңлектә аралашып яшәгәнлекләре хакында сөйли, аларның телләрендәге үзенчәлекләрне дә күрсәтә [Кашгари, 1960, I, с. 68; II, с. 53]. Ибне Фадлан Болгарга килгән вакытта, болгар халкы Алмасның хатыны угыз ханнарыннан берсенең кызы булганлыкны, Болгарда Харә-

[1] Нәсыйх – киңәш итү.
[2] Халкый – халыкны.
[3] Лотфилә – шәфкатьлеге белән.
[4] Йанлари – әйләнә-тирәдәгеләрне.

зем төрекләренең яшәгәнлекләрен әйтеп уза [Ковалевский, с. 129–140 (перевод), 202б–209а (текст)]. Әбүл-Гази да кыпчакларның Дон, Идел һәм Җаек елгалары арасындагы урыннарда яшәгәнлекләрен сөйли [Родословное..., с. 34]. Чиктәш угыз кабиләләре, Харәзем төрекләре белән тыгыз сәүдә, экономик һәм культура мөнәсәбәтләрендә булу, хәтта кыз бирешеп, кыз ярәшеп, ыруг-кардәшлек бәйләнешләрендә яшәү Идел буе төрки теленә тәэсирсез калмаска тиеш иде. Болгар илендә язылган әсәрләрнең телендә көньяк төркисе – угыз элементларының булуы да үткәндәге шул социаль тарихи шартлар белән бәйле. Урта гасырлар болгар-татар әдәбиятының нигезен тәшкил иткән Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы кебек әсәрләрнең телләрендә угыз элементлары булганлыктан, кайберәүләр тарафыннан болгар-татарныкы итеп танымаска тырышуларның да сәбәбе әле генә саналган шартлар белән исәпләшмәүдән, Идел буенда монголларга кадәр барлыкка килгән әдәбият мирасын якыннан өйрәнмәүдән һәм әдәбиятны тудыручы соңыннан татар исеме белән аталган болгар-кыпчак төрекләренең тарихи язмышы белән бәйләп карамаудан иде. Шунлыктан, Болгар дәүләтендә XII йөзнең урталарында ук формалашкан Идел буе әдәби теле танылмады, ә Сырдәрьяның түбән агымы буендагы культура үзәкләрендә барлыкка килгән Әхмәт Ясәви теленең таралу мәйданы артык киңәйтеп күрсәтелде. Хәтта XIV йөздә Алтын Урда заманында Урта Идел, Урал буйларында формалашкан әдәби телнең дә нигезе итеп Харәземнән килгән тел саналды. Мәсәлән, Әмир Нәҗип болай язды: Әхмәт Ясәви «хикмәтләре язылу белән XII йөздә төрки халыкларның икенче бер әдәби теле – угыз-кыпчак телләре нигезендәге әдәби тел барлыкка килә. Соңга таба бу әдәби тел Харәземдә тагын да үсә, Алтын Урда дәүләте төзелеп, Харәзем шуңа кушылганнан соң, бу дәүләттә формалашкан әдәби телнең нигезе итеп менә шул тел алына» [Нәҗип, б. 93].

Әлбәттә, Ә. Нәҗип бу юлларны язганда – XII йөзләрдә Идел буе төрки әдәбиятының булганлыгын күрсәтүче «Дастане Могҗизат» кебек әсәрләр әдәбият белемендә әле телгә алынмыйлар иде.

Сөләйман Саксини әсәрләре күрсәткәнчә, XII йөзнең урталарында нәкъ Әхмәт Ясәвинең әсәрләре Сырдәрьяның түбән агымында иҗат ителгән вакытларда, Болгар дәүләтендә, ягъни Иделнең урта агымыннан алып, Каспийга кадәр җәелгән аралыкта, Әхмәт Ясәви хикмәтләреннән һәм аларның теленнән башка, мөстәкыйль бер әдәбият һәм әдәби тел барлыкка килә. Бу үзенең теле, стиле – өслүбе белән генә түгел, идея-эчтәлеге белән дә Әхмәт Ясәвинең динимистика, суфичылык идеяләре белән сугарылган хикмәтләреннән башка юнәлештәге, дөньяви характердагы әдәбият һәм поэзия була. Ул – болгар галиме, әдибе һәм шагыйре Сөләйман бине Дауд Саксини Сувари әсәрләре һәм аларның теле. Бу – угыз-кыпчак теле түгел, ә, Н.А. Баскаков сүзләре белән әйткәндә, «болгар һәм кыпчак ыру телләренең үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән» [Баскаков, с. 160] болгар-кыпчак (борынгы татар) теле. Идел буенда монголлар

килгәнчегә кадәр формалашкан җирле әдәби тел – шул тел була. Җ. Алмаз фикеренчә, Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре дә әнә шул әдәби телдә язылган [Алмаз, 1960].

Монгол яулап алучылары килгәч, Идел буендагы бердәнбер культура үзәкләреннән булган Болгар шәһәрләре җимерелә, халкы буйсындырылып, дистәләрчә галимнәре, язучылары һәлак ителә, иҗат эшчәнлеге, әдәбият һәм әдәби тел үсеше тоткарлана. Ләкин соңга таба, яулап алучылар, үзләрен әйләндереп алган күпсанлы җирле болгар-кыпчаклар тәэсиренә бирелеп, аларның диннәрен дә кабул иткәч, җирле халыкның телен дәүләт теле итеп танырга мәҗбүр булалар. Шул хәлдә, яңа тарихи шартларда элекке Идел буе төрки әдәби теле яңадан җанланып китә, яңа әсәрләр иҗат ителә башлый. Бу – Алтын Урда ханнарының теләве белән түгел, тарих процессының таләбе белән була. Бу – Болгар дәверендә XII йөзнең урталарында формалашкан әдәби тел үсешендәге икенче этап булып тора. М. Сәфәргалиевнең исә хәзерге татар теленең тарихын кыпчак теленең Алтын Урда дәвере белән генә чикләп каравы һич тә дөреслекне чагылдырмый [Сафаргалиев, с. 36]. Чыннан да, Алтын Урда дәүләте үзәге булган Иделдә XIV йөз урталарында формалашкан әдәби тел кайдандыр Харәземнән китерелгән тел түгел; әйткәнебезчә, ул – Идел буендагы күпсанлы җирле төрки халыкларның, болгар-кыпчакларның җанлы сөйләм теле нигезендә икенче социаль шартларда алга таба үсеп киткән тел. Татар теленең формалаша башлавын болгар чорыннан аерып алу мөмкин түгел. Вахит Хаков: «Үзенең локаль үзенчәлекләре белән татар әдәби теле X–XIV йөзләрдә Урта Идел һәм Кама буйларында формалаша» [Хаков, б. 33], – дип язуы белән, мәсьәләгә дөрес якын килә. Чөнки «яңа дәүләт составына кергәч тә, Болгар Алтын Урда культурасын үз тирәсендә формааштыручы үзәк булып торган» [Смирнов, с. 74]. Үзенең шундый югары культурасы, әдәбияты булган һәм Алтын Урта дәүләтенең төп халкын тәшкил иткән кыпчакларның әдәби теле мистик Әхмәт Ясәви хикмәтләре теленнән килә дип билгеләргә тырышу җәмгыятьнең үсеш законнарына туры килми. Монда икенче бер нәрсәне генә онытырга ярамый. Ул да булса, битикче – язучы уйгурларның да, шунда яшәгән харәзм төркләренең дә ул әдәби телгә йогынтысы көчле булган. XIV йөзләрдән алып, Идел буенда болгар-татар телендә иҗат ителгән әсәрләр лексикасында уйгур элементларының киң урын алуының да сәбәбе шул хәл белән аңлатылырга тиеш.

Борынгы Идел буе төрки әдәбияты вәкиле Сөләйман Саксинига багышланган бу хезмәт хәзергә беренче тәҗрибә буларак каралырга тиеш. Киләчәктә шагыйрьнең башка әсрәләре яисә аның үзе турында яңа материаллар табылуы мөмкин; андый хәлдә бу талант иясенең иҗатын тагын да ныклабрак өйрәнергә булыр. Ләкин, бәхет йолдызы киләчәктә ниләр генә китермәсен, Сөләйман бине Дауд Саксини-Сувари һәм аның «Дастане Могҗизат» әсәре болгар-татар әдәбияты

тарихында лаеклы урынны алыр һәм аңа тиешле бәя дә бирелер дип өмет итәргә кирәк, чөнки чын сәнгать әсәрләре үлүне белмиләр.

8.05.1969

### Әдәбият

*Алмаз Җ.* Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. 1960. № 2.

*Бартольд В.В.* Сочинения. М.: Изд-во вост. лит., 1963, т. 2, часть 1, 710 (место прикаспийских областей в истории мусульманского мира).

*Баскаков Н. А.* Тюркские языки / отв. ред. Г.Д. Санжеев; Институт языкознания АН СССР. М.: Изд-во вост. лит., 1960. 248 с.

*Белинский В.Г.* Избранное. М.: Московский рабочий, 1954.

*Бикмөхәммәт Р.* Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре (традицион образларны өйрәнү тәҗрибәсеннән). Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Валитова А.* К вопросу о фольклорных мотивах в Кутадгу билик // Советское востоковедение. 1958. № 5.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге (Больше-Тарханский могильник). М., 1964.

*Греков Б.Д.* Избранные труды, т. 2, изд. АН, М., 1959, 569 (Волжские болгары в IX–X вв.).

*Заходер Б.Н.* Каспийский свод сведений о Восточной Европе (Горган и Поволжье в IX–X вв.). М.: Изд-во вост. лит., 1962, 144 бит.

*Карамзин Н.М.* История государства Российского. Т. 3, изд. второе, исправ. СПб., 1818.

*Кашгари М.* Диван лөгатет-төрк. 2. Истанбул, 1338/1915, 70 б.

*Кашгари М.* Диван. I. 68; II, 53 (Ташкент).

*Кашгари М.* Диван. Ташкент, 1960. I, 103.

*Ковалевский А. П.* Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956.

*Лихачев Д.С.* Человек в литературе Древней Руси М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1958.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951.

*Маркс К.* «Политик экономияне тәнкыйть итүгә карата»га сүз башы // Маркс К., Энгельс Ф. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Т. 1. Казан, 1949.

*Маркс К., Энгельс Ф.* Манифест Коммунистической партии. Госполитиздат, 1952.

*Маркс К.* Тезисы о Фейербахе (Ф. Энгельс. Людвиг Фейербах и конец классической немецкой философии. Госполитиздат, 1952.

*Маркс К.* К критике политической экономии. Госполитиздат, 1951.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // МТД, 2, Казань, 1962.

*Махмутова Л.Т.* Фонетические особенности касимовского говора татарского языка // МД, Таткнигоиздат, 1955.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфад әл-Ахбар.... 1. Казан, 1897.

*Нәҗип Әмир.* XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи һәм аның заманы // Совет әдәбияты. 1957. № 4. Б. 93.

*Плано Карпини.* История монголов / под ред. Н.П. Шастиной, ГИГЛ. М., 1957.

ПСРЛ, т. 1, Лаврентьевская летопись (вып. 2 Суздальская летопись по Лаврентьевскому списку). Изд. второе. Л., 1927.

Родословное древо тюрков / соч. Абуль-Гази, Хивинского хана; перевод и предисловие Г.С. Саблукова. Казань: Тип. импер. ун-та, 1906.

*Рясянен М.* Материалы по исторической фонетике тюркских языков / перевод с немец. А.А. Юлдашева. М.: ИЛ., 1955.

*Сафаргалиев М.Г.* Распад Золотой Орды. Саранск: Мордва книгоиздат., 1960.

*Смирнов А.П.* Древняя история чувашского народа. Чебоксары: Чувашгосиздат, 1948.

*Тенишев Э.Р.* «Материалы по татарской диалектологии» (рец.) // Вопросы диалектологии тюркских языков. Т. IV. Изд-во АН АзССР, Баку, 1966. Б. 216–220.

Ф. Людвиг Фейербах и конец классической немецкой философии. Госполитиздат, 1952.

*Хаҗи Хәлфә.* Лексикон. Т. 2, 3.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле буенча очерклар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965.

*Халиков А.Х.* Среднее Поволжье в эпоху камня и бронзы: автореф. дис. ... д-ра ист. наук. Казань, 1966.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу Али Ахмеда бен Омара Ибн-Даста. СПб., 1869.

*Хлебникова Т.А.* Основные производства волжских болгар периода X – начала XIII в.: автореф. дис. ... канд. ист. наук. 1964. 25 с.

*Шамгунова Р.* Чистай сөйләшенең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре // МТД, 2.

*Текстны басмага әзерләде:*
***Әлфрид Кашаф улы Бостанов,***
*Ph.D., Амстердам университеты ассистент-профессоры*

УДК 81′282.2

*Ә.К. Булатова*

# АЗНАКАЙ РАЙОНЫ МӨСЛИМ АВЫЛЫНЫҢ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Изучение говора населенного пункта, способствует выявлению ведущих тенденций развития диалектных систем татарского языка. В ходе анализа фиксаций особенностей речи жителей деревни Муслюмово Азнакаевского района Республики Татарстан выявлено, что в результате экстралингвистических и интралингвистических причин и факторов произошло некое смешение различных говоров, относящихся к двум основным татарским диалектам.

**Ключевые слова:** диалектология, мишарский диалект татарского языка, средний диалект татарского языка, кузнецкий говор, мензелинский говор.

The study of settlement dialects helps to identify the leading trends in the development of dialect systems of the Tatar language. In the analysis of the recordings of speech peculiarities of the village inhabitants in the Muslyumovo, Aznakayevsky district, Republic of Tatarstan, it was revealed that as a result of extra-linguistic and intralinguistic reasons and factors, a certain mixture of various dialects related to the two main Tatar dialects occurred.

**Key words:** dialectology, Mishar dialect of the Tatar language, middle dialect of the Tatar language, Kuznetsk dialect, Meenzalya dialect.

Хәзерге татар диалект системасында тел үсешенең бүгенге көн этабына хас булган үзенчәлекле күренешләр урын ала. Дөньяда барган техник процесс авыл тормышының икътисади һәм иҗтимагый өлкәләренә зур йогынты ясый, шул рәвешле аерым сөйләшнең (сөйләшләрнең) яшәеше, аның әдәби тел белән бәйләнышлары да берникадәр үзгәреш кичерә.

Хәзерге көндә татар теленең диалект системасында берничә дистә ел элек кабул ителгән ареал чикләр үзгәрә. Телдә барган процесслар, шулай ук сөйләш вәкилләренең башкалар белән аралашуы нәҗтиҗәсендә, сөйләшнең үзенчәлекләрендә аерымлыклар барлыкка килә. Шуңа нисбәтле аерым сөйләш торышын һәм үсешен өйрәнү татар диалектологиясе өчен актуль мәсьәлә булып кала.

Әлеге мәкалә кысаларында 2019 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Азнакай төбәгенә оештырылган комплекслы экспедиция материаллары нигезендә Мөслим авылында урын алган җирле сөйләш үзенчәлекләре ачыклана.

Җирле сөйләш үзенчәлекләренә мөнәсәбәттә Мөслим авылы – Азнакай районында, шулай ук Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышында мишәр диалектына караган бердәнбер авыл. Торак пункт Азнакай шәһәреннән көнбатышка 36 чакрым ераклыкта, Ык елгасының сул ярында урнашкан. Урсай авыл җирлегенә карый.

2010 елгы халык саны алу вакытында 263 кеше яшәгән, хәзерге авыл җирлеге мәгълүматларына караганда 207 кеше яши (83 хуҗалык). Авылда башлангыч мәктәп, мәдәният йорты бар. Тарихы ягыннан авылга 1870 елларда нигез салына: Пенза губернасының Чатука, Гөренка, Татар Шелдаусы, Урман асты авылларыннан берничә гаилә күченеп килә [Зарипов, б. 80]. Авыл халык телендә Мишәр Мөслиме дип аталып йөртелә. Рус телендәге атамасы: Муслюмово (кайбер чыганакларда Новая Муслюмкина). Авыл исеме «Мөслим» антропонимыннан килеп чыккан дип күзаллана (Азнакай районы белән чиктәш Мөслим районы һәм авылы бар). Халык нигездә авыл хуҗалыгында, нефть чыгару сәнәгатендә эшли.

Авылның җирле сөйләше татар милли теле, аның диалектлары системасында үзенчәлекле урын алып тора. Аерым алганда, ул татар теленең ике төп диалекты йогынтысы нәтиҗәсендә формалашкан. Беренчедән, авылга мишәр диалекты вәкилләре нигез салган. Икенчедән, авыл халкы тирә-юньдәге башка торак пунктларның халкы белән тыгыз аралашып яшәү нәтиҗәсендә, сөйләмнәренә урта диалектның минзәлә сөйләше үзенчәлекләре дә кереп киткән. Шул ук вакытта авыл сөйләшендә мишәр диалектының кузнецк сөйләшенә хас үзенчәлекләр шактый системалы рәвештә сакланып калган дип әйтә алабыз. Әле сөйләшкә түбәндәге үзенчәлекләр хас: [а] сузыгының иренләшмәве, [о]~[ы], [о]~[ы], [у]~[ы], [ө]~[ә], [ү], [э]~[ө], [ә]~[и] тәңгәллекләре характерлы. Кузнецк сөйләшендә [о]~[ө] авазлары иренсезләштереләләр. Әдәби телдәге [ай]/[әй], [уй] дифтонглары сөйләштә [а]/[ә] авазларына туры килә, алардан соң килгән тел очы тартыклары йомшара. [Өй] дифтонгына [ү] авазы туры килә. Рус теле сүзләре сөйләшнең үз әйтелешенә яраклаштырып кулланыла. Сөйләштә й-лаштыру күзәтелә, шулай ук [х]~[к] тәңгәллеге хас, [т]>[ч], [н]>[м], [п]>[б], [н]>[ң], [с]>[ч], [м]>[б], [ңл]>[лг] һ.б. ассимиляция-диссимиляция күренешләре дә урын ала. Грамматик үзенчәлекләргә килгәндә, 1 нче һәм 2 нче зат берлек сандагы алмашлыклар юнәлеш килешендә *мәңа, сәңа* формасында кулланыла, хәзерге заман хикәя фигыльләрнең 3 нче зат берлек санында әдәби формага еш кына *-дыр/-дер* хәбәрлек кушымчалары ялгану күзәтелә, фигыльләрнең йөкләтү юнәлеше формасы *-кыз/кез, -гыз/-гез* кушымчалары *-гыр/гер, кыр-кер* ярдәмендә ясала. Теләк, ният мәгънәсен белдерә торган фигыль формалары *-гы/-ге* формалы фигыльгә тартым кушымчасы һәм *кели* сүзе кушылып ясала [Татар халык сөйләшләре, 2: б. 42–53].

Шул ук вакытта Азнакай төбәгенә хас урта диалектның минзәлә сөйләше вәкилләре белән тыгыз аралашып яшәү нәтиҗәсендә, авыл кешеләренең телләре үзгәреш кичергән, мишәр сөйләшенең кайбер үзенчәлекләре җуелган, югарыда күрсәтелгән сөйләшләр берникадәр катнашып киткән.

Азнакай районы диалекталь бүленеш буенча урта диалект минзәлә сөйләшенең төп урынчылыгына карый. Әлеге урынчылыкның

түбәндәге үзенчәлекләре бар: сүз башында әдәби телдәге [й] урынына [ж] кулланыла (ягъни җ-лаштыру). [Өй ] дифтонгы сүзнең беренче иҗегендә монофтонглаша, шуның белән бергә, кайбер сүзләрдә [өй] дифтонгы саклана. Шулай ук [х]~[к] тәңгәллеге хас, [з]>[ч], [н]>[м], [л]>[н], [н]>[ң], [с]>[ч], [ш]>[ч], [ц]>[ч], [ф]>[к] ассимиляция-диссимиляция күренешләре күзәтелә. Рус теленнән кергән сүзләрдә [в] урынына [б] кулланыла.

Түбәндәге грамматик үзенчәлекләр күзәтелә: тартымлы исемнәрдә, билгеле төшем килеше белән төрләнгәндә, *-ны, -не* кушымчасының «*н*» элементы йотылып әйтелә, әдәби телдәге билгесез үткән заман кушымчасы *-ган*, *-гән* урынына кушма формант *-ырлык*, *-ерлек* кулланыла, үткән заман хәл фигылен белдерү өчен кушма формант *-гачтын*, *-гәчтен*, *-гачтан*, *-гәчтән*, хикәя фигыльнең күптән үткән заманын белдерү өчен кушма формант *-дырые*, *-дерие* файдаланыла [Татар халык сөйләшләре, 1: б. 212–241].

Мөслим авылы кешеләренең телендә, 2019 елгы диалектологик экспедиция материаллары нигезендә, мишәр диалектының кузнецк сөйләшенә караган түбәндәге фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр ачыкланды.

1. Кузнецк сөйләше өчен характерлы үзенчәлек – әдәби телдәге [у], [ү] ирен сузыклары таррак әйтелә, сүзләрнең беренче иҗегендә килгәндә, алар дифтонгоид [ү°], [у°] булып та әйтеләләр. Әлеге үзенчелек башка мишәр диалекты сөйләшләрендә дә күзәтелә: *йу°л* – йул, *кү°п* – күп, *дү°рт* – дүрт, *кү°р* – күр һ. б.

2. Түбәндәге күчешләр хас:

[у°]~[о]: *умер* – гомер, *үмэ*/*ү°мэ* – өмә һ.б.

[ү°]~[ө]: *үй* – өй, *сүлим* –сөйлим һ.б.

[о]~[ы] һәм [у]~[ы], [ы°]: шылай/шы°лай/шолай; шындый/ шы°ндый/ шондый дип әйтеләләр, шул ук вакытта диалекталь формалар белән бергә, шулай, шундый/шу°ндый варианты да кулланыла.

3. Рус сүзләрендәге [о] авазы, кузнецк сөйләшенә хас булганча, [у] авазы белән алмаштырыла: *кину* – кино, *вагун* – вагон һ.б.

4. Рус теле сүзләре сөйләшнең үз әйтелешенә яраклаштырып кулланыла: рус алынмаларында [е] авазы [и], [ә] авазлары белән алыштырыла: *писук* – песок (шикәр комы), *сәстра* – сестра (апа) һ.б.

5. Метатеза күренеше күзәтелә: *урнысы* – [аның] урыны, *борнысы* – [аның] борыны һ.б.

6. Тирән тел арты тартыклары урынына тел арты [к], [г], [х] кулланыла: *нәк* – нәкъ [нәқ], *каты* – каты [қаты] һ.б.

7. Кайбер очракларда ике сузык арасында килгәндә, [г] саңгыраулаша: *тукыз* – тугыз һ.б.

8. [к]~[х] күчеше күзәтелә: *катын* – хатын, *йакшы* – яхшы [йахшы] һ.б.

Татар әдәби телендәге [х] урынына [к] әйтү теге яки бу күләмдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә очрый. Шулай ук бу үзенчәлек кузнецк сөйләшендә дә күзәтелә. Татар диалектологиясендә ул

бигрәк тә урта диалект үзенчәлеге дип санала. Урта диалектның минзәлә сөйләшендә исә аерым сүзләрдә генә күзәтелә.

9. [ғ] гарәп алынмаларында күп очракта төшеп кала: *ашик* – гашыйк [ғашыйк], *аҗәп* – гаҗәп [ғаҗәп] һ.б.

10. Ике сузык арасында килгәндә, [г] тартыгы аерым очракларда төшеп кала: *теел* – түгел, *теесе* – тегесе һ.б.

11. [п]~[б], [п]~[ф] тәңгәллеге урын ала. Бу сөйләштә дә татар әдәби телендәге ирен-ирен, рус һәм интернациональ телләрдәге ирентеш өрелмәле [ф] йомык [п] тартыгы белән алмаштырыла. Шулай ук [б] авазына [п] саңгырау авазы тәңгәл килә. Бу күренеш минзәлә сөйләшенең төп урынчылыгына хас булмаганга, без аны кузнецк сөйләше үзенчәлеге итеп карый алабыз: *потак – ботак, пету – бетту, тупрак – туфрак* һ.б. [ф] ~ [п].

12. ч-лаштыру күзәтелә: *кузнич* – кузнец, *нимеч* – немец һ.б.

13. [й]~[ж] күчеше характерлы: *йәйәү* – җәяү [җәйәү], *йәй* – җәй һ.б.

14. [н] ~[ң] күчеше: *Синен исемен кем?* – Синең исемең кем?

15. Тел уртасы [й] тартыгы кайбер очракта төшеп кала, аннан соң килгән тартыклар нечкәрә: *кач'ан* – кайчан, *кан'* – каян, *ад'ә* – әйдә.

16. Сөйләш вәкилләре гасырдан артык тирә-юньдәге башка авыл кешеләре белән тыгыз аралашып яшәгәннәр, шунлыктан телләренә бу төбәктә таралган татар теленең урта диалекты минзәлә сөйләше үзенчәлекләре дә кереп киткән. Әмма авыл кешеләре сөйләшендә, бигрәк тә өлкән буында әле мишәр диалектына караган күп кенә диалектизмнар яшәп килә: *варега* – бияләй, *кычык* – эт, көчек, *мачы* – песи, (*песи* сүзе белән беррәттән кулланыла), *бидра* – чиләк (минзәлә сөйләшендә дә шушы вариант файдаланыла); *кабак* – капка: *кабак төбе* – капка төбе, *кабак элеп кер* – капкаңны ябып кер (элек капканың келәсен элгәннәр, хәзер андый бикләр булмаса да, йозакка бикләсәләр дә, *элү* фигылен кулланалар), *ызба* – йорт, каралты-кура, *венә кайсы* – менә шул, *вота* – менә бу (рус телендәге *вот* кисәкчәсеннән), *кан'-кан' килденме* – ерактан килдеңме, *аппару ашаганнар* – ашап бетергәннәр, *кучетка* – кочерга, *бырат* – абый, ир туган, *сәстра* – апа, кыз туган, *кечеткән* – кычыткан, *кимак* – коймак, *виньык* – себерке (веник) һ.б.

Авыл халкы сөйләмендә шулай ук җирле Азнакай төбәгенең минзәлә сөйләшенә хас үзенчәлекләр дә очрый: *эскәмбия* – эскәмия, *буә* – буа, *сыза* – кечкенә сулык, сулы чокыр, *бәй* ымлыгының кулланышы, бүксә – эч, корсак һ.б.

Шуны да искәртеп китү урынлы, авылда яшәүче яшь буын, нигездә, әдәби телдә сөйләшә, алда искәртеп кителгән диалекталь үзенчәлекләр урта һәм өлкән буын кешеләрендә генә сакланып килә.

Хәзерге этапта татар теленең диалектларын динамикада өйрәнү, элек фәнни әйләнешкә кертелгән материалларны бүгенге көн торышы белән чагыштыру, тел күренешләрен халыкның иҗтимагый тормышы белән бәйләп карау ихтыяҗы бар. Төрле сөйләшләр аерым

ареал эчендә башка сөйләшләр белән катнашу нәтиҗәсендә, шулай ук әдәби тел йогынтысында яңа үзенчәлекләр алалар. Сөйләшләрнең үзара катнашып китүе җирле халыкның иҗтимагый бәйләнешләренә турыдан-туры бәйле була.

Татар теле диалектларының үсеш тенденцияләрен ачыклауда аерым торак пунктның сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнү мөһим. Азнакай районы Мөслим авылы кешеләренең тел үзенчәлекләрен анализлау нәтиҗәсендә без төрле экстралингвистик һәм интралингвистик фактор һәм сәбәпләргә нисбәтле татар теленең ике төп диалектына караган сөйләшләрнең катнашып китүен ачыкладык, шул ук вакытта мишәр диалектының кузнецк сөйләше аерым үзенчәлекләренең тотрыклы сакланып килүен дә күзәтәбез.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. Т. 1. 543 б; Т. 2. 567 б.

*Зарипов Р.С.* Еллар авазы. Азнакай: Интех, 1998. 96 б.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов: (мишарский диалект). М.: Наука, 1978. 271 с.

*Рамазанова Д.Б.* Вопросы татарской диалектологии. Казань: Алма-Лит, 2008. 271 с.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз. Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. китап. нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008.

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

# ӘЛФРИД БОСТАНОВНЫҢ «ЗӘЙНӘП МАКСУДОВА КИТАПХАНӘСЕ» (Мәскәү: «Мәрҗани» басма йорты, 2019) КИТАБЫНА РЕЦЕНЗИЯ

*Бустанов А.* Библиотека Зайнап Максудовой (Москва: ИД «Марджани», 2019)

2019 ел ахырында яшь галим Әлфрид Бостановның татар әдәби чыганакларын өйрәнүне һәм замана укучысына җиткерүне күз алдында тоткан «Зәйнәп Максудова китапханәсе» (Мәскәү: «Мәрҗани» басма йорты, 2019. 464 б.) исемле китабы дөнья күрде. Китапның мөхәррирләре: филология фәннәре кандидаты А.А. Хасавнех, тарих фәннәре кандидаты Ш.Ш. Шихалиев.

Китапның авторы турында: Әлфрид Бостанов – тарихчы, этнограф, Омск дәүләт университетының этнография һәм музей эше бүлеген тәмамлаган (2009), Россия Фәннәр Академиясенең Көнчыгыш кулъязмалар Институтында танылган галимнәр С.Г. Кляшторный, Т.И. Султанов җитәкчелегендә ике тапкыр стажировка үткән (2008, 2009 еллар), Амстердам университетында аспирантура тәмамлап, ислам белгече Михаэль Кемпер һәм Стефан Дюдюаньон җитәкчелегендә диссертация яклаган (2013), Ph.D докторы, Себер мөселманнарының китап мәдәниятен өйрәнү буенча монографик хезмәт һәм фәнни мәкаләләр авторы, Дагстан мөселман галимнәре биографияләре сүзлеген төзүчеләренең берсе. 2005 елдан башлап, ул Көнбатыш Себер, Көньяк Казакъстан, Дагстан һәм Идел буе төбәкләренә оештырылган археографик, этнографик һәм археологик экспедицияләрдә катнаша.

Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты, кулъязма чыганаклар тарихы белән кызыксынучы укучыга Ә. Бостанов совет заманында яшәгән мөселман җәмәгать эшлеклесе Кыяметдин әл-Кадыйриның (Кыям Кадыйров) үзенчәлекле әдәби мирасын, мөфти-фронтовик Габделбари Исаев эшчәнлеген һ.б. өйрәнүче галим буларак та таныш.

Зәйнәп Максудова (1897–1980) – совет заманында татарның ислам мирасын, борынгы татар әдәбиятын һәм кулъязмаларын саклау эшенә зур хезмәт керткән шәхес. Тәкъдим ителгән китап әлеге укытучы-галимәнең бай китапханәсен өйрәнүгә багышланган.

Зәйнәп Максудова (Зәйнап Габделҗәлил кызы бинте Габделмәннан бине Максуд бине Ибраһим бине Миңлебай бине Туйкуч әл-Болгари), Татарстанның хәзерге Әгерҗе районы (элеккеге Вятка губернасы) Уразай авылында дөньяга килгән, тарихы күп гасырларга сузылган татар имамнары нәселеннән. Үз вакытында заманының алдынгы уку йортларыннан берсе булган Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем ала, гарәп һәм башка көнчыгыш телләрен, рус телен өйрәнә. Әлеге белемнәре аңа киләчәктә борынгы язмаларны оригиналда уку

мөмкинлеге тудыра. Совет дәүләтенең башлангыч елларында ук татар балаларына рус телен, мәдәниятен актив таратучы булып таныла. Болардан тыш ул 1920 елларда Көнчыгышны өйрәнү юнәлешендә Ташкент шәһәрендәге Урта Азия дәүләт университетында Александр Шмидт һәм Александр Семенов кебек танылган галимнәрдә укый. Әлеге уку йортларында белем алу булачак галимәдә ислам тарихына һәм борынгы кыйммәтле чыганакларга үзенчәлекле караш формалаштыра.

Совет чорында Зәйнәп Максудова Казан шәһәре мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбиятын укыта, соңрак Казан педагогика институтына гарәп теле укытучысы булып эшли, ул вакыттагы Казан дәүләт университеты һәм Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре белән тыгыз элемтәдә тора.

Гомере буе мәктәп укытучысы булып эшләгән галимә 1957 елда лаеклы ялга чыкканнан соң гына үзен тулысы белән әлеге чыганакларны өйрәнүгә багышлый. Илдәге сәяси үзгәрешләр аңа ислам мәдәни мирасын халыкка кайтарырга мөмкинлек тудыра: бу чорда алдынгы карашлы милли зыялылар ачыктан-ачык борынгы әдәби мирасыбызның байлыгы, интеллектуаль традицияләрнең прогрессивлыгы хакында сөйли башлый.

Кулъязма чыганаклар туплаудан тыш, З. Максудова Сәйф Сараи, Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани кебек бөтен төрки дөньяга танылган атаклы шәхесләрнең хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итә; шулай ук тарихчы Сәед Вахиди, Бишбалта бистәсе имамы Исмәгыйль Габиди һ.б. ларның архивларын тәртипкә салырга да булыша.

Китап авторы Әлфрид Бостанов әйтүенчә, Зәйнәп Максудованың максаты татарлар арасында соңгы мең ел дәвамында кулланышта булган гарәп язулы китапларның каталогын төзү аша Идел буе ислам гыйлеме интеллектуаль генеологиясен реконструкцияләүдән гыйбарәт була. Һәм әлеге юнәлештә З. Максудова күп эшләр башкарырга өлгерә. Каталог төзелә һәм ул бүгенге көндә ТР Милли китапханәсендә саклана.

Әлеге мәдәни байлыклар, нигездә, Зәйнәп Максудованың үз өендә сакланган. XVII–XX гасырларда тупланган искиткеч бай кулъязма китаплар коллекциясе аңа мирас буларак кала: борынгы китаплар, кулъязмалар берничә буын Максудовлар тарафыннан җыйналып, кадерләп саклана. Әлеге китапханәдә мантыйк, шәригать буенча китаплар, поэзия үрнәкләре тупланган, күпчелек кулъязмалар Идел буе мәдрәсәләрендә укучы шәкертләр тарафыннан күчереп язылган, монда шулай ук Урта Азия һәм Мисыр манускрипт күчерелмәләре дә урын ала. Шулар нигезендә мөгаллимә үзенең мәгънәви яктан иң кыйммәтле булган хезмәтен башкара: татарлар тарафыннан башкарылган язмаларның тәфсилле белешмәлеген төзи. Болардан тыш, Максудова XV гасырдан башлап татар шигърияте антологиясен бөртекләп җыя.

Әлеге кыйммәтле ядкярләрне укучыга җиткерүдә Зәйнәп Максудованың кызы – медицина фәннәре кандидаты Гөлнара Газизованың да роле зур. Ул, әлеге мирасны саклап, Татарстан Республикасы Милли музеена тапшырган. Шул рәвешле, 1981 елга Максудова китапханәсенең зур өлеше Татарстан Милли музее фондына тапшырыла һәм шунда саклана, бер өлеше 1994 елда ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсенә, кайберләре КФУның Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә урын ала.

Шул рәвешле, Зәйнәп Максудова китапханәсе һәм архивы ТР Милли музееның татар мәдәнияте әһелләре шәхси коллекцияләренең бер өлешен тәшкил итә. Алар арасында XV–XX гасырга караган 191 данә татар, гарәп, фарсы телләрендәге кульязмалар бар. Әлеге коллекция – совет чорында формалаштырылган, бик сирәк очрый торган ислам китаплары җыелмасы.

Үз өендә тупланган әлеге китапханәне бик тәфсилләп өйрәнү, шулай ук археографик экспедицияләргә чыгу, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Казан дәүләт университеты китапханәләрендә эзләнүләре нәтиҗәсендә татарларның Урал-Идел буе ислам әдәбияты картотекасын төзү галимә тарафыннан дистәләрчә еллар буе дәвам иттерелә.

Әлеге мәгълүматлар Ә. Бостанов тарафыннан әзерләнеп, китапка кереш рәвешендә тәкъдим ителгән шактый күләмле мәкаләдә урын ала. Анда автор Максудовларның нәсел тарихын, Зәйнәп ханымның катлаулы биографиясен, Иж-Бубый мәдрәсәсендә һәм Урта Азия (Төркестан) университетында белем алу тарихы вакыйгаларын яза һәм совет чорында ислам китап культурасын бөртекләп өйрәнүче һәм искиткеч зур коллекцияне саклаучы галимәнең формалашу феноменына анализ ясый һәм бәя бирә.

«Максудова архивын һәм китапханәсен өйрәнү шуны күрсәтә: без монда әлеге фондны тәртипкә китергән, югары белем алган хатын-кызның Россиядәге ислам мәдәниятенә карашлары белән эш итәбез. Мөселман халкының үткәнен ул үзенең гаиләсе язмышы һәм бай гаилә китапханәсе аша бәяли. Максудова үзен әлеге, үз күз алдында юкка чыгып баручы мәдәни дөньяның бер өлеше итеп сизә», – дип яза китап авторы кереш мәкаләсендә. – «Китаплардагы шәхси язмалар һәм комментарийлар Максудованың кул астында булган күпсанлы чыганаклар корпусы белән мөнәсәбәтен чагылдыра. … Шул рәвешле, совет чоры академик белеме Максудовада ислам кулъязма китабы традициясен «эчтән» белүе белән гармонияле рәвештә үрелеп бара».

Әлфрид Бостанов тарафыннан Максудова китапханәсендәге гарәп имлясында язылган кулъязмаларның җентекле тасвирламасы тәкъдим ителгән. Биредә әлеге китапханә фондында сакланган 378 хезмәт турында тулы мәгълүмат алырга мөмкин.

Китапны төзүче тарафыннан искәртелгәнчә, сакланып калган көнчыгыш кулъязмалары һәм басма китаплары – ислам китап культурасын аңлау юнәлешендә кыйммәтле чыганак. Әлеге хезмәт – совет чорында Татарстанда таралышта булган борынгы китапларны туплауга аерым шәхес керткән өлешнең ачык үрнәге. Ислам китапларының сирәк коллекцияләренең берсе булган Зәйнәп Максудова китапханәсе – иясе вафат булганнан соң дәүләт архивларына тапшырылган бик сирәк очрый торган кыйммәтле байлык. Туплаган китаплар төрле фән өлкәсенә (тарих, агиография, поэзия) караган җирле яки Урта Азия якларыннан килгән кыйммәтле, кайбер очракта уникаль хезмәтләр, халкыбызның рухи мирасының бер өлешен тәшкил итә. Шуның белән бергә әлеге коллекция – Идел буе мөселман галимнәренең шәхси китапханәләре нинди булуы турында да беркадәр күзаллау тудырырга ярдәм итә торган чыганак та. Әлеге китапханә белән танышу нигезендә бүгенге көн укучысы 1917 елгы инкыйлабка кадәр формалашкан һәм, соңрак, өлешчә Максудова кулына килеп кергән аерым шәхси коллекцияләр турында да фикер йөртә ала. Коллекциядә Зәйнәп ханымның XVIII–XIX гасырларда Вятка губернасы мәдрәсәләрендә укыган һәм мөгаллимлек иткән әтисе Габделҗәмил һәм бабасы Максудның күпсанлы кулъязма-автографлары да сакланган. Аерым китаплардагы мөһерләрдән чыгып, әлеге чыганакларның хәтта Риза Фәхретдин, Рәмзи һәм Ш. Мәрҗани био-библиографик сүзлекләрендә дә исемнәре телгә алынмаган галимнәрнең китапханәләреннән алынганлыгы турында фикер йөртеп була. З. Максудова китапханәсендә совет чорында репрессияләнгән имамнарның автографлары да сакланган булуы әлеге кулъязмаларның кыйммәтен тагын да арттыра. Мисалга, Мир Сәйиид Шәрифнең мантыйк буенча китабы элегрәк нәкышбәндия тарикате шәехе, 1930 елда атып үтерелгән Әхмәд-Сафа бине Фәтхулла (Бикколый. – *Ф.С.*) әз-Задури (Задур авылыннан) китапханәсендә сакланган була һ.б.

Олы фәнни хезмәтне тәфсилләп өйрәнгәндә, бәлки, аерым җитешсезлекләргә дә тап булырга мөмкин. Тәкъдим ителгән хезмәтләрнең әлеге олы китапханәнең бөтен чыганакларын да иңләп бетермәгән булу ихтималы да бар. Китапның баш бите (тышлыгы), аңлатма язуы, иллюстрацияләр һәм кереш сүзнең рус телендә язылып, төп мәгълүматларның исә татарча, фарсыча, гарәпчә тәкъдим ителгән булуы кайбер укучыларда сораулар тудырырга мөмкин. Эчтәлек тә, материалларның нинди телдә бирелгән булуыннан чыгып, русча, өлешчә татарча тәкъдим ителгән. Ләкин китапның кыйммәте – аның асыл нәтиҗәсендә: китап Зәйнәп Максудова шәхсиятен, дөньяга, китап мәдәниятенә карашын аңларга ярдәм итәчәгенә шигем юк.

Әлеге хезмәт халкыбызның гыйльми, поэтик мирасының безнең буын яшәгән XXI йөзъеллык башына кадәр дә актив фәнни өйрәне-

лешкә кертелмәгән уникаль чыганакларның булуын, әлеге юнәлештә эзләнүләрне дәвам иттерергә кирәклеген дә искәртә.

Татар фәненә борынгы бәһаләп бетермәслек бай чыганакларны өйрәнә алырлык гыйлемле, Аурупа белеме алган, берничә телне, шул исәптән татар телен, ана телен дә камил белгән яшь белгеч килүе соклану хисе тудыра. Әлеге уникаль фондны барлап өйрәнүче һәм киң катлам укучыга тәкъдим итүче галим – Әлфрид әфәндегә яңадан-яңа фәнни табышлар телибез.

***Сәйфуллина Флера Сәгыйть кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең*
*татар әдәбияты кафедрасы мөдире*

# Р.Р. СОЛТАНОВАНЫҢ «ТАТАР ТЕАТРЫ СЦЕНОГРАФИЯСЕ: ТӨП ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ ЗАКОНЧАЛЫКЛАРЫ (XX – XXI ГАСЫР БАШЫ)» МОНОГРАФИЯСЕ ТУРЫНДА

*Султанова Р.Р.* Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI вв.). – Казань: ИД «Казанская недвижимость», 2019. – 592 с., 816 ил.

Театр рәссамы, сценограф – бүгенге көндә теар өлкәсендә бик әһәмиятле һөнәр иясе. Ул режиссер белән бергә, драматургия әсәренә нигезләнеп, спектакльнең пространство-вакыт төшенчәләрен үзенчә интерпретацияли.

Әлеге сәнгатьнең тамашага корылуы аркасында, сценограф һәрвакыт залның сулышын, тамашачыларның реакциясен тоемлый. Ул һәрвакыт сәнгать агымнарыннан гына түгел, иҗтимагый проблемалардан да, дәүләтнең, ниһаять, шәһәр хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге сәясәтеннән дә хәбәрдар.

Куелышның уңышлы булу-булмавы турында сценографның карашы еш кына профессиональ тәнкыйтьче фикеренә караганда төгәлрәк.

Күптән түгел генә әйләнешкә кергән сәнгать терминологиясе (сценография) – бүгенге көндә театр сәнгате өлкәсендәге сизелерлек үзгәрешләрнең дәлиле.

Рауза Солтанова, беренчеләрдән булып, үзенең хезмәтендә татар театры сценографиясе үсешен буеннан буена – XX гасыр башыннан алып бүгенге көнгә кадәр тикшерә. Бу – сәнгать белеме өчен аеруча актуаль тема, өстәвенә, бу темага моңа кадәр хезмәтләр дә язылмаган иде, ә Татарстанның театр тормышы үзенең төрлелеге һәм бай булуы белән аерылып тора. Татар халкының мәдәни традицияләре бик ерак гасырларга барып тоташа, ә Казан Идел буеның мәдәни үзәге булып кала бирә. Автор Казанда гына түгел, Татарстанның башка шәһәрләрендә дә үз театрлары, үз тамашачылары булган театрлар барлыкка килүне ассызыклый.

Монография зур документаль һәм сәнгати кыйммәткә ия кушымтаны да үз эченә ала.

Китапның структурасы мантыйкка корылуы, уйлап эшләнгәнлеге һәм үзенчәлекле булуы белән игътибарга лаек. Р.Р. Солтанова үзенең тикшеренүендә чорларга бүленешне нигезләгәндә – мәдәни-тарихи, театр рәссамнары әсәрләрен анализлаганда сәнгати якын килә. Теоретик яктан авторның сәнгатьтә гәүдәләнгән милли дөньяны аңлау семантикасы турындагы фикерләре бик тә әһәмиятле.

Тикшеренү материалларын җыю һәм атрибуцияләү буенча Р.Р. Солтанованың күп көч куеп, тырышып эшләвен билгеләп үтәсе килә. Дәүләт һәм шәхси архив материаллары, газета-журналлардагы публикацияләр, театр әһелләре белән әңгәмәләрнең язмалары тикшеренүче өчен төп чыганаклар булып хезмәт иткән. Сценографияне

өйрәнгәндә, ул театр костюмнарын эзләп табу, ә еш кына коткару вазифасын да үз өстенә ала. Ул матурлыгы һәм шрифт графикасының оригинальлеге белән аерылып торган уникаль театр афишаларын җыйды һәм системалаштырды. Шулай итеп, театр рәссамнары эшчәнлегенең мәгънәсен, театр тормышы атмосферасын тулаем тәшенүдә, татар халкы мәдәниятендә театрның нинди мөһим урын тотуын аңлауда Р.Р. Солтанова тарафыннан кулланылган комплекслы анализ гаять зур әһәмияткә ия. Беренче көннәреннән үк татар театрының чын халык театры булуы мәгълүм. Аның барлыкка килү шартлары хезмәттә бик җанлы итеп торгызылган.

Беренче күчмә «Сәйяр» театр труппасының (1906–1912) заллары һәрвакыт халык белән шыгрым тулы була, ул гына да түгел, кирәкле реквизит һәм костюмнарны артистларга еш кына нәкъ менә тамашачылар китереп бирә торган була. Театрның демократик рухлылыгы тамашачы белән диалогка корылган бәйләнеш тудырды. Һәм ул татар театрының үзенчәлекле сыйфатына әверелде. Аның башында атаклы мәгърифәтче язучы Г. Камал тора.

Бу чордагы спектакльләрнең театр декорациясе чишелеше стилен автор этнографизм сыйфатларына ия көнкүреш натурализмы дип характерлый. Автор билгеләп үткәнчә, мондый театрда актерлар уенына өстенлек бирелә. Стационар шартларда эшләгән театрга, Г. Камалның чакыруы буенча, нәкъ менә рәссам С. Яхшыбаев килү белән «интерьер» театрының статиклыгына чик куела. Билгеле бер күренеш буласы урын декорацияләр ярдәмендә торгызыла, рәссам тарафыннан өстәмә рәвештә кертелгән төс һәм махсус утлар эмоциональлекне арттыра. Сәнгати бизәлеш чараларының киңәюен автор билгеле бер дәрәҗәдә рус театрының йогынтысы белән бәйли.

Р.Р. Солтанованың революциядән соңгы унбиш елны үз эченә алган вакыт аралыгын аерым бүлек итеп чыгаруы да үзен аклый. Бу елларда Казан – иң зур иҗади эксперимент, күргәзмә-музей эшчәнлеге, бөтен Россия күләмендә сәнгати белем бирү үзәге. Әле күптән түгел генә Казан Сул фронты (ЛЕФ) һәм аның татар секциясе СУЛФ иҗади мирасының әһәмияте турындагы бәхәсләр көн үзәгендә иде. Тикшерелә торган чорның театр декорациясе сәнгатендә, Р.Р. Солтанова күрсәтүенчә, ул еллардагы барлык сәнгати юнәлешләр гәүдәләнеш тапкан. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, автор XX гасырның башыннан азагына кадәр «сул» рәссамнарның казанышларына ихтыяҗның ни дәрәҗәдә зур булуын эзлекле рәвештә исбат итә. Шунысы әһәмиятле: Р.Р. Солтанова «Җайдак» («Всадник») графиклар коллективы, АРХУМАС һәм Хәзерге заман театрының конструктив-эксперименталь остаханәсе (КЭМСТ) арасында күчемле бәйләнешне күзәтә. Бу театрдагы спектакльләрнең сәхнә бизәлешендә агитация-масса сәнгате формалары конструктивистик төс алган. Сәхнә пространствосы да төрле дәрәҗәдәге мәйданчыкларга әверелергә мөмкин иде, актерларның костюмнары һәм пластикасы кискен график формалар алган булган. Рус театрындагы В. Маяковскийның

«Мистерия-буфф»ы КЭМСТ постановкасының уңышлы мисалы була. Шагыйрьнең иҗаты Сул фронт вәкилләренең күбесен рухландыра. Автор КЭМСТның кайбер спектакльләрен фәнни әйләнешкә кертә һәм аларның сценография үзенчәлекләрен тикшерә. Рәссам К. Чеботарев һәм яшь режиссер Р. Ишморатовның хезмәттәшлеге уңышлы нәтиҗәләргә китерүен күрсәтә.

Театр-декорация сәнгатенә өлкән буын рәссамы П.П. Беньков (1872–1949) үзеннән зур өлеш кертә. Ул татар театрының беренче профессиональ рәссамы була. Аның иҗатында, автор фикеренчә, МХАТ традицияләре татар сәхнәсендә милли төсмер алды. Бу бигрәк тә милли драматургия постановкаларында тулысынча чагыла: Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә» (1921) романтик трагедиясе, М. Зәетовның «Иске Казан диварлары артында» (1927) һәм Ф. Бурнашның «Адашкан кыз» (1927), «Хөсәен Мирза» (1927) әсәрләре.

Татар сәнгате классигы Б. Урманче (1897–1990) да 1920 еллар сәхнә бизәлешенә үз өлешен кертте. 1930–1950 елларда сәнгатьнең төп критерие – партиялелек, аның социалистик эчтәлекле булу заманы – татар театры өчен иң четерекле чор. Милли форма ул вакытта икенче дәрәҗәдәге бер нәрсә буларак кабул ителә. Шуны да онытмыйк, культура революциясенең төп бурычларыннан берсе дини карашлар һәм традицияләр белән көрәшү булды – ислам булсынмы ул, христианлыкмы яки мәҗүсилекме. Гасырлар дәвамында барлыкка килгән көндәлек һәм бәйрәм тормышының нигезен тәшкил иткән халык традицияләре һәм йолаларының тамырын корыту бурычы куелды. Шулай итеп, фольклор һәм әдәби әсәрләрнең эчтәлеге рәхимсез редукциягә дучар була. Әлеге вазгыятьтә тормышны революцион үзгәртеп коруларга багышланган әсәрләр төп урынны били.

Р.Р. Солтанова Татар академия театры рәссамы М. Абдуллин мисалында әсәрләрнең һәм аларның авторларының язмышы еш кына түрәләр, администрация һәм партия җитәкчелеге кулында булуын күрсәтә. Иң авыр чор 1936–1945 еллар булуы билгеле: милли мәдәниятнең күренекле эшлеклеләре репрессияләргә дучар ителде, көчле цензура кертелде. Татар театрына нигез салучыларның берсе – К. Тинчурин репрессияләнде һәм атып үтерелде, Б. Урманче дистәләрчә елларга сөргенгә җибәрелде. 1958 елда Казанга кайткач та, хакимият аның театрдагы эшенә шикләнеп каравын дәвам итте, һәм нәтиҗәдә аңа бөтен көчен биреп эшләргә мөмкинлек булмады. П. Беньков Казаннан Үзбәкстанга китәргә, Б. Урманче 1941–1958 елларда Урта Азиядә яшәргә мәҗбүр булдылар.

Бу елларда П.Т. Сперанский (1891–1969) зур иҗади казанышларга ирешә. 1924–1969 елларда ул Казан зур драма театрының, соңыннан Татар академия театрының баш рәссамы була, чирек гасырга якын М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының баш рәссамы булып эшли. Автор аның, фантазиягә гаять бай булуы һәм спектакль-тамаша тудырырга омтылуы белән беррәттән, экспедицияләр вакытында һәм музей тупламаларында татар халык сәнгатен

җентекләп өйрәнүен ассызыклый. Шуңа күрә милли классикага караган әсәрләрнең куелышларында (Г. Камал, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт) персонажларның костюмнарын иҗат иткәндә, татар йорты үзенчәлекләрен нечкә тоеп, ул документаль яктан гаҗәеп төгәл эшли. Р.Р. Солтанова язганча, гомумтөрки «Идегәй» дастаны һәм «Хуҗа Насретдин» пьесасы буенча куелган спектакльләрдә аның сценографиясе әдәби мирасны индивидуаль кабул итүе белән аерылып тора. П. Сперанский барлыгы 63 спектакльнең сценографиясен эшли. Ул – зәвыклы стилист, төрле дәверләр һәм халыклар мәдәниятен һәм сәнгатен яхшы белеп иҗат итә. Әйтергә кирәк, ул иҗаты өчен төрле чыганаклардан күп нәрсә ала. Аның пейзаж сурәтләнгән арткы пәрдәләренең колориты мирискусниклар нәкышен, Головин һәм Бенуа әсәрләрен хәтерләтә. Революцион тематикадагы спектакльләр КЭМСТ тәҗрибәсен исәпкә алып куела.

П. Сперанский үзен күренекле театр эшлеклесе итеп тә күрсәтә. 1952 елда ул ТАССРның театр рәссамнары конференциясендә республикадагы театр сәнгате кризисының сәбәпләрен атый. Рәссам билгеләп үткәнчә, бу – планлы-хуҗалык характерындагы проблемалар һәм тәнкыйтьнең торышы. Алар спектакльләрнең идея-сәнгати сыйфаты түбәнәюгә китерә. Спектакльләрнең сыйфатын читтән чакырылган режиссерлар ярдәмендә күтәрергә карар кылына. Китап авторы режиссер В. Бебутов һәм П. Сперанскийның рус һәм Европа классикасын кую өлкәсендәге хезмәттәшлеге нәтиҗәләренә югары бәя бирә. Мәскәүдә «Король Лир» күрсәтелә, ул реалистик әсәр итеп кенә түгел, ә модерн һәм Урта гасырлар эстетикасы сыйфатларын берләштергән җәүһәр буларак интерпретацияләнә. Атаклы трагедиянең яңача куелышы матбугатта шау-шулы бәхәс тудыра.

Новаторлык алымнары татар театрына тиз генә үтеп керә алмый. Яман аты чыккан социаль заказ дистәләрчә елларга иҗади эзләнүләрне тоткарлый. Шуңа күрә Р.Р. Солтанова сценографиянең барлыкка килүен режиссер белән рәссамның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәсе буларак күрсәтергә омтыла. 1960–1970 елларда рәссамнар спектакльнең автордашы буларак үзләрен күрсәтә башлый. Һәм, бәян итү мантыйгыннан күренгәнчә, бу юнәлештә П. Сперанский эзлекле рәвештә эшләгән. Г. Камал исемендәге ТДАТның баш режиссеры М. Сәлимҗанов (1936–2002), шартлы-метафорик, уенга корылган театр төзеп, татар театрын яңартучы буларак күрсәтелә. Предметпространство мохите режиссерның куелышларында символик мәгънә ала. М. Сәлимҗановның эзләнүләре Мәскәү, Ленинград/Петербургта Россия театрын яңарту юнәлешендә бара. Сүз – Д. Боровский һәм Э. Кочергинның иҗади эзләнүләре турында. Ул вакытта ТДАТдагы актерларның күпчелеген башкала вузларын тәмамлаучылар тәшкил итә. М. Сәлимҗановка драматургия материалына үз карашын театр администрациясе һәм тәнкыйтьчеләр алдында күп тапкырлар якларга туры килә. Режиссер кискен социаль мәсьәләләргә мөрәҗәгать итүдән курыкмый.

Китапта А. Гыйләҗев повесте буенча куелган «Өч аршын җир» спектаклен әзерләү белән бәйле эпизод аеруча киңәйтеп бирелгән. 1974 елда әзер спектакльне тамашачыга күрсәтү тыела – театр өчен авыр сынау була бу. Әмма 1987 елда спектакль барыбер сәхнәдә куела. Автор билгеләп үткәнчә, бу пьеса 1989 елда Ленинградтагы гастрольләрдә театрның визит карточкасына әверелә. Бу вакытта театр репертуарында, язучылар һәм рәссамнар иҗатындагы кебек үк, хәзерге заман турындагы әсәрләр өстенлек итә башлый, революция темасы урынына тарихи әсәрләр килә. Халыкның милли аңында тирән үзгәрешләр күзәтелә. Алар аның этномәдәни бердәйлеккә омтылышы, үз тамырларын булдыру теләге турында сөйли. Фольклорның героик-эпик жанрларына тартылу бик ачык күренә. Белгечләр татар сәнгатенең 20 нче еллардагы казанышларына ешрак мөрәҗәгать итәләр, 20 нче һәм 70 нче еллар дәверләре арасында бәйләнеш булдыру омтылышы сизелә. 70 нче еллар азагында, Россия халыкларының үзаңында барган этномәдәни процессларны өйрәнеп, илебезнең танылган этнографы К. Чистов: «этник компонентның матди культура, йолалар һәм күпмедер дәрәҗәдә хәтта тел өлкәсеннән милли профессиональ мәдәният, этнопсихология һәм билгеле бер дәрәҗәдә фольклор даирәсенә күченүе» турында нәтиҗә ясый[1]. Аңның аксиологик аспектларын реконструкцияләү иҗатның төрле өлкәләрендә төрле дәрәҗәдәге интенсивлык белән барган. Актив позицияле һәм тамашачы белән турыдан-туры элемтәдә торган театр шушы үзгәрешләрне ачык чагылдыручылардан була.

Автор әлеге проблема буенча зур тарихи-мәдәни катламга мөрәҗәгать итми. Милли театрның сценографиясен тикшерүче өчен 1980 елларда ТАССРда мәдәният өлкәсендәге сәясәт нәтиҗәсендә татар телендәге басмаларның эзәрлекләнүе, аларның һәм татар мәктәпләренең саны кимү мөһимрәк. Нәтиҗәдә театр тамашачысын югалту проблемасы килеп туарга мөмкин иде. Автор турыдан-туры Г. Камал исем. ТДАТ репертуарына мөрәҗәгать итә һәм, әлеге материалны анализлап, 1960–1990 елларда этномәдәни бердәйлекне саклау турында яза. Әгәр К. Тинчуринның тамашачы яратып өлгергән «Зәңгәр шәл» музыкаль мелодрамасы яңартылган репертуарга үзенең күркәм холыклы хатын-кызлары һәм милли көнкүрешнең кабатланмас күренешләре белән татар театры классикасы буларак керсә, «Идегәй» спектаклендә режиссер М. Сәлимҗанов (сценограф Т. Еникеев) каһарманлык дастанын яңача аңлата. Аның вакыйгалары ниндидер катаклизм буларак уйланылган, мәгънәсе феодаль ызгыш-талаш кысаларыннан читкә чыга. Декорацияләр нәкъ менә шундый кайчандыр башланган фаҗига киңлеген торгыза. Бу спектакль татар мәдәни байлыгының Евразия мәдәниятенең бер өлеше буларак әһәмиятен аңларга ярдәм итте.

[1] *Чистов К.В.* Традиционные и вторичные формы культуры // Расы и народы: Современные этнические и расовые проблемы / АН СССР. Ин-т этнографии им. Н.Н. Миклухо-Маклая. М., 1975. Вып. 5. С. 32–41.

Милли театрда эшләгән татар милләтеннән булмаган һәм Казан традициясе белән бәйләнмәгән сценограф иҗатының үзенчәлекле үрнәге – ул С. Скоморохов эшчәнлеге. Бу сценограф, режиссер, сценограф һәм актерлар арасындагы элемтә ныклырак булсын өчен, Идел буе шәһәрләренең башка театрларында тупланган тәҗрибәне дә кулланды. Автор билгеләп үткәнчә, С. Скоморохов Европа авторларының пьесалары сценографы буларак та, татар театр классикасы өстендә эшләгәндә дә үзен иркен хис итә. Татар театрының үзенчәлекләрен тирәнтен аңлау С. Скомороховка, тикшеренүче фикеренчә, стиль ягыннан бербөтен спектакльләр иҗат итәргә булышкан.

Режиссер белән бергә сценограф милли классикага мөнәсәбәттә дә иң кыю тәҗрибәгә барырга әзер тора. Шул рәвешле Г. Тукайның атаклы «Шүрәле»сендә мәгънәви акцентлар үзгәртелә (сүз Т. Миңнуллин пьесасы буенча куелган «Җанкисәккәем» спектакле турында). Урман пәрие революциягә кадәрге чорның, затлы ак костюмнар киеп, куе урманда йөрүче зыялы затларына әверелә.

Татар театрының постмодернистик эзләнүләр юнәлешендә зур уңышларга ирешүе ачык күренә. Монографиянең соңгы бүлеге «Сәнгати телнең күптөрлелеге – 1990–2010 еллар сценографиясе» дип атала. Автор сүзләре белән әйткәндә, бу чорда яңа төр сценография (действенная») барлыкка килә: «... пространство-мохит спектакльнең барлык компонентлары арасындагы үзара бәйләнешне билгели». Бу хәзерге заман чынбарлыгына постмодернистик соц-арт күзлегеннән карауда да чагыла (мәсәлән, Т. Миңнуллинның «Дивана» спектакле шундыйлардан; режиссеры Ф. Бикчәнтәев, сценографы Т. Еникеев). Пьесаның баш персонажы Вилнең үз-үзен тотышы акылга сыймый, ул бөтен нәрсәдә дөнья революциясенең юлбашчысына охшарга тырыша, һәм бу – хәзерге чынбарлыкта. Сценограф аның – төп геройның адекват булмаган халәтенә пародия ясый: ул Ленин кебек шалашта яши, кумиры кебек киенгән. Шулай итеп, бөек юлбашчы турындагы совет мифы, ә аның артыннан ук «Баскетболист» (2001) спектаклендәге якты киләчәк турындагы миф та деконструкциягә дучар ителә. Сценограф спорт мәйданчыгы киңлеген дә, спортта моңарчы күрелмәгән уңышларга ирешеп, әйләнә-тирәдәге тормышны да тулаем үзгәртәчәкләренә ышанган персонажларны да, аларның костюмнары һәм пластикасын да гротеск стилендә хәл итә.

Жанрларны бутап бетерү һәм спектакльләрнең якты тамашага һәм күңел ачуга корылуы театрның массачыл мәдәният чараларын үзләштерүендә чагыла. Хәзерге шартларда, автор фикеренчә, бу котылгысыз күренеш. Шунысын да әйтик, монда театрның яшьләр аудиториясе белән кызыксынуы сизелә. Бу җәһәттән Р.Р. Солтанованың хәзерге татар театрында ориентализм традицияләрен саклау һәм үзгәртеп кору турындагы нәтиҗәләре бик мөһим. Татар театры башлангыч чорда ук ук ул персонажларның костюмнарында, кирәк-яракларның үзенчәлекләрендә ачык төсләргә һәм декоративлыкка тартыла, сәхнәнең пространство зоналарын хәл итүдә декоратив драпировка-

лар куллануга өстенлек бирә. Татар театрына нигез салучыларның берсе булган Г. Камал драматургиясенә хас карнаваллаштыру, персонажларны икенче төскә кертү, (икенче) кием кидерү тенденциясе аеруча актуальләшә. Р.Р. Солтанова татар театры үсешенең төрле чорларында сценографиянең я «интерьер», я «карнавал-уен» тибы өстенлек алуы турында нәтиҗә ясый. Сценографиянең һәрберсендә дөньяны күзаллауда милли пластик үзенчәлек чагылыш таба: бармаклар бер учка тупланган кебек, театр да тормышны тулаем колачларга омтыла. Тик пространство бераз башкачарак үзәкләшә. «Интерьер» тибында ул предметлар белән уратып алынган, «карнавал-уен» тибында үзгәрүчән (386 б.). Биредә автор фәлсәфәче Е.В. Синцовның ислам сәнгатенең тасвирлап булмый торган үзенчәлеге турындагы фикерләрен дәвам итә. Ислам сәнгатенең образлы-мәгънәви традициясе ТДАТ сценографиясендә дә чагыла һәм кульминацион күренешләрдә зәңгәр, яшел, ак төсләр символикасына өстенлек бирүдә гәүдәләнә. Бу төсләр актерларның киемендә, драпировкаларда һәм кулисаны бизәүдә очрый. Ритуаль гамәлләрне үз эченә алган күренешләрдә ак төс өстенлек итә. Милли классикага караган спектакльләр сценографиясендә фарсы миниатюраларының йогынтысын күзәтергә була: бәйрәм рухы һәм төсләрнең купшылыгы, җәннәт бакчасы мотивы, кием-салымның төсләргә байлыгы һәм пространствоның ике үлчәмлелеге. Бу нисбәттән авторның Назыйм Хикмәтнең «Мәхәббәт турында легенда» пьесасы буенча куелган спектакльнең татар һәм рус театрларында куелышын чагыштыруы бик әһәмиятле. Һичшиксез, безнең көннәрдә дә исламның дин, чынбарлыкны тою буларак йогынтысы Татарстан сәнгате өчен әһәмиятен югалтмый һәм үзенең һәрьяклап эшләнүен көтә.

Татар театрында чит ил драматургиясе темасына мөрәҗәгать итеп, Р.Р. Солтанова Б. Брехт пьесаларын кабул итү үзенчәлеген җентекләп характерлый. Рус һәм татар театрларында куелган спектакльләрне чагыштырып, ул бик тә әһәмиятле нәтиҗәгә килә: «освоение брехтовского наследия русскими и татарскими театрами происходило по-разному: в постановках русского театра театральная эстетика немецкого драматурга ассоциируется с системным обновлением принципов театрального искусства. Это прорыв в будущее, отказ от ставших привычными традиций психологического театра. В этом плане путь русского театра совпадает с общемировой тенденцией. А в татарском театре Брехт воспринимается как часть культурного пространства, элементы которого могут быть введены в спектакль, в целом ориентированный на уже существующую традицию. Эти новые элементы брехтовской системы призваны лишь дополнить, обогатить, несколько видоизменить то, что уже накоплено и закреплено в театральном сознании. В этом случае новации Брехта атрибутируются через хорошо узнаваемое – через эпический дух, который всегда был присущ татарской культуре, татарскому словесному творчеству, особенно в его древних формах (сказаниях, легендах, баитах и др.). Эпос

всегда был частью театральной культуры татар, поэтому брехтовское наследие в этом контексте предстает не как «чужое» и радикально новое. Оно согласуется с древней традицией, выглядит как ее продолжение…, поэтому постановки брехтовских пьес на татарской сцене не предполагают отказа от традиций психологической драматургии, рождая очень любопытный и не предполагаемый самим Брехтом сплав двух противоположных линий мировой драматургии» (с. 514).

XX–XXI гасыр чигендә ТДАТ репертуарында Кальдерон, Мольер, Шекспир пьесалары була. Бу спектакльләрнең уңышы – күп яктан режиссер, актерлар һәм сценографның яңа сыйфатта бергәләп эшләү, тамашачыларның кабул итү дәрәҗәсе үсү нәтиҗәсе.

Монографиянең йомгак өлешендә тикшеренүнең кыскача нәтиҗәләре китерелә. Библиография өйрәнелгән проблематиканың тарихы һәм теоретик аспектлары буенча үтә нык тулы булуы белән аерылып тора. Тикшеренү нәтиҗәләрен һәм кушымталардагы материалларны төрле максатта – сәнгать тарихын өйрәнгәндә дә, театр белеме теориясе һәм практикасында һәм музей эшендә дә, Татарстан Республикасында театр музеен төзү өчен дә гамәли кулланырга мөмкин. Мондый музейның экспозицияләре төрле катлам тамашачыларда җитди кызыксыну уятыр иде.

***Розенберг Наталья Абрамовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, культурология докторы, профессор (С.-Петербург)*

УДК 636

***Р.Ә. Хәертдинов,***
***Р.Х. Равилов,***
***Т.М. Әхмәтов,***
***И.Н. Камалдинов***

# ТАТАРСТАН ТЕРЛЕКЧЕЛЕГЕНДӘ СЕЛЕКЦИОН КАЗАНЫШЛАР

В статьи описаны селекционные достижения в животноводстве Республики Татарстан, созданные за последние 20 лет с участием ученых кафедры биологии, генетики и разведения животных Казанской государственной академии ветеринарной медицины им. Н.Э. Баумана. Они следующие: аутосексный яичный кросс БТ-125 (Бугульма татарская) с сцепленным с полом признакам медленной оперяемости и яйценоскостью 306 шт за год, массой яйца 60 – 62 г; татарский тип медоносной пчелы со медосбором 40 – 60 кг, исключительной зимостойкостью и устойчивостью к болезням; татарстанский тип молочного скота с генотипом 1/8 холмогорская +1/16 черно-пестрая + 13/16 голштинская пород, продуктивностью 6435 кг молока, а рекордной – 9091 кг по стаду; татарская порода лошадей, знаменитая, хорошо известная в истории более тысяча лет, выносливая, неприходливая, универсального направления использования, устойчивая к болезням и кровососущим насекомым.

**Ключевые слова:** селекция, достижение, порода, тип, куры, кросс, скот, лошадь, пчела.

The article describes the breeding achievements in the livestock industry of the Republic of Tatarstan, created over the past 20 years with the participation of scientists of the Department of Biology, Genetics and Animal Breeding of the Kazan State Academy of Veterinary Medicine named after N.E. Bauman. They are as follows: the autosex egg cross BT-125 (Bugulma Tatar) with a snagled with the floor signs of slow plumage and egg-likeness of 306 pieces per year, the weight of an egg 60 – 62 g; Tatar type of honey bee with honey harvest 40 – 60 kg, exceptional winter resistance and resistance to disease; Tatarstan type of dairy cattle with genotype 1/8 Holmogorsky 1/16 black-variety breeds, productivity of 6,435 kg of milk, and record – 9091 kg per herd; Tatar breed of horses, famous, well known in history for more than a thousand years, hardy, non-incoming, universal direction of use, resistant to disease and blood-sucking insects.

**Keywords:** selection, achievement, breed, type, hens, cross, cattle, horse, bee.

Казан губернасы XX гасыр башында Россиянең икътисади яктан артта калган губерналарының берсе була. Халык күбесенчә (90%) авылда яши, җир эшкәртеп, мал асрап көн күрә, ләкин хуҗалык бик примитив рәвештә алып барыла. Авылларда терлек саны чагыштырмача күп булса да, мәсәлән, 1913 елгы мал санын исәпләү буенча губернада барлыгы 448,2 мең ат, 511,2 мең мөгезле эре терлек, 182,3 мең дуңгыз, 1291,9 мең сарык белән кәҗә була, алар,

ашату һәм карау начар булу сәбәпле, үсешләре – вак, ә продуктлылык бик түбән була [Григорьев]. Мәсәлән, ул вакытта сыерларның авырлыгы бары тик 256–320 кг, ә җилкәдәге биеклеге 110–117 см була һәм алардан 720–1440 л сөт савыла [Палкин һ.б.]. Моның төп сәбәбе – терлеккә азык җитмәүдә, чөнки аларның азыгын бары тик табигый болын печәне белән башак (көрпә сибелгән туралган салам) тәшкил итә, алар да әле җитәрлек дәрәҗәдә булмый, тәэмин ителеш 50% тан артмый. Билгеле, бу шартларда терлекләрнең продуктлыгын арттыру буенча селекция эше нәтиҗә бирми, терлектә табигый шартларга яраклашу сыйфатлары өстенлек ала. Шулай да ул чорда терлекләрнең нәселлек сыйфатларын яхшырту буенча берникадәр эш алып барыла башлый. Беренче чиратта алпавыт хуҗалыкларына Россиянең бүтән өязләреннән һәм өлешчә Европа илләреннән нәселле терлекләр кайтарыла. Мәсәлән, 1908–1916 еллар эчендә андый хуҗалыкларга 172 баш нәселле үгез кайта, аларның 94 е голланд, 34 е бестуж, 5 е швиц, 24 е симментал, 5 е ярослав, 9 ы холмогор токымыннан була. Ул елларда алпавыт Г. Молостков, Н. Сазонов, Л. Лихачев, А. Ишморатов хуҗалыкларында орлов токымлы атлар асрау буенча ат заводлары булдырыла. Алар бу атларны унышлы гына үрчетеп килә. Ләкин мондый чаралар аерым крестьян хуҗалыгындагы терлекләргә әллә ни тәэсир итә алмый, чөнки культуралы токымнарны асрау яхшы ашатуны таләп итә. Шуңа күрә крестьян хуҗалыкларындагы терлекләр совет чорына кадәр токымсыз җирле терлек булып кала бирә. Аның нәселлелеген яхшырту 1930 елларда – коллективлаштыру чорында башлана. Колхозларда, совхозларда крестьян хуҗалыкларыннан җыелган токымсыз терлекләрне киң масштабта югары продуктлы, эре, культуралы токымнар белән каплата башлыйлар. Бу процесс 5 буын булганчы – 1970 елларга кадәр дәвам итә. Шулай итеп, Татарстанда Россиянең бүтән регионнарыннан һәм чит илләрдән китерелгән токымнар үрчетелә башлый, ягъни татарның үз токымнары булдырылмый. Мәсәлән, Татарстанның төньяк һәм Казан тирәсендәге районнарында – холмогор токымлы сыерлар, Кама аръягында һәм көнбатышта – бестуж, көнчыгышта – швиц үрчетелә. Атчылыкта русская, орлов юртаклары һәм авыр йөк ташу өчен русская токымы районлаштырыла.

1980 елның башында ил буенча терлекчелектә югары механикалаштырылган, автоматлаштырылган технологияләрне киң куллану аркасында, озак елларга исәпләнгән яңа токымнар һәм типлар булдыру буенча программа кабул ителде [Яковлев һ.б.]. Аның нигезендә регионнарга үз токымнарын булдыру ирке бирелде һәм аларда, шул исәптән Татарстанда да, бу юнәлештә актив эш башланды. Әлеге эш шушы язмада яктыртыла.

**Селекцион казанышлар**. Соңгы 30–40 елда, югарыда әйтелгән программаны тормышка ашыру максатыннан, Казан ветеринария медицинасы академиясенең биология, генетика һәм үрчетү кафедрасы галимнәре тарафыннан байтак кына эшләр башкарылды.

Токым булдыру – күп чыгымнар сорый һәм озак вакыт (кимендә 25–30 ел) таләп итә торган авыр эш. Шуңа карамастан кафедра портфолиосында 4 токым исәпләнә. Иң беренчесе – 2002 елда Россиянең кошчылык буенча фәнни-тикшеренү институты җитәкчелегендә һәм академия галимнәре катнашында аутосекслы йомырка салучы тавыклар кроссы булдырылды. Бу эш Бөгелмә нәселле кошчылык заводында алып барылды, шуңа күрә кросс БТ-125 (Бугульма татарская-125) исеме белән теркәлде [Авт. таныклыгы № 36957; Ситдиков и др.]. Кросс леггорн токымлы тавыклар нигезендә чыгарылды, ул 3 линиядән тора: БТ-1, БТ-2 һәм БТ-5, генетик яктан үзенчәлекле, ягъни аутосекслы, ахыргы гибридлы әтәч һәм тавык чебиләр бер берсеннән канат каурыйларының озынлыгы белән аерылып тора. Бу үзенчәлек нәселдәнлек ягыннан бик тотрыклы, чөнки аның гены җенси Х-хромосома белән бәйле, шуңа күрә бер тәүлеклек чебиләрне әтәч белән тавыкка җиңел генә аерырга мөмкинлек бирә. Ә ризык өчен йомырка җитештергәндә, әтәчләр кирәк түгел, тавыклар әтәчсез дә йомырка сала. Ахыргы гибридлы тавыкларның йомырка салу продуктлылыгы бик югары һәм ел дәверендә 306 данә тәшкил итә, ә йомырканың авырлыгы 60–62 г. Кросс Татарстанның Бөгелмә, Чистай кошчылык фабрикаларында кулланыла.

Икенче селекцион казаныш – Татарстан типлы сөтле сыер 2006 елда булдырылды [патент № 3037; Хаертдинов и др., 2006]. Ул элеккеге холмогор токымы нигезендә чыгарылды, эш 20 ел дәверендә алып барылды. Холмогор токымы тагын илдә һәм дөньяда сөтлелеге иң югары булган голштин һәм аклы-каралы ала (чёрно-пёстрая) токымнары белән кушылып яхшыртылды. Шулай итеп, өч токым генофондыннан торган яңа Татарстан типлы сыерлар булдырылды. Татарстан типлы сыерлар башка аңа охшаш токымнардан үзенең генотибы белән аерылып тора. Аның генотибы 1/8 өлеш холмогор (Х), 1/16 – ала (ЧП) һәм 13/16 – голштин (Г) токымнарыннан тора. Яңа токым бу өч токымның иң яхшы сыйфатларын берләштерә, ягъни холмогордан – безнең табигать шартларына яраклашу, чыдамлылыкны, ә аладан – хәзерге заман технологияләренә туры килү, голштиннан – югары сөт продуктлылыгын, дөрес экстерьер билгеләрен үзенә алды. Аннан соң Татарстан тибының сөт продукциясе универсаль технологик сыйфатларга ия, ягъни ул сыр ясау өчен дә, стерилизацияләнгән сөт, каймак яки бүтән төрле продукт алу өчен дә бер үк дәрәҗәдә яраклы булып тора.

Татарстан тибы республиканың төньяк һәм Казан тирәсендә урнашкан 16 районында үрчетелә. Баш саны буенча икенче урында тора һәм республикадагы барлык сыерларның 38% ын тәшкил итә, продуктлылык буенча – шулай ук икенче урында, бары тик чиста голштин токымыннан гына калыша, яңа типның уртача продуктлыгы нәселле хуҗалыкларда 6475 кг сөт тәшкил итә, ә рекордлы продуктлылык 9091 кг га җитә. Татарстан тибының нәсел базасы бай һәм ныклы. Бу токым буенча республикада 12 нәсел заводы, 34 нәсел

репродукторлары уңышлы эшләп килә [Нуртдинов һ.б.]. Татарстан тибының киләчәге зур һәм өметле.

Өченче селекцион казанышка 2010 елда ирешелде: татар типлы бал кортлары республика умартачылык идарәсе җитәкчелегендә һәм кафедра галимнәре катнашында чыгарылды [патент № 5476; Сафиуллин и др.]. Кафедра аңа кадәр күп еллар дәвамында, профессор С.В. Жданов эшләгән заманнардан ук (1935–1972 еллар), Татарстан җирлегендә үрчетелә торган бал кортларын җентекләп өйрәнде һәм алар белән селекция эшләре алып барды. Кафедрада башкарылган фәнни эшләр Татарстан умартачыларының көндәлек кулланмасына әверелде. Җирле бал кортларының әһәмиятле генофондын саклап калу өстендә фәнни эшләр башкарылды. Бу эшләр ниһаять татар типлы бал кортларын формалаштырырга мөмкинлек бирде.

Татар типлы бал кортлары җирле табигать шартларына нык яраклашкан һәм бу шартларда югары күләмдә (40–60 кг) бал җитештерергә сәләтле. Алар безнең климаттагы кышкы салкыннарга чыдам, авыруларга бирешми һәм тагын күп кенә файдалы сыйфатларга ия. Мәсәлән, татар кортлары урта урыс токымына караганда тынычрак һәм ул кадәр үк усал түгел, балны да алардан күбрәк җыя. Безнең кортларның күч аеру инстинкты 18% ка кимрәк, алар карабодай, рапс, горчица, эт какысы һ.б. үсемлекләрне югары серкәләндерергә сәләтле. Корт аналары югары үрчем һәм көчле умарта булдыра. Бу сыйфатлар татар типлы бал кортларын бүтән токымнардан өстенрәк куя һәм аларны умартачылыкта киң кулланырга мөмкинлек бирә.

Дүртенче селекцион казаныш – тарихи татар атларын яңадан тергезү булып тора [патент №10037; Хаертдинов и др. 2019]). Бу эш Министрлар кабинеты, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җитәкчелегендә Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше буенча Баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе һәм кафедра галимнәре тарафыннан башкарылды. Ул 15 ел дәвамында алып барылды. Татар атлары тарихта бик яхшы билгеле булсалар да, алар бу гасыр башына юк дәрәҗәсендә, чөнки аларны 1930 еллардагы коллективлаштыру чорында, вак токымлы крестьян атлары дип, киң масштабта эре токымнар белән каплатып, токым буларак югалу дәрәҗәсенә җиткергәннәр иде. Аннан соң аларны Бөек Ватан сугышы елларында, чыдам атлар дип, бик күпләп фронтка җибәрделәр, алар аннан, билгеле, кире кайтмады.

Татар атларын яңадан тергезү проблемасы 2005 елда Казанның 1000 еллыгы уңаеннан уздырылган чаралардан соң тарихчылар, корреспондентлар тарафыннан күтәрелде. Бу эшне башкарып чыгу өчен, Татарстан Президенты тарафыннан комиссия төзелде, шушы комиссия җитәкчелегендә практик эш башланды. Беренче чиратта, тарихи чыганакларга таянып, татар атларының стандарты, модель тибы булдырылды һәм алар нигезендә ике оригинатор хуҗалыкта (ИЭ «Нәбиуллин Ф.М.» (Лениногорск районы, Югары Каран авылы) һәм КФХ «Бакиров Ф.Р.» (Әлки районы, Татар Әхмәт авылы)) әлеге стандартка

туры килгән атлар туплана башлады. Алар Татарстанның ерак районнарыннан, Башкортстаннан, Чиләбе, Оренбург өлкәләреннән һәм Төньяк Казакъстан якларыннан җыелды. Әлеге атлар белән 10 ел буена селекция эше алып барылды һәм 3 буын алынды. Татар атларын, яңа токым буларак, Россиянең селекцион казанышлар буенча Дәүләт комиссиясе рәсми рәвештә раслады.

Татар атлары уртача гәүдәле (тере авырлыгы 460–475 кг, җилкәдәге биеклек 142–146 см, гәүдә озынлыгы 150–157 см), күбесенчә сары (75%), өлешчә сары-кола (25%) төстә. Сары төстә булганда, аларның гәүдәсе һәм аяклары – алтынсу ком, ә ял белән койрыклары аксылрак яки шул ук гәүдә төсендә. Сары-колада аз гына аерма бар, ягъни гәүдә һәм аякларның өске өлеше сарыдагы кебек ком төсендә булса да, ял белән койрык һәм аякларның аскы өлеше каралҗым була, тагын сырт буйлап каралҗым төстәге каеш үтә. Сары һәм сары-кола төсләр татар атларында борынгыдан ук сакланып килә, чөнки бу төсләр турында язмалар борынгы кытай чыганакларында теркәлеп калган. Татар атлары – борынгы күчмә халык атлары, аларның төсләре үләннәре кипкән далага тәңгәл килә һәм табигатькә яраклашуның бер күрсәткече булып тора.

Токым сынау эшләре шушы сары һәм сары-кола төстәге атларда үткәрелде, ләкин соңрак тарихи чыганаклардан татар атларында тагын башка төсләрнең дә булуы ачыкланды. Бу беренче чиратта чаптар белән коба төсләренә карый, алар – сары белән сары-колага бик якын торган төсләр. Шуңа күрә хәзерге вакытта чаптар белән коба төстәге атлар да татар токымы исәбенә кертелә. Чаптар төсендәге атларның гәүдә, аяклары җирән, ә ял белән койрык нык аксыл яки төтен төсендә. Коба атларда гәүдә, аяклар җирән яки ачык коңгырт төстә булса да, алар сары йоннар белән катнашкан, ял белән койрык шул ук төстә яки тагын да ачыграк, сырт буйлап каралҗым каеш үтә.

Татар атлары – бик чыдам атлар, алар табигать шартларына яхшы яраклашкан, ел дәверендә ачык һавада булырга сәләтле, шуңа күрә аларга җәен дә, кышын да табигый үлән белән туклану кулайрак, кышын алар андый азыкны кар астыннан тибенеп таба, ә җәен кигәвен-черкигә бирешми. Көн дәвамында 7–8 сәгать буе бертуктаусыз чабып, 100–120 чакрым юл үтәргә мөмкин.

Хәзерге вакытта татар атларының баш саны 1100 гә җитте, алар 8 хуҗалыкта үрчетелә. Атлар тормышта төрле юнәлештә кулланыла, ягъни аларны җигеп йөк ташырга да, атланып чабарга да, сөтен савып кымыз ясарга да, сугымга җибәреп ит продукциясе алырга да мөмкин. Татарның үз аты булдырылгач, элеккеге онытылып беткән ат белән үткәрелә торган милли уеннар, ярышлар, мәсәлән, ерак арага ат чабышлары, аударыш көрәше, кыз куу һ.б. кире кайтарыла башлады. Татар халкының төп бәйрәмен – Сабан туйларын үз атларыбыз катнашында үткәрү халык күңеленә аеруча хуш килә. Шуңа күрә татар атларын яңадан тергезү терлекчелектә соңгы вакытта булдырылган иң уңышлы селекцион эшләрнең берсе булып тора, чөнки татар

халкының элеккеге тарихы әлеге атлар белән тыгыз бәйләнгән булган, алар – халыкның горурлык символы һәм мактанычы.

**Әдәбият**

*Григорьев Н.В.* Животноводство Татарии: опыт, проблемы, перспективы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. 336 с.

*Нуртдинов М.Г., Хазипов Н.Н., Хаертдинов Р.А. и др.* Развитие племенного молочного скотоводства в Татарстане. Казань: Центр инновационных технологий, 2006. 132 с.

*Палкин Г.А., Герасимов И.С., Чернышев Н.Р.* Достижения науки – в практику животноводства. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 104 с.

*Сафиуллин Р.Р., Набиуллин Р.Г., Хазипов Н.Н. и др.* Патент на селекционное достижение № 5476. Пчелы медоносные Татарский. Госкомиссия РФ по испытанию и охране селекционных достижений. 2010.

*Ситдиков Д.Г., Алиев М.Ш., Ключникова В.Н. и др.* Авторское свидетельство № 36957. Куры Бугульма. Госкомиссия РФ по испытанию и охране селекционных достижений. 2002.

*Хаертдинов Р.А., Афанасьев М.П., Ахметов М.Г. и др.* Патент на селекционное достижение №3037. Крупный рогатый скот Татарстанский. Госкомиссия РФ по испытанию и охране селекционных достижений. 2006.

*Хаертдинов Р.А., Ахметов И.В., Бакиров Ф.Р. и др.* Патент на селекционное достижение №10037. Лошади Татарская. Госкомиссия РФ по испытанию и охране селекционных достижений. 2019.

*Хәертдинов Р.А., Хаҗипов Н.Н., Зарипов Р.У. и др.* Татар атлары. Казань: Идел-Пресс. 2019. 120 б.

*Яковлев Б.Я., Габитов Н.А., Хаертдинов Р.А. и др.* Перспективный план селекционно-племенной работы в молочном скотоводстве в хозяйствах Татарской АССР до 2000 года. Казань: Татар. управление статистики, 1989. 229 с.

***Хәертдинов Рамил Әнвәр улы,***
*биология фәннәре докторы, профессор, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең биология, генетика һәм терлек үрчетү кафедрасы мөдире*

***Равилов Рөстәм Хамәт улы,***
*ветеринария фәннәре докторы, профессор, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе ректоры*

***Әхмәтов Таһир Мөнәвир улы,***
*биология фәннәре докторы, профессор, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең фәнни эшләр буенча проректоры, биологик химия, физика һәм математика кафедрасы мөдире*

***Камалдинов Илнур Наил улы,***
*биология фәннәре кандидаты, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең биология, генетика һәм терлек үрчетү кафедрасы доценты*

**2019 елның декабрендә** «Казан Кремле» музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмәләр залында Татарстан Республикасының халык рәссамы, скульптор-монументалист Әхсән Фәтхетдиновның тууына 80 ел тулу уңаеннан «Рәссам Әхсән Фәтхетдинов: дустыма хатлар» дип аталган күргәзмә ачылды. Проект «Казан Кремле» дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәттәшлеге кысаларында оештырылды. Күргәзмәнең кураторы – сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова.

Күргәзмә экспозицияләрендә («Ияләр» (1989 – 1999), «Рәнҗетелгәннәр» (1989 – 1991), «Кабер ташлары» (2000 еллар), «Баганалар» (2008–2009) «Казан Кремле» дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы фондларыннан, Түбән Кама шәһәренең комплекслы музееннан, «Казан» милли мәдәният үзәгеннән, Ш. Мәрҗани исемендәге фәнни һәм мәдәни программаларга ярдәм итү һәм аларны үстерү фондыннан эшләр урын алган.

**2020 елның 15–22 гыйнварында** Казан шәһәренең Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында Нәҗип Җиһанов исемендәге V «Мирас» татар музыкасы фестивале узды. Быелгы фестиваль ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланды. Фестивальне Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры оештырды.

Фестиваль татар композиторы, татар музыка сәнгатенең танылган эшлеклесе, Татарстанда симфоник оркестр оештыру инициаторы булган Нәҗип Җиһановның туган көнендә ачылды. Фестиваль кысаларында «Туган җирем Татарстан», «Яшьлек», «Көй һәм сүз» дип аталган концертлар узды. Концертларның программасына татар академик музыкасы классиклары белән беррәттән, бүгенге көндә әйдәп баручы композиторларның әсәрләре кертелгән иде.

**2020 елның 7 февралендә** Россия Фәне көне уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов Казан Кремле территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы Археология музеена килде. Чарада Татарстан Республикасы вице-премьеры Л.Р. Фазлыева, Татарстан Республикасы мәдәният министры И.Х. Әюпова, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре катнашты.

Археология институты директоры А.Г. Ситдыйков музей буенча экскурсия уздырды, белгечләр эшчәнлегенең төп юнәлешләре белән таныштырды, алда торган бурычлар турында сөйләде.

Р.Н. Миңнеханов республикада мәдәни мирас объектларын саклап калу мәсьәләсендә зур тәҗрибә туплануын, бу юнәлештә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең өлеше гаять зур булуын аерым билгеләп үтте, киләчәктә дә әлеге өлкәдәге эшчәнлектә темпларны киметмәскә кирәклеген ассызыклады.

**2020 елның 7 февралендә** Россия Фәне көне уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә тантаналы чара узды. Анда Татарстан Республикасы

Фәннәр академиясе президиумы әгъзалары, академик институтлар, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге, шулай ук Фәннәр академиясенең фәнни-методик җитәкчелеге астында булган башка институтларның фәнни хезмәткәрләре, Казанның югары уку йортлары һәм фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Саләхов бүгенге Россия һәм дөнья фәненең үсеш тенденцияләре турында сөйләде, галимнәрне бәйрәм белән котлады һәм киләчәктә дә уңышлар, яңа казанышлар теләде. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан галимнәренең ил икътисадының барлык тармакларына керткән зур өлешен билгеләп үтте.

Галимнәрне бәйрәм белән шулай ук Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге директоры Олег Синяшин котлады.

Чыгышлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм ведомство бүләкләрен тапшыру белән чиратлашып барды. Тантаналы чара Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең исемле премияләрен тапшыру белән тәмамланды.

**2020 елның 14 февралендә** Казан шәһәре Чехов урамындагы 53 нче йортта күренекле татар язучысы Әмирхан Еники истәлегенә мемориаль такта ачылды. Тантаналы чарада Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова, әдипнең туганнары, галимнәр, мәдәният эшлекләре, иҗат интеллигенциясе, журналистлар һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Чараның ахырында Әмирхан Еникинең кызы Флера Карташова чыгыш ясады, ул үзенең әтисе иҗатына булган зур кызыксыну, хөрмәт һәм игътибар өчен тантанада катнашучыларның барысына да рәхмәт сүзләрен җиткерде.

**2020 елның 15 февралендә** патриот-шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 114 ел тулу уңаеннан шагыйрьнең Казанның 1 Май мәйданында урнашкан һәйкәленә татар җәмәгатьчелеге чәчәкләр салды. Тантанада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, галимнәр, мөгаллимнәр, студентлар, мәктәп укучылары катнашты.

Соңрак, традиция буларак, Татарстанның Милли музеенда шагыйрьнең легендар «Моабит дәфтәрләре»н тантаналы алып чыгу чарасы оештырылды. «Моабит дәфтәрләре»н тантаналы рәвештә Гомумроссия халык фронтының Татарстандагы Төбәк штабы рәистәше, «Ватан берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы советы рәисе Александр Юрьевич Коноплев алып чыкты.

Чарада «Җәлил укулары» халыкара әдәби шигырь укучылар бәйгесендә җиңүчеләр башкаруында Муса Җәлилнең шигырьләре яңгырады.

**2020 елның 18–25 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Төмән өлкәсенең Тобольск, Вагай

районнары татар авылларында комплекслы экспедиция оештырылды. Экспедиция вакытында саз татарларының теле, фольклоры, гамәли-декоратив сәнгате үрнәкләре тупланды.

**2020 елның 20 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының яңа фәнни-гамәли проектлары – башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен «Туган тел (татар теле)» укыту-методик комплекты, татар теле сүзлекләренең электрон фонды, Язма һәм музыкаль мирас үзәге сайты һәм гарәп язуындагы басма текстны кириллицага күчерү программасы – киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Чарада Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар, вакытлы матбугат басмалары вәкилләре катнашты.

**2019 елның 21 февралендә** Халыкара Туган тел көне уңаеннан Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» дип исемләнгән XI Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.

Конференциянең пленар утырышы Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан Еникинең 110 еллык юбилей елын йомгаклауга багышланды. Юбилей уңаеннан Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтының күргәзмә залында «Әмирхан Еники һәм аның дәвере» дип исемләнгән фотокүргәзмә ачылды. Биредә Әмирхан Еникинең гаилә архивыннан уникаль фоторәсемнәр тәкъдим ителде.

Конференциянең секция утырышларында төрки лингвокультурологиянең теоретик һәм практик аспектларына, хәзерге лингвокультурологиянең актуаль юнәлешләренә, мәдәниятара аралашу һәм тәрҗемә проблемаларына, сәнгать әсәрләрендә дөньяның тел картинасын чагылдыруга багышланган фәнни докладлар тыңланды.

Конференциядә чит илләрдән (Германия, Казакъстан, Төркия, Япония һ.б.) һәм Россия төбәкләреннән 200 гә якын кеше катнашты.

**2020 елның 28 февралендә** Яр Чаллы шәһәрендә Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Чаллы бүлекчәсенә 40 ел тулу уңаеннан тантаналы чара узды. Чара кысаларында Яр Чаллы мәктәпләрендә Татарстанның төрле төбәкләреннән җыелган күренекле язучылар белән очрашулар оештырылды.

Тантаналы кичәгә хакимият оешмалары җитәкчеләре, иҗат әһелләре, укытучылар һәм башка бик күп мәртәбәле кунаклар чакырылган иде.

**2020 елның 17 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Рәшит Ваһапов исем. Халыкара татар җыры фестивале һәм татар җыр сәнгате: тарих баскычлары, бүгенге торышы һәм үсеш юллары» темасына халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.

Конференциядә танылган галимнәр, күренекле сәнгать әһелләре, югары белем оешмалары укытучылары һәм киң җәмәгатьчелек катнашты. Программага утызга якын чыгыш кертелгән иде, алар барысы да фәнни җыентыкта урын алачак.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2020. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 26.03.2020. Басылды: 10.04.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла